# ШУРА

№ 32
2021




Рамадан мөбарәк!

ДИНИ АЛЬМАНАХ
1908 елдан бирле нәшер ителә

# ЭЧТӘЛЕК


Җомга хотбәсе . . . 5
Җомга хотбәсенең тәрҗемәсе . . . 11

ВӘГАЗЬЛӘР . . . 15
Рамазан гыйбадәтләре . . . 16
Рамазан – Коръән ае . . . 21
Рамазанда Коръән укуның фазыйләтләре . . . 26
Коръәни Кәрим – могҗиза . . . 33
Коръәни Кәримне уку әдәпләре . . . 39
Ураза гаете вәгазе . . . 44
Ураза гаете хотбәсенең гарәпчә укылышы . . . 50
Ураза гаете хотбәсенең кириллицага транслитерациясе . . . 52
Ураза гаете хотбәсенең татарчага тәрҗемәсе . . . 54
Рамазаннан соң мөселманның халәте . . . 56
Динем – Ислам . . . 61
Балаларны яклау – аларга яхшы тәрбия бирү . . . 65
Әйләнә-тирә мохитны саклау . . . 72
Зөлкагъдә ае – харам айларның берсе . . . 78
Туган илне яратуның мөһимлеге . . . 83
Харам матдәләрне куллануның зыяны . . . 86

ӘҢГӘМӘ . . . 92
«Хәләл – ул безнең тормышыбыз» . . . 93

ҮРНӘК ЗАТЛАР . . . 102
Сәгъд бине Әби Вәккас радыяллаһу ганһе . . . 103

«НӘРСӘ? КАЙДА? КАЙЧАН?» . . . 110

ТАРИХ . . . 121
Төркиядәге «Әфәнде Күпере» татар авылының барлыкка килүе 122
Хәбибрахман Шакир: меңләгән күлләр иленә сикәлтәле юл . . . 125

УРАЗА . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 128

Рамазан – сабырлык ае . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 129

Рамазан белән бәйле матди чыгымнар . . . . . . . . . . . . . . . . . 141

ХӘДИС . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 142

Ураза китабы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 143

Кадер кичәсе фазыйләтләре китабы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 160

Игътикяф китабы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 162

ТӘФСИР . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 165

Юныс галәйһиссәлам кыйссасы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 166

Коръән сүрәләре . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 174

ФӘН . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 180

Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм исламияттә беренче педагог . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 181

НӘСЫЙХӘТ . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 186

Кабер газабы һәм газапның катылыгы бәяны . . . . . . . . . . . . . 187

Олы гөнаһлар . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 201

ӘДӘБИ СӘХИФӘ . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 203

Кайнар диңгез юлы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 204

**«ШУРА» дини альманах, №32**

*апрель – июнь 2021*
*шәгъбан – зөлкагъдә1442*

Альманах Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек итү буенча федераль хезмәтнең (Роскомнадзор) Татарстан Республикасы (Татарстан) идарәсендә 2013 елның 17 нче июлендә ПИ №ТУ16-01077 нче теркәлү таныклыгы алды.

**ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ:**

Үзәкләшкән дини оешма –
Татарстан Республикасы
мөселманнары Диния нәзарәте
420021 Казан, Габдулла Тукай урамы, 38 нче йорт

Бәясе ирекле
2013 елның июленнән чыга
Басма кварталга бер тапкыр чыга
**12+**

**БАШ РЕДАКТОР:**
Камил Искәндәр улы Сәмигуллин
Телефон: +7 (843) 237-94-53 (кабул итү бүлмәсе)

**РЕДАКЦИЯ СОВЕТЫ:**
Ришат Хәмидуллин
Булат Мөбарәков
Илдус Фәиз

**ҖАВАПЛЫ СӘРКАТИП**
Телефон: +7 (843) 598-09-42

**ДИЗАЙНЕРЛАР:**
Рөстәм Даутов
Илшат Хәйретдинов

**БИТКӘ САЛУЧЫ:**
Раушан Сәйфетдияров
Ленар Хамматов

**ТЫШЛЫКТАГЫ РӘСЕМ:**
Илшат Хәйретдинов

**РЕДАКЦИЯ**

Редакциянең һәм нәшер итүченең адресы:
«Хозур» – «Тынычлык» нәшрият йорты» шәхси оешмасы
420111 Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6/27 нче йорт
Тел./факс: +7 (843) 598-09-42
Электрон почта: shura@huzur.ru
Сайт: www. huzur.ru

*Типографиянең адресы:*
*«ОТ Принт» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте типографиясендә бирелгән электрон-макетның тулы сыйфатына тәңгәлләштереп бастырылды.*
*Адрес: 420030, Казан шәһ., Жуковка ур., 2.*

Тираж – 2000 данә
Басарга кул куелды: 05.04.2021
Чыгу көне: 15.04.2021

*Редакциягә килгән язмалар кире кайтарылмый*

*Журналда тәрҗемә итеп бастырылган материалларны редакция рөхсәтеннән башка күчереп бастыру тыела*

*Журнал битләрендә Коръәни Кәримдәге аять-сүрәләр урын алганлыктан, басмага игътибарлы булуыгыз сорала*

**«СОВЕТ»**

Ежеквартальное печатное издание на татарском языке

## Җомга хотбәсе

Имам-хатыйб азанга кадәр җәмәгатькә йөзе белән карап утыра. Азан тәмамлангач, мөнбәргә басып, тавыш белән түбәндәге доганы укый.

اَلْحَمْدُ لِلّٰهِ اَلْحَمْدُ لِلّٰهِ اَلْحَمْدُ لِلّٰهِ الَّذِي هَدَانَا لِهٰذَا وَمَا كُنَّا لِنَهْتَدِيَ لَوْ لَا أَنْ هَدَانَا اللّٰهُ. وَمَا تَوْفِيقِي وَاعْتِصَامِي إِلَّا بِاللّٰهِ۞ فَسُبْحَانَ الَّذِي قَالَ فِي كِتَابِهِ الْكَرِيمِ أَسْتَعِيذُ بِاللّٰهِ: وَمَا تَشَاؤُونَ إِلَّا أَنْ يَشَاءَ اللّٰهُ۞ نَشْهَدُ أَنْ لَا إِلَهَ إِلَّا اللّٰهُ وَحْدَهُ لَا شَرِيكَ لَهُ۞ شَهَادَةً مُنْجِيَةً مِنْ عَذَابِ اللّٰهِ۞ وَنَشْهَدُ أَنَّ سَيِّدَنَا مُحَمَّدًا عَبْدُهُ وَرَسُولُهُ۞ دَاعِينَا إِلَى اللّٰهِ۞ صَلَّى اللّٰهُ تَعَالَى عَلَيْهِ وَعَلَى أَوْلَادِهِ وَأَزْوَاجِهِ وَعَلَى خُلَفَائِهِ الرَّاشِدِينَ الْمُرْشِدِينَ الْمَهْدِيِّينَ مِنْ بَعْدِهِ۞ وَوُزَرَائِهِ الْكَامِلِينَ فِي عَهْدِهِ۞ خُصُوصًا مِنْهُمْ عَلَى الْأَئِمَّةِ بِالْحَقِّ أُمَرَاءِ الْمُؤْمِنِينَ أَبِي بَكْرٍ وَ عُمَرَ وَعُثْمَانَ وَ عَلِيٍّ۞ وَعَلَى بَقِيَّةِ الصَّحَابَةِ وَالتَّابِعِينَ لَهُمْ بِإِحْسَانٍ إِلَى يَوْمِ الدِّينِ۞ رِضْوَانُ اللّٰهِ تَعَالَى عَلَيْهِمْ أَجْمَعِينَ۞ أَمَّا بَعْدُ فَيَا عِبَادَ اللّٰهِ! ۞ اِتَّقُوا اللّٰهَ وَ أَطِيعُوهُ۞ إِنَّ اللّٰهَ مَعَ الَّذِينَ اتَّقَوْا وَالَّذِينَ هُمْ مُحْسِنُونَ۞

Вәгазь өлеше. Имам вәгазьгә караган төп аятьне укый:

قَالَ اللّٰهُ عَزَّ وَ جَلَّ فِي كِتَابِهِ الْكَرِيمِ أَسْتَعِيذُ بِاللّٰهِ:

______________________________۞

Имам вәгазьгә караган төп хәдисне укый:

وَ قَالَ النَّبِيُّ صَلَّي اللهُ عَلَيْهِ وَ سَلَّمْ:

___________________________________ ۞

Вәгазьнең эчтәлегенә багышланган аять һәм хәдисләр укылганнан соң, тавыш белән түбәндәге сүзләрне укый:

أَلا إِنَّ أَحْسَنَ الْكَلَامِ وَأَبْلَغَ النِّظَامِ۞ كَلَامُ اللهِ الْمَلِكِ الْعَزِيزِ الْعَلَّامِ كَمَا قَالَ اللهُ تَبَارَكَ وَ تَعَالَى فِي الْكَلَامِ: وَإِذَا قُرِئَ الْقُرْآنُ فَاسْتَمِعُوا لَهُ وَ أَنْصِتُوا لَعَلَّكُمْ تُرْحَمُونَ۞ أَسْتَعِيذُ بِاللهِ: إِنَّ الدِّينَ عِنْدَ اللهِ الْإِسلَامُ۞

Соңыннан кулларын дога өчен күтәреп, эчтән генә түбәндәге доганы кыла. Әлеге дога утырышта укыла торган дога.

Гомумән, утырган вакытта һәртөрле дога кылына ала.

بَارَكَ اللهُ لَنَا وَ لَكُمْ۞ وَ لِسَائِرِ الْمُؤْمِنِينَ وَ الْمُؤْمِنَاتِ وَالْمُسْلِمِينَ وَ الْمُسْلِمَاتِ۞ اَلْأَحْيَاءِ مِنْهُمْ وَ الْأَمْوَاتِ۞ إِنَّكَ سَمِيعٌ قَرِيبٌ مُجِيبُ الدَّعَوَاتِ۞ بِرَحْمَتِكَ يَا أَرْحَمَ الرَّاحِمِينَ۞ وَ سَلَامٌ عَلَى الْمُرْسَلِينَ وَالْحَمْدُ لِلَّهِ رَبِّ الْعَالَمِينَ۞

Соңыннан басып, икенче хотбә буларак, түбәндәгеләрне укый:

اَلْحَمدُ لِلّه حَمْدَ الْكَامِلِينَ وَالصَّلَوةُ وَ السَّلَامُ عَلَى سَيِّدِ الْأَوَّلِينَ وَ الْآخِرِينَ۞ مُحَمَّدٍ وَآلِهِ وَ صَحْبِهِ أَجْمَعِينَ۞ تَعْظِيماً لِنَبِيِّهِ وَتَكْرِيماً لِفَخَامَةِ شَانِ شَرَفِ صَفِيِّهِ۞ فَقَالَ عَزَّ وَجَلَّ مِنْ قَائِلٍ مُخْبِراً وَآمِراً:

إِنَّ اللهَ وَمَلَائِكَتَهُ يُصَلُّونَ عَلَى النَّبِيِّ يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا صَلُّوا عَلَيْهِ وَسَلِّمُوا تَسْلِيماً۞

اَللَّهُمَّ صَلِّ عَلَى مُحَمَّدٍ، وَعَلَى آلِ مُحَمَّدٍ۞ كَمَا صَلَّيْتَ عَلَى إِبْراهِيمَ وَعَلَى آلِ إِبْراهِيمَ۞ إِنَّكَ حَمِيدٌ مَجِيدٌ۞ اَللَّهُمَّ بَارِكْ عَلَى مُحَمَّدٍ، وَعَلَى آلِ مُحَمَّدٍ۞ كَمَا بَارَكْتَ عَلَى إِبْراهِيمَ وَعَلَى آلِ إِبْراهِيمَ۞ إِنَّكَ حَمِيدٌ مَجِيدٌ۞

اَللَّهُمَّ وَارْضَ عَنِ الْخُلَفَاءِ الْأَرْبَعَةِ ذَوِى الْقَدْرِ الْجَلِيِّ وَالشَّرَفِ الْعَلِيِّ۞ سَيِّدِنَا أَبِي بَكْرٍ وَ عُمَرَ وَ عُثْمَانَ وَ عَلِيٍّ رَضِيَ اللَّهُ عَنْهُمْ۞ وَعَنِ السِّتَّةِ الْبَاقِيَةِ مِنَ الْعَشَرَةِ الْمُبَشَّرَةِ۞ وَعَنِ الْعَمَّيْنِ الْمُكَرَّمَيْنِ عِنْدَ اللهِ اَلْمُحْتَرَمَيْنِ عِنْدَ النَّاسِ۞ سَيِّدِنَا الْحَمْزَةَ وَالْعَبَّاسِ رَضِيَ اللَّهُ عَنْهُما۞ وَ عَنِ السِّبْطَيْنِ الْجَلِيلَيْنِ السَّعِيدَيْنِ الشَّهِيدَيْنِ۞ سَيِّدِنَا الْحَسَنِ وَ سَيِّدِنَا الْحُسَيْنِ رَضِيَ اللَّهُ عَنْهُما۞ وَعَنْ سَائِرِ الصَّحَابَةِ وَالتَّابِعِينَ لَهُمْ بِإِحْسَانٍ إِلَى يَوْمِ الدِّينِ رِضْوَانُ اللهِ عَلَيْهِمْ أَجْمَعِينَ۞ وَ عَنْ سَائِرِ الْمُؤْمِنِينَ وَالْمُؤْمِنَاتِ وَالْمُسْلِمِينَ وَالْمُسْلِمَاتِ۞ اَلْأَحْيَاءِ مِنْهُمْ وَالْأَمْوَاتِ۞ إِنَّكَ سَمِيعٌ قَرِيبٌ مُجِيبُ الدَّعَوَاتِ۞ بِرَحْمَتِكَ يَا أَرْحَمَ الرَّاحِمِينَ ۞

اَللَّهُمَّ انْصُرْ مَنْ نَصَرَ الدِّينَ، اَللَّهُمَّ انْصُرْ مَنْ نَصَرَ الدِّينَ، اَللَّهُمَّ انْصُرْ مَنْ نَصَرَ الدِّينَ[1] ۞ وَاخْذُلْ مَنْ خَذَلَ الْمُسْلِمِينَ۞ وَاكْتُبِ الصِّحَّةَ وَالسَّلَامَةَ عَلَيْنَا وَعَلَى الْحُجَّاجِ وَالْغُزَاةِ وَالْمُسَافِرِينَ وَالْمُقِيمِينَ وَالْحَاضِرِينَ وَالْغَائِبِينَ۞ فِي بَرِّكَ وَبَحْرِكَ وهَوائِكَ مِنْ أُمَّةِ مُحَمَّدٍ عَلَيْهِمْ أَجْمَعِينَ۞ وَ سَلَامٌ عَلَى الْمُرْسَلِينَ وَالْحَمْدُ لِلَّهِ رَبِّ الْعَالَمِينَ۞

Иң соңыннан «Әгуузү» һәм «Бисмилләһ»не эченнән генә әйтеп, түбәндәге аятьне тавыш белән укый һәм хотбә тәмам була:

إِنَّ اللهَ يَأْمُرُ بِالْعَدْلِ وَالْإِحْسَانِ وَ إِيتَاءِ ذِي الْقُرْبَى وَيَنْهَى عَنِ الْفَحْشَاءِ وَ الْمُنْكَرِ

[1] Бу вакытта җәмәгать күңелдән «Әәмин» дип әйтә.

وَالْبَغْيِ يَعِظُكُمْ لَعَلَّكُمْ تَذَكَّرُونَ۞ وَلَذِكْرُ اللهِ أَكْبَرُ وَاللهِ يَعْلَمُ مَا تَصْنَعُونَ۞

**Имам-хатыйб азанга кадәр җәмәгатькә йөзе белән утыра. Азан тәмамлангач, мөнбәргә басып, тавыш белән түбәндәге доганы укый:**

Әлхәмдүлилләәһи, әлхәмдүлилләәһи, әлхәмдүлилләәһил-ләӟии һәдәәнә лиһәәӟәә вә мәә күннәә линәһтәдийә ләү ләә ән һәдәәнәллаһ. Вә мәә тәүфиикый вәгътисаамий илләә билләәһ. Фә сүбхәәнәл-ләӟии каалә фии китәәбиһил- кәриими әстәгыйӟү билләәһи: «Вә мәә тәшәә-үүнә илләә ән йәшәә-әллаһ». Нәшһәдү ән ләә иләәһә илләллаһу. Вәхдәһү ләә шәриикә ләһү. Шәһәәдәтән мүнҗийәтән мин гаӟәбилләһи. Вә нәшһәдү әннә сәййидәнә Мүхәммәдән габдүһү вә расүүлүһү. Дәәгыйнәә иләл-лаһи. Салләллаһу тәгаалә галәйһи вә галәә әүләәдиһи вә әзвәәҗиһи вә галәә хуләфәә-иһир-раашидиинәл мүршидиинәл мәһдиййинә мин бәгъдиһи. Вә үзәраа-иһил кәәмилиинә фии гаһдиһи. Хусуусан минһүм галәәл ә-иммәти бил-хәккый үмәраа-ил мү'миниинә Әби Бәкрин вә Гумәра вә Гуҫмәәнә вә Галиййин. Вә галәә бәкыййәтис сахәәбәти вәт-тәәбигыйнә ләһүм би-ихсәәнин иләә йәүмид-дини. Ридъвәәнуллаһи тәгаалә галәйһим әҗмәгыйнә.

Әмма бәгъде: фә йәә гыйбәдәллаһ! Иттәкуллаһә вә әтыыйгууһу. Иннәллаһә мәгал-ләӟиинәт-тәкау, вәл-ләӟиинә һүм мухсинүүн.

**Вәгазь өлеше. Имам вәгазьгә караган төп аятьне укый:**

Каалә-ллаһу газзә вә җәллә фии китәәбиһил кәриими әстәгыыйӟү билләһи: ____________________

**Имам вәгазьгә караган төп хәдисне укый:**

Вә каалән нәбиййү салләллаһу галәйһи вә сәлләм: ____________________

____________________

**Вәгазьнең темасына багышланган аять һәм хәдисләр укылганнан соң, тавыш белән түбәндәгеләрне укый:**

Әләә иннә әхсәнәл кәләәми вә әбләган низаами. Кәләәмуллаһил мәликил газиизил галлләәми, кәмәә каалэллаһу тәбәәракә вә тәгаалә филкәләәми. Вә иҙәә куриәл-куръәәну фәстәмигуу ләһү вә әңсыйтү ләгалләкүм түрхәмүүнә. Әстәгыыйҙү билләһи: «Иннәд-диинә гыйңдәллаһил Исләәм».

**Соңыннан, кулларын дога өчен күтәреп, эчтән генә түбәндәге доганы кыла. Әлеге дога – утырышта укыла торган дога.**

**Гомумән, утырган вакытта Ахирәт өчен һәртөрле дога кылына ала.**

Бәәракәллаһу ләнәә вә ләкүм. Вә лисәә-ирил мү’миниинә вәл мү’минәәти, вәл мүслимиинә вәл мүслимәәти. Әл-әхьйәә-и минһүм вәл әмвәәти. Иннәкә сәмиигун кариибүн мүҗиибүд дәгавәәти. Бирахмәтикә йәә әрхәмәр-раахимиинә. Вә сәләәмүн галәәл мүрсәлиинә, вәлхәмдүлилләәһи Раббил гааләмин.

**Соңыннан, басып, икенче хотбә буларак, киләсе сүзләрне укый:**

Әлхәмдүлилләәһи, хәмдәл кәәмилиинә вәссаләәтү вәссәләәмү галәә сәййидил әүвәлиинә вәл әхыйринә Мүхәммәдин вә әәлиһи вә сахбиһи әҗмәгыйн. Тәгъзыймән линәбиййиһи вә тәкриимән лифәхаамәти шәәни шәрафи сафиййиһи. Фәкаалә газзә вә җәллә мин каа-илин мүхбиран вә әәмиран:

«Иннәллаһә вә мәләә-икәтәһү йүсаллүнә галән нәбиййи. Йәә әййүһәлләҙиинә әәмәнүү саллүү галәйһи вә сәллимүү тәслиимән». Аллаһуммә салли галәә Мүхәммәдин, вә галәә әәли Мүхәммәд. Кәмәә салләйтә галәә Ибрааһиимә вә галәә әәли Ибраһиимә, иннәкә хәмиидүн мәҗиид. Аллаһуммә бәәрик галәә Мүхәммәдин, вә галәә әәли Мүхәммәд. Кәмәә бәәрактә галәә Ибрааһиимә вә галәә әәли Ибрааһимә, иннәкә хәмиидүн мәҗиид.

Аллаһуммә вәрда ганил хуләфәә-ил әрбәгати ҙәвил кадрил җәлиййи вәш-шәрафил галиййи сәййидинәә Әби Бәкрин вә Гумәра вә Гуҫмәәнә вә Галиййин радыяллаһу ганһүм. Вә ганис-ситтәтил бәәкыйәти минәл гашәратил мүбәшшәрати. Вә ганил гаммәйнил мүкәррамәйни гыйндәллаһи әл-мүхтәрамәйни гыйндән-нәәси сәййидинәл Хәмзәтә вәл Габбәәси радыяллаһу ганһүмәә. Вә ганис сибтайнил җәлииләйнис сәгыыйдәйни әш-шәһиидәйни сәййидинәл Хәсәни вә сәййидинәл Хүсәйни радыяллаһу ганһүмәә. Вә ган сәә-ирис сахәәбәти вәт-тәәбигыйнә ләһүм би-ихсәәни иләә йәүмид-диин. Ридъвәәнуллаһи галәйһим әҗмәгыйн. Вә ган сәә-ирил мү'миниинә вәл мү'минәәти, вәл мүслимиинә вәл мүслимәәти. Әл-әхьйәә-и минһүм вәл әмвәәти. Иннәкә сәмиигун кариибүн мүҗиибүд дәгавәәти. Бирахмәтикә йәә әрхәмәр раахимин.

Аллаһуммән-сур мән нәсарад-диин. Аллаһуммән-сур мән нәсарад-диин. Аллаһуммән-сур мән нәсарад-диин[1]. Вәхҙүл мән хәҙәләл мүслимиин. Вәктүбис-сыйххәтә вәс-сәләәмәтә галәйнәә вә галәәл хүҗҗәәҗи вәл гузәәти вәл мүсәәфириинә вәл мукыыймиинә вәл хәәдыйриинә вәл гаа-ибиинә. Фии бәррикә вә бәхрикә вә һәвәә-икә мин үммәти Мүхәммәдин галәйһим әҗмәгыйн. Вә сәләәмүн галәәл мүрсәлиинә. Вәлхәмдүлилләәһи Раббил гааләмиин.

**Иң соңыннан «Әгууҙү» һәм «Бисмилләһ»не эченнән генә әйтеп, түбәндәге аятьне тавыш белән укый һәм хотбә тәмам була:**

«Иннәллаһә йә'мүру бил гадли вәл ихсәәни вә иитәә-и ҙил курбәә вә йәнһәә ганил фәхшәә-и вәл мүнкәри вәл бәгъ-ии, йәгыйзукүм ләгалләкүм тәҙәккәруун. Вәләҙикруллаһи әкбәр, вәллааһи йәгъләмү мәә тәсънәгуун».

[1] Бу вакытта җәмәгать күңелдән «Әәмин» дип әйтә.

## Җомга хотбәсенең тәрҗемәсе

Имам-хатыйб азанга кадәр җәмәгатькә йөзе белән карап утыра. Азан тәмамлангач, мөнбәргә басып, тавыш белән түбәндәге доганы укый:

Безне туры юлга күндергән Аллаһыга мактау булсын[1]. Аннан башка безне берәү дә (туры юлга) күндерә алмый.

Коръәни Кәримдә: **«Әмма Аллаһы теләми торып, сез тели алмассыз. Һичшиксез, Аллаһы – Белүче, Хикмәт иясе»**, – дип әйтүче Аллаһы – барлык кимчелекләрдән дә Пакь.

Без бердәнбер булган Аллаһыдан башка илаһның юклыгына һәм Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең Аның Расүле һәм колы булуына шаһитлык итәбез. Без Пәйгамбәребез, аның балалары, хатыннары, элек яшәп киткән изгеләребез һәм һидаять юлында булган һәркем өчен, Аллаһының рәхмәтен сорыйбыз.

Һәм аның турыдан-туры хәлифәләре – мөэминнәрнең хакимнәренә: Әбү Бәкер, Гомәр бине Хаттаб, Госман бине Гаффан, Гали бине Әбү Талиб радыяллаһу ганһүмәдән Аллаһы риза булсын. Кыямәт көнендә барлык пәйгамбәрләргә һәм табигыйннәргә Аллаһының ризалыгы һәм рәхмәте булсын.

Моннан соң Аллаһыга гыйбадәт кылучылар Аңа итагать итсен.

> **«Һичшиксез, Аллаһы – [гөнаһлардан] курыккан һәм [Раббыларының ризалыгын гына өмет итеп] игелекле гамәлләр кылган кешеләр белән».**

«Ән-Нәхл / Бал кортлары», 16:128

**Вәгазь өлеше. Имам вәгазьгә караган төп аятьне укый:**

Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтә: ____________________

1 3 тапкыр әйтелә.

**Имам вәгазьгә караган төп хәдисне укый:**

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән: ___

_______________________________________________

**Вәгазьнең эчтәлегенә багышланган аять һәм хәдисләр укылганнан соң, тавыш белән түбәндәге сүзләрне укый:**

Дөреслектә, иң дөрес һәм төзек сөйләм – ул Аллаһының Сөйләме. Коръәндә Аллаһы Тәгалә әйтүенчә:

> **«Коръән укылган чакта, аны тыңлагыз һәм дәшми торыгыз, – бәлки, сез [Аллаһы тарафыннан] рәхмәт ителерсез»;**

«Әл-Әгъраф / Киртәләр», 7:204

> **«Һичшиксез, Аллаһы хозурында [хакыйкый һәм кабул ителгән] дин – Ислам [дине генә]».**

«Әлү Гыймран / Гыймран гаиләсе», 3:19

**Соңыннан кулларын дога өчен күтәреп, эчтән генә түбәндәге доганы кыла. Әлеге дога утырышта укыла торган дога.**

**Гомумән, утырган вакытта һәртөрле дога кылына ала.**

Без Аллаһыдан барыбыз өчен дә рәхмәтен иңдерүен сорыйбыз. Мөэмин-мөселманнар өчен ярдәм ике дөньяда да булачак. Син – Ишетүче, Якын һәм догаларыбызга җавап бирәсең. Синең рәхмәтең белән, йә, Рәхимле һәм Шәфкатьле Аллаһы. Пәйгамбәрләргә сәламнәр һәм Аллаһының рәхмәте булсын. Галәмнәрнең Раббысы булган Аллаһыга мактаулар булсын.

**Соңыннан басып, икенче хотбә буларак, түбәндәгеләрне укый:**

Аллаһыга мактаулар, пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә, аның гаиләсенә, сәхабәләренә һәм аңа иярүчеләргә сәламнәребез һәм Аллаһының рәхмәте булсын.

Аллаһы Тәгалә Изге Китабыбызда әйткәнчә:

**«Һичшиксез, Аллаһы һәм фәрештәләре Нәби салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә салават әйтәләр. Ий иман китерүчеләр! Сез аңа салават әйтегез һәм [«Ий, Нәби, сиңа сәлам булсын», – дип] сәламләү белән сәлам бирегез».**

«Әл-Әхзәб / Гаскәрләр», 33:56

Йә, Аллаһы, тугры хәлифәләр: Әбү Бәкер, Гомәр бине Хаттаб, Госман бине Гаффан, Гали бине Әбү Талиб радыяллаһу ганһүмәгә һәм җәннәт белән шатландырылган алты сәхабәгә, Расүлебезнең югары дәрәҗәдә булган абыйлары – Хәмзә бине Габделмотталиб һәм Габбас бине Габделмотталибка, шәһит булып киткән сөекле оныклары Хәсән белән Хөсәенгә рәхмәтеңне иңдер. Сәхабәләр һәм табигыйннәр өчен Кыямәт көнендә Аллаһының рәхмәтен, ризалыгын ирештер.

Мөэмин-мөселманнар өчен ярдәмең ике дөньяда да булачак. Дөреслектә, Син догаларыбызны Ишетүче һәм догаларыбызга җавап бирәсең. Синең рәхмәтең белән, йә, Рәхимле һәм Шәфкатьле Аллаһы!

Йә, Аллаһы, динебез Исламга ярдәм итүчеләргә Син дә ярдәм ит (өч тапкыр әйтелә). Мөэминнәрне җәберләүчеләрне көчсезләндер. Безгә, галимнәргә, юлчыларга, исәннәргә һәм үлеләргә – пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең өммәтенә тынычлык һәм тәртип билгелә.

**Иң соңыннан «Әгуузү» һәм «Бисмилләһ»не эченнән генә әйтеп, түбәндәге аятьне тавыш белән укый һәм хотбә тәмам була:**

**«Һичшиксез, Аллаһы [һәрнәрсәне аңлатыр өчен иңдергән китабында] гадел булырга, изгелек кылырга һәм [бигрәк тә] якын**

**туганнарга [мохтаҗ булган нәрсәләрен] бирергә [һәм туганлык җепләрен ныгытуны] әмер итә. [Зина кебек] Фәхешлектән, [көферлек, ширек һәм шуның кебек дин кабул итмәгән] тыелганнан һәм [кешеләргә] җәбер-золым кылудан тыя. Сез акылга килерсез дип, сезне үгетли».**

«Ән-Нәхл / Бал кортлары», 16:90

Аллаһыны зикер итегез. Хакыйкатьтә, Ул сезнең ни кылганнарыгызны белә.

# Вәгазьләр

*9 нчы апрель вәгазе,*

*Шәгъбан аеның 27 нче көне, һиҗри исәп буенча 1442 ел*

# Рамазан гыйбадәтләре

Әлхәмдүлилләһи Раббил гааләмиин әссаләәтү вәссәләәмү галәә расүлиһи Мүхәммәдин вә галәә әәлиһи вә әсхаабиһи әҗмәгыйн. Әмма бәгъде: барча мактауларыбыз галәмнәрне юктан бар кылган Аллаһы Тәгаләгә булса иде. Һәм дә салават-шәрифләребез Аның хәбибе Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә булса иде.

Хөрмәтле дин кардәшләрем, әссәләмү галәйкүм вә рахмәтуллаһи вә бәрәкәтүһ!

Әлхәмдүлилләһи Раббил гааләмиин, без даими рәвештә Аллаһы Тәгаләгә хәмед-сәналәребезне әйтәбез. Әлхәмдүлилләһи Раббил гааләмиин, аның сөекле Расүле Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә салават-шәрифләребезне җиткерәбез.

Раббыбызның рәхмәте белән безгә шәгъбан аеның соңгы җомгасында катнашу насыйп булды. Бүген күңелләребез җилкенеп тора – берничә көннән мөбарәк Рамазан ае башланачак. Һәрбарчабызга шушы шәрәфле айның савабы дистәләтә, йөзләтә һәм меңләтә булган гыйбадәтләрен ихлас күңел белән башкару, Аллаһы Тәгаләнең шәфәгатенә ирешү насыйп булсын.

Рамазан аеның башка айлардан аерылып торган гыйбадәте ураза дибез. Ягъни бер ай дәвамында төнге вакытлардан тыш ашаудан, эчүдән, җенси якынлыктан тыелып тору. «Әл-Бәкара» сүрәсенең мәшһүр аятендә Аллаһы Тәгалә болай дип әйтә:

يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا كُتِبَ عَلَيْكُمُ الصِّيَامُ كَمَا كُتِبَ عَلَى الَّذِينَ مِن قَبْلِكُمْ لَعَلَّكُمْ تَتَّقُونَ ﴿١٨٣﴾

**«Ий иман китерүчеләр! Сездән алда килеп киткәннәргә [фарыз булып] язылган кебек, сезгә дә [Рамазан аендагы] ураза [фарыз буларак] язылды. Бәлки, [ачлык ярдәме белән гөнаһлардан сакланып] тәкъвалык ияләреннән булырсыз!»**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:183

Күпләребезнең бу аятьне, аның туган телебезгә тәрҗемәсен, тәфсирен ишеткәне бар. Әмма Раббыбызның шушы сүзләрен күңелебезгә сеңдерәбезме? Аллаһы Тәгалә Рамазан аенда ураза тотуны безгә мәҗбүри рәвештә йөкләде икән – аны һичшиксез тотарга тиешбез. Әйе, балигъльк яшенә җитмәгәннәр, сәфәрдә булганнар, сәламәтлекләре сәбәпле тота алмаучылар өчен искәрмәләр бар. Әмма болар барысы да – аерым очраклар. Асыл нигезендә, ураза – һәр мөселман ир-аты һәм хатын-кызы өчен фарыз гыйбадәт.

Нәрсә соң ул гыйбадәт дигән сорауга да шунда җавапны табарбыз: уразаны без ябыгу өчен дә, организмыбызны чистарту өчен дә, җәмгыятьтә мактану өчен дә тотмыйбыз. Без Аллаһы Тәгаләнең боерыгын үтибез, гыйбадәт кылабыз, ягъни Раббыбызга тәкъвалыгыбызны гамәлебез белән дәлиллибез. Шуңа да уразаның асыл максаты ач тору түгел, ә Хак Тәгаләнең ризалыгына ирешү булырга тиеш.

Аллаһы Тәгалә Адәм балаларын шулкадәр ярата, безнең һәр гамәлебез, ниятебезгә карап, гыйбадәт була ала. Ашау да, йоклау да, гаилә әгъзаларын бүләк белән сөендерү дә, балаларга тәрбия бирүне дә – Аллаһы исеме белән башлыйбыз, Раббыбыз ризалыгына ирешергә теләп эшлибез икән – барысы да гыйбадәт. Шул ук Рамазан уразасының хәтта сәхәре белән ифтарында да савапка ирешә алабыз, гөнаһлы булуыбыз да

бик ихтимал. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм сөннәтенә ияреп, сәхәрнең саваплы вакыт икәнен танып ризыкланабызмы, әллә кадерле мизгелләрне йокыга тотабызмы? Ифтарда ризыкны кирәк кадәр генә ашыйбызмы, әллә исраф кылабызмы? Ашаган ризыгыбыз хәләлме, әллә шиклесе дә бармы? Сәхәр-ифтарларда мескен-ятимнәрне искә алабызмы, күршеләребез белән бүлешәбезме, әллә үзебезнең тамак туклыгы белән канәгатьләнебезме?

Әлбәттә, мөселманнарга бурыч итеп йөкләнелгән, башкару рәвешләре билгеләнелгән гыйбадәтләр бар. Әйтеп үтелгәнчә, ураза тоту Рамазан аенда гына фарыз. Башка айларда да берничә көн тотабыз икән – савап алабыз, иншәАллаһ, юк икән – гөнаһлы булмыйбыз. Ә биш вакыт намаз – көндәлек бурычыбыз. Рамазан аенда тагын бер намаз өстәлә – тәравих намазы. Хәнәфи мәзһәбендә ул 20 рәкагать итеп укыла. Һәр дүрт рәкагать саен зикер-тәсбихләр әйтелә, шул арада намаз укучылар ял итә. Тәравих намазы фарыз түгел, әмма аны ихлас белән укыйбыз икән – савабы бихисап булыр.

Аллаһының Расүле салләллаһу галәйһи вә сәлләм хәдис-шәрифендә болай дип әйтә: «Әгәр минем өммәтем Рамазан ае үз эченә никадәр саваплар алганын белсә, аның ел буе дәвам итүен теләр иде».

Рамазанның адәм баласы белеп бетерә алмас нигъмәтләре бар. Димәк, ураза гына фарыз дип, башка гыйбадәтләрне игътибардан чыгармыйк. Тәравихларын да калдырмыйк, төнге тәһәҗҗөд намазларын да укыйк. Рамазан – Коръән ае. Күбрәк игътибарыбызны Аллаһының Китабына юнәлдерик. «Әл-Бәкара» сүрәсендә Раббыбыз болай дип әйтә:

شَهْرُ رَمَضَانَ الَّذِي أُنزِلَ فِيهِ الْقُرْآنُ هُدًى لِّلنَّاسِ وَبَيِّنَاتٍ مِّنَ الْهُدَىٰ
وَالْفُرْقَانِ ۚ ﴿١٨٥﴾

**«Рамазан ае – аңарда кешеләр өчен һидаять, туры юлны күрсәткән ачык дәлилләр, хакны ялганнан аерган Коръән иңдерелгән [ай]...»**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:185

Бу дөнья – фани. Монда без ничек яшәсәк – мәңгелек дөньяда йә җәннәтле булырбыз, йә җәһәннәмгә эләгербез. Рамазан – һәрберебез өчен җәннәткә якынаю өчен форсат. Шул ук намазын да укыйбыз, зикер-тәсбихләрен дә әйтәбез, садакасын да бирәбез – әмма савабы бермә-бер булыр. Аллаһы Тәгаләнең рәхмәте белән, шәйтаннар богаулы чорда изгелекләр кылу да җиңелрәк. Башыбызга яман уй килде икән – димәк, шушы Рамазан аеның гыйбадәтләре белән калебебезне чистарту, ниятләребезне дөресләү кирәк. Намазны пенсиядә укырмын, ураза тоту миңа тиеш түгел, мескен-ятимгә байлар ярдәм итсен, дип фикер йөртәбез икән – болар барысы да үзебезнең күңелебездә. Иблис бит богаулы. Дөрес нәтиҗәләр ясый алсак иде.

Рамазан – ул форсат. Бик күпләр шушы Рамазан аена ирешергә, уразасын тотарга, Коръән хәтем кылырга, намазларын укырга, садакаларын бирергә, изгелекләрен арттырырга теләр иде, әмма күз алдыгызга китерегез: ничәмә-ничә кардәшебез узган Рамазаннан соң бакыйлыкка күчте.

Рамазан гыйбадәтләрен калдырмыйк. Аның нигъмәтләрен әрәм итмик. Рамазанны исән-сау килеш каршы алып, Гаеттә анадан яңа туган сабый кебек очрашу насыйп булсын. Рамазанда кылган изгелекләребезне ел дәвамында туктатмыйча, бөтен тормышыбызны күркәм бер гыйбадәт итә алсак иде.

* * *

Фузаил бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул булына торган бер догам барлыгын белсәм, мин җитәкче өчен дога кылар идем», – дип әйткән.

Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә президентыбыз – Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядькәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең, телебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Рөстәм хәзрәт Хәйруллин,*

*«Гаилә» мәчете имам-хатыйбы*

*16 нчы апрель вәгазе*

*Рамазан аеның 4 нче көне, һиҗри исәп буенча 1442 ел*

# Рамазан – Коръән ае

Әгууҙү билләәһи минәш-шәйтаанир-раҗиим. Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим. Әлхәмдүлилләәһи Раббил гааләмиин әссаләәтү вәссәләәмү галәә расүлиһи кәрим вә галәә әәлиһи вә әсхаабиһи әҗмәгыйн.

Барлык галәмнәрнең Раббысы булган, безне Үзенең төрле нигъмәтләре белән бүләкләгән Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгаләгә хәмед һәм сәналәр, барча мактауларыбыз, олуглауларыбыз булса иде. Аллаһы Тәбарәкә вә Тәгаләнең Хәбибе һәм Хак Расүле, галәмнәргә рәхмәт булarak җибәрелгән сөекле пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләм хәзрәтләренә, аның хөрмәтле гаиләсенә, барлык сәхабәләренә сәламнәребез һәм салаватларыбыз булса иде.

Бөтен көннәрнең солтаны, ике гаеттән дә олуграк булган мөбарәк җомга көнне, Аллаһы Тәгаләнең рәхмәтенә ирешер өчен, мәчетебезгә җыелган мөхтәрәм дин кардәшләрем! Әссәләмү галәйкүм вә рахмәтуллаһи вә бәрәкәтүһ!

Бүгенге вәгазебездә Коръәннең иңә башлау тарихы, китап булып җыелуы хакында сөйләшербез.

Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм пәйгамбәр булганчы пәйгамбәрлеге һәм вәхи иңәчәге хакында бернәрсә дә сөйләмәгән. Ул шулай буласын алдан үзе дә белмәгән һәм көтмәгән. Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

وَمَا كُنتَ تَرْجُو أَن يُلْقَىٰٓ إِلَيْكَ ٱلْكِتَٰبُ إِلَّا رَحْمَةً مِّن رَّبِّكَ ۖ فَلَا تَكُونَنَّ ظَهِيرًا لِّلْكَٰفِرِينَ ﴿٨٦﴾

**«[Расүлем! Мәккәгә кире кайту өметеңне өзмә. Пәйгамбәрлегеңнән алда] Син бу китапның сиңа вәхи ителәчәгенә өметләнми идең, ләкин Раббыңнан, бер рәхмәт буларак [мондый бер китап сиңа иңдерелде]. Шуңа кяферләргә ярдәмче булма».**

«Әл-Касас / Кыйсса», 28:86

Коръән иңүе Мәккә кырыенда урнашкан Хира тавы мәгарәсендә, ягъни тау куышлыгында 610 елда, Рамазан аеның Кадер кичәсендә башлана. Моннан алдарак Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм ошбу мәгарәдә ялгызы калып, күп вакытын Аллаһыга гыйбадәттә үткәрә иде. Берничә көн үткәч, хатыны Хәдичә радыяллаһу ганһә янына кайтып, кирәкле әйберләрен алып, яңадан шул тау куышлыгына китә иде.

Иң беренче аятьләр шушы Хира тавы мәгарәсендә иңә. Бу – «Әл-Галәк» сүрәсенең беренче биш аяте. Җәбраил галәйһиссәлам килеп, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә: «Укы», – дип әйтә. Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Мин укый белмим», – дип җавап кайтара. Шуннан соң Җәбраил галәйһиссәлам Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмне бик каты итеп кысып ала. Җибәргәч, тагын: «Укы», – дип әйтә. Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм янә: «Мин укый белмим», – дип кабатлый. Шуннан соң тагын кысып ала һәм җибәргәч тагын: «Укы», – дип әйтә. Пәйгамбәребез тагын: «Мин укый белмим», – дигәч, Җәбраил галәйһиссәлам аны өченче тапкыр кысып ала һәм җибәргәч болай дип әйтә:

اقْرَأْ بِاسْمِ رَبِّكَ الَّذِي خَلَقَ ﴿١﴾ خَلَقَ الْإِنسَانَ مِنْ عَلَقٍ ﴿٢﴾ اقْرَأْ وَرَبُّكَ الْأَكْرَمُ ﴿٣﴾ الَّذِي عَلَّمَ بِالْقَلَمِ ﴿٤﴾ عَلَّمَ الْإِنسَانَ مَا لَمْ يَعْلَمْ ﴿٥﴾

**«[Расүлем! Һәрнәрсәне юктан бар итеп] Яратучы Раббың исеме белән [башлап, Коръәнне] укы! Ул кешене [сөлек кебек ана-**

**лыкка ябышып, кан имеп тукланган, аталандырылган күкәй күзәнәктән гыйбарәт булган] оеган каннан яратты. Укы! Синең Раббың – чиксез юмартлык Иясе. [Ул бернәрсә сорамыйча бирә]. Ул каләм белән [язу язарга] өйрәтүче. Кешегә [ишетү, күрү һәм аңлау кебек сәләтләр биреп һәм аятьләр иңдерү белән дәлилләр биреп] белмәгән нәрсәләрен өйрәтүче».**

«Әл-Галәк / Оешкан кан», 96:1-5

Коръәни Кәрим 23 ел дәверендә пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә аять-аять иңдерелә.

Беренче 13 ел дәвамында пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм Мәккәдә булганда – Мәккә аятьләре һәм Мәдинәгә һиҗрәт кылгач, 10 ел дәвамында Мәдинә аятьләре иңгән. Аятьләр иңгән саен, Аллаһының Расүле салләллаһу галәйһи вә сәлләм аларны язарга әмер иткән. Пәйгамбәребезнең сәхабәләре аларны агач кабыкларында, ташларда, тиреләрдә һәм хайван сөякләрендә яза торган булган.

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең вафатыннан соң, Коръәнне яттан белгән бик күп сәхабәләр калган һәм аларда Коръәннең кулдан язылган күчермәләре булган.

632 елда Йәмамә сугышында күп хафизлар һәм Коръәнне язган сәхабәләр шәһит булгач, мөселман өммәте каршында Коръәнне саклап калу мәсьәләсе килеп туган.

Әбү Бәкер радыяллаһу ганһе хәлифәлек иткән дәверендә, барлык Коръән язучыларны җыеп, бөтен язмаларыннан бер китап җыярга куша һәм Зәйд бине Сәбит радыяллаһу ганһене аларның җитәкчеләре итеп билгели. Бу бердәнбер нөсхә була. Әбү Бәкер радыяллаһу ганһе үзе үк бу беренче кулъязманы саклаучы итеп билгеләнә һәм үлгәнче аны үзендә саклый. Аның вафатыннан соң, бу нөсхә Гомәр радыяллаһу ганһегә бирелә һәм, ул шәһит булып киткәнчегә кадәр, анда саклана.

Бервакыт Гомәр радыяллаһу ганһе нык итеп яралана һәм Коръән кулъязмаларын сакларга кызы Хафсага тапшыра.

Акрынлап Ислам дине төрле илләргә (Фарсы һәм Византия һ.б. дәүләтләргә) тарала башлый. Андагы халык гарәп телен белмәгән һәм алар арасында гарәпләрнең кайсы диалекты дөресрәк булуы мәсьәләсендә бәхәсләр туган.

Өченче хәлифә булган Госман радыяллаһу ганһе Коръәнне бер уку стандартына китерү җаваплылыгын үз өстенә ала. Ул исән булган барлык Коръән язучы сәхабәләрне җыя һәм Хафса радыяллаһу ганһәдә булган китапның нөсхәләрен язарга әмер итә. Барлыгы 6 нөсхә әзерлиләр. Калган башка төрле язмалар юк ителә. Шушы алты китапның икесе Мәккә белән Мәдинәдә кала. Калган дүртесен дөньядагы иң мөһим булган ислам мәркәзләренә: Басра, Куфа, Шам һәм Бәхрәенгә дүрт хафиз белән җибәрелә. Соңрак тәҗвид галимнәре тарафыннан, гарәп теле белмәгән халыкларга укырга җиңелрәк булсын өчен, Коръәнгә нокта, хәрә, тукталыш хәрефләре өстәлә. Шулай итеп, Аллаһы Тәгалә Үзе вәгъдә иткәнчә Коръәни Кәримне бүгенге көнгә хәтле саклап кала.

Хөрмәтле дин кардәшләрем! Аллаһы Тәгалә ошбу мөбарәк җомга көннәрендә кылган гыйбадәтләребезне кабуллардан кылса иде. Ике җомга арасында кылган гөнаһларыбызны, хата-кимчелекләребезне кичерсә иде. Раббыбыз һәммәбезгә дә мөэмин-мөселманнарга вәгъдә иткән җәннәтләренә керергә насыйп әйләсә иде. Әәмин.

* * *

Фузаил бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул булына торган бер догам барлыгын белсәм, мин җитәкче өчен дога кылар идем», – дип әйткән.

Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә президентыбыз – Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт

итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядъкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең, телебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Илнур хәзрәт Хәйруллин,*

*ТҖ МДНнең Шәригать сораулары бүлегенең баш белгече,*

*Коръәнне өйрәнү үзәгенең җитәкчесе, Коръән-хафиз*

*23 нче апрель вәгазе,*

*Рамазан аеның 11 нче көне, һиҗри исәп буенча 1442 ел*

# Рамазанда Коръән укуның фазыйләтләре

Бөтен дөньяларны юктан бар кылып, безгә җан иңдереп һәм күп төрле нигъмәтләрен бирүче Аллаһы Тәгаләгә шөкерләр һәм данмактаулар булса иде. Пәйгамбәрләребезнең соңгысы булган Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә күңелебезнең иң түрләреннән чыккан салават-шәрифләребез ирешсә иде.

Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйткән:

شَهْرُ رَمَضَانَ الَّذِي أُنزِلَ فِيهِ الْقُرْآنُ هُدًى لِّلنَّاسِ وَبَيِّنَاتٍ مِّنَ الْهُدَىٰ وَالْفُرْقَانِ ۚ

**«Рамазан ае – аңарда кешеләр өчен һидаять, туры юлны күрсәткән ачык дәлилләр, хакны ялганнан аерган Коръән иңдерелгән [ай]...»**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:185

Рамазан ае – ул ураза тоту, дога кылу, күп гыйбадәтләр ае гына түгел, бу ай – Коръән ае да. Бу айда бөек, мөбарәк Кадер кичендә Коръән инде. Коръәннең тәфсирен иң яхшы белүче сәхабәләрнең берсе Габдулла бине Габбас әйтүенчә, Коръән Кадер кичендә Ләүхүл-Мәхфүздән беренче күккә иңдерелде һәм шуннан Җәбраил галәйһиссәлам Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә 23 ел эчендә өлешләп-өлешләп китереп торды. Башка китаплардан аермалы буларак, Аллаһы Коръәнне Пәйгамбәребезгә, Мусага Синай тавында Тәүратны биргән кебек, әзер ки-

тап буларак тапшырмады, ә өлешләп бирде. Коръәннең өлешләп иңүендә зур хикмәтләр бар. Аллаһы Тәгалә аларны Коръәндә искә ала:

1. Аллаһы Пәйгамбәребезне ныгытып торды, аны юатты һәм көрәшкә рухландырды.

كَذَٰلِكَ لِنُثَبِّتَ بِهِ فُؤَادَكَ ۖ وَرَتَّلْنَاهُ تَرْتِيلًا ﴿٣٢﴾

**«...Аның белән синең күңелеңне куәтләндерик [тә аны җиңел генә хәтереңдә калдыр] дип [аны егерме өч ел кебек дәвамлы вакыт эчендә өлешләп иңдердек]. Һәм Без аны тәфсилләп бәян иттек».**

«Әл-Фүркан / Аеручы», 25:32

Мөшрикләр Пәйгамбәребезне төрле әшәке сүзләр белән рәнҗеттеләр, аңа сихерче, ялганчы дип яла яктылар, төрле каршылыклар күрсәттеләр. Болар барысы да аның күңелен төшерә, аны борчый иде. Бу хакта Раббыбыз болай дип әйткән:

فَلَا يَحْزُنكَ قَوْلُهُمْ ۘ إِنَّا نَعْلَمُ مَا يُسِرُّونَ وَمَا يُعْلِنُونَ ﴿٧٦﴾

**«Шуңа күрә аларның [Аллаһы Тәгалә хакындагы инкяр һәм ширек тулы, синең хакта исә нәфрәтле һәм мыскыллы] сүзләре сине борчымасын. Без алар яшергән нәрсәне дә, күрсәткән нәрсәне дә беләбез».**

«Йәсин», 36:76

Әмма Аллаһы аңа Җәбраил галәйһиссәламне җибәреп аятьләр иңдереп торгач: «Аллаһы минем белән бит, мин ялгыз түгел», – дип рухланып, үзенә көч ала торган булды. Әгәр дә аңа вәхи килү бераз туктап торса, ул моның өчен бик кайгырды һәм Җәбраил галәйһиссәламне сагынып көтә торган иде.

2. Мөэминнәрнең ихласлыкларын һәм аларны диндә ныгыту өчен, Коръәннең өлешләп иңүе сәхабәләрне әкренләп тәрбияләде, камилләштерде. Алар үзләре дә Пәйгамбәребезнең аларга Аллаһының яңа аятьләрен укуын көтәләр иде.

3. Коръән аятьләре сәхабәләрнең күңелләрендә нык уелып калсын, алар аятьләрнең иңү сәбәпләрен белеп, яхшы аңласыннар һәм аларга аятьләрне ятларга җиңелрәк булсын өчен.

4. Кяферләрнең, монафикъларның һәм яһүдиләрнең мәкерләрен фаш итү өчен.

Шуңа күрә бу аларга бер дә ошамый иде, аларның планнары җимерелә иде.

وَقَالَ الَّذِينَ كَفَرُوا لَوْلَا نُزِّلَ عَلَيْهِ الْقُرْآنُ جُمْلَةً وَاحِدَةً ۚ

**«Кяфер булган кешеләр [синең пәйгамбәрлегеңә каршы төшәр өчен]: «[Бүтән пәйгамбәрләргә иңдерелгән китаплар кебек] Коръән [дә] аңа нишләп тулысынча берьюлы иңдерелмәде?» – диде».**

«Әл-Фүркан / Аеручы», 25:32

5. Бирелгән сорауларга, килеп туган мәсьәләгә җавап бирү өчен, нинди генә хәл, вакыйга булмасын, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә шунда ук бу хакта аятьләр иңә иде.

6. Коръәннең Аллаһыдан килгәнен исбатлар өчен. Кяферләр: «Коръәнне Мөхәммәд үзе язды, яки аңа кемдер әйтеп торды, яки ул элекке китаплардан күчереп алды, яки ул эпилепсия белән чирләп, өянәк вакытында аңа төрле сүзләр ишетелгән. Ул шуларны Аллаһыдан дип аңлаган», – дип һәм башка төрле шуңа охшаш сүзләр сөйләделәр һәм сөйлиләр. Мөшрикләр һәм яһүдиләр Пәйгамбәребезне тикшереп, төрле сораулар

бирәләр иде. Шуннан соң бик тиздән аларга җавап та килә торган булды. Бу аларны аптырашта калдыра иде.

7.

فَإِنَّهُمْ لَا يُكَذِّبُونَكَ وَلَـٰكِنَّ الظَّالِمِينَ بِآيَاتِ اللَّهِ يَجْحَدُونَ ﴿٣٣﴾

**«Алар [синең хаклыгыңны белгәннәре өчен, асылда] сине ялганчыга санамыйлар, ләкин залимнәр Аллаһының аятьләрен [хак булганын белә торып] инкяр итәләр».**

«Әл-Әнгам / Терлек», 6:33

Коръән – Аллаһының Китабы, Аның Сүзләре. Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнән соң бүтән пәйгамбәр булмас һәм Китап та иңмәс. Аллаһы Коръән белән Үзенең динен төгәлләде, камил кылды. Коръәндә:

الْيَوْمَ أَكْمَلْتُ لَكُمْ دِينَكُمْ وَأَتْمَمْتُ عَلَيْكُمْ نِعْمَتِي وَرَضِيتُ لَكُمُ الْإِسْلَامَ دِينًا ۚ

**«Бүген сезнең өчен динегезне камил иттем, [Мәккәне алуны насыйп итү белән динегезне бөтен, ялган диннәрдән өстен кылып] сезгә нигъмәтемне тәмамладым һәм сезнең өчен, дин буларак, Исламнан канәгатьмен»**, – дип әйтелгән.

«Әл-Маидә / Табын», 5:3

Коръәннең үзенчәлеге тагын шунда ки: Аллаһы башка китапларны һәм расүлләрне билгеле бер халыкка гына җибәрде. Мәсәлән, Тәүрат һәм Инҗил китаплары бары тик яһүдиләргә генә бирелгән иде. Ә Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм бөтен халыкларга да җибәрелде һәм Коръән дә бөтен халыклар өчен дә иңдерелде. Аллаһы Коръәндә тормышның максаты һәм мәгънәсен аңлата, кеше үзен борчыган сорауларына җавапны шуннан таба. Исламга килгән күп кеше, үзләренең исламга килү тарихларын сөйләгәндә, үзләренең күп китап-

лар укулары, хаклыкны күп эзләүләре хакында сөйли. Ә инде ахырдан Коръәнне алып укыгач, үзләренең тәэсирләнгәннәрен, борчыган сорауларына җавап табуларын һәм, ниһаять, тынычланулары хакында сөйли.

**Коръән уку өстенлеге**

Галимнәр Коръән уку белемен иң хөрмәтле белемнәрдән дип әйтте. Аллаһы Үзе безгә шуны әмер итә:

وَرَتِّلِ الْقُرْآنَ تَرْتِيلًا ﴿٤﴾

**«...Коръәнне тәртил белән [әкрен-әкрен, ачык итеп] укы».**

«Әл-Мүзәммил / Чорналган», 73:4

Коръән укуның өстенлеге хакында Аллаһы Коръәннең үзендә дә искә ала, мәсәлән:

الَّذِينَ آتَيْنَاهُمُ الْكِتَابَ يَتْلُونَهُ حَقَّ تِلَاوَتِهِ أُولَٰئِكَ يُؤْمِنُونَ بِهِ ۗ وَمَن يَكْفُرْ بِهِ فَأُولَٰئِكَ هُمُ الْخَاسِرُونَ ﴿١٢١﴾

**«Кешеләр Без биргән [Тәүрат һәм Инҗил дигән] китапны хак уку белән укыйлар [сүзләрен үзгәртмиләр, мәгънәсенә төшенәләр]. Алар аңа ышаналар. Кем дә кем [Китапны үзгәртеп яки хөкемнәрен кире кагып] аны инкяр итсә, шулар – [үзләрен матди һәм рухи зарарга дучар итеп] югалтучылар».**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:121

Хак уку белән уку, Ибне Мәсгуд радыяллаһу ганһе һәм Ибне Габбас радыяллаһу ганһе аңлатуынча, ул укыган белән гамәл кылу, укыган белән яшәү, андагы хәләлне хәләл итеп һәм харамны харам итеп алу буладыр. Менә болар чын мөэминнәр булырлар. Ә Гомәр бине Әл-Хаттаб радыяллаһу ганһе фикеренчә, хак уку – ул Аллаһының рәхмәте хакында

аятьләр укылганда, Аның рәхмәтен сорау, газап хакында аятьләр укылганда, Аллаһыга сыенудыр.

Коръәнне уку өстенлекләре, әлбәттә, Сөннәттә дә килә:

1. Коръәннең һәр хәрефе өчен әҗер булыр.

Пәйгамбәребез болай дип әйткән: «Кем Аллаһының китабынан бер хәреф укыса, аңа бер изгелек язылыр. Ә бу изгелек тагы ун тапкырга арттырылыр. Мин «Әлиф Ләм Мим» бер хәреф дип әйтмим, әмма «Әлиф» – ул бер хәреф, «Ләм» – ул бер хәреф, «Мим» – ул бер хәреф[1].

2. Коръән укучы янында фәрештәләр булыр.

Пәйгамбәребез болай дип әйткән: «Коръәнне оста укучы белән илче фәрештәләр булыр. Ә кем инде Коръәнне тотлыгып, авырлык белән укыса, аңа ике әҗер булыр».[2]

3. Коръән укучының күңеленә тынычлык иңәр һәм рәхмәт аны чолгап алыр.

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Әгәр бер төркем кеше Аллаһының йортына җыелып, Аллаһының Китабын укыса һәм аны өйрәнсә, аларга тынычлык иңәр, һәм рәхмәт аларны чолгап алыр, фәрештәләр аларны каплар һәм Аллаһы аларны Үзе янындагыларга мактап искә алыр», – дип әйткән.[3]

4. Коръән укучысына шәфәгатьче булыр.

Пәйгамбәребез: «Коръәнне укыгыз, чөнки ул укучыларына Кыямәт көнендә шәфәгатьче булыр», – дигән.[4]

Коръән – ул һидаятьне, туры юлны күрсәтүче дә, нур да, тәннәргә һәм җаннарга шифа да. Ул берәүләрне югары күтәрә, ә берәүләрне түбән итә. Ул – Аллаһының рәхмәте, ул тиңе булмаган могҗизадыр.

---

[1] Имам Әт-Тирмизи хәдисләр җыентыгыннан.

[2] Имам Әл-Мөслим хәдисләр җыентыгыннан.

[3] Шуннан ук.

[4] Шуннан ук.

Әмма без бу Китапның кадерен генә аңлап бетермибез, аңа карата без гафилбез. Коръәндә:

أَفَلَا يَتَدَبَّرُونَ الْقُرْآنَ أَمْ عَلَىٰ قُلُوبٍ أَقْفَالُهَا ﴿٢٤﴾

**«Алар Коръән турында һич уйламыйлармы [моның кадәр нәсыйхәтләргә карамастан, шундый хәлгә төшәләр]? Әллә [каты һәм надан] йөрәкләрендә йозаклар бармы?»** – дип әйтелгән.

«Мөхәммәд», 47:24

Сәхабәләрнең һәм табигыйннәрнең Коръән укуларына игътибар итсәк, әлбәттә, без алар кебек булдыра алмабыз. Әмма көнгә, иң кимендә, бер-ике бит укуны барыбыз да булдырабыз. Бу вакытта без Коръәнгә карата гафилләрдән һәм Коръәнне калдыручылардан булмабыз. Иң мөһиме: Коръән көн саен безнең кулда булсын, бигрәк тә бу мөбарәк Рамазан аенда. Гафил булмыйк, Коръәнне укыйк һәм укырга өйрәник.

* * *

Фузаил бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул булына торган бер догам барлыгын белсәм, мин җитәкче өчен дога кылар идем», – дип әйткән.

Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә президентыбыз – Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядькәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең, телебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Марат хәзрәт Сәйфетдинов,*

*Балтач Үзәк мәчетенең икенче имамы*

*30 нчы апрель вәгазе,*

*Рамазан аеның 18 нче көне, һиҗри исәп буенча 1442 ел*

# Коръәни Кәрим – могҗиза

Барча галәмнәрнең Раббысы, тәрбиячесе, яратучысы булган Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгаләгә барча хәмед-сәналәребез ирешсен. Шулай ук йөрәкләребезнең түреннән чыккан салават-шәрифләребез, юлбашчыбыз, пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә ирешсен. Хөрмәтле мөселманнар, шушы изге җомга көне белән сезне тәбрик итәм. Аллаһы Тәгалә барчагызга да күңелләрегездәге изге ният, морад-максатларыгызга ирешергә насыйп әйләсен. Күңелләребездә булган барча начар сыйфатларыбыздан арынырга насыйп итсен. Безләрнең бүгенге көнебезне кичәгеләреннән, иртәгесе көннәребезне бүгенгесеннән хәерлерәк кылса иде.

Мөхтәрәм дин кардәшләрем! Аллаһы Тәгалә безне изге китабы – Коръәни Кәрим белән бүләкләде. Бу бик зур нигъмәттер. Аның эчтәлеге, һәр хәрефе һәм хәтта хәрәкәсе дә үзе бер хикмәттер, дусларым. Аны ачуга ук, дога һәм Аллаһыга хәмед-сәна чагылышы – «Фатиха» сүрәсе. Бик зур көчкә һәм хикмәткә ия булган сүрә ул. Аннан Аллаһы Раббыбыз болай дип әйтә:

الم ﴿١﴾ ذَٰلِكَ الْكِتَابُ لَا رَيْبَ ۛ فِيهِ ۛ هُدًى لِّلْمُتَّقِينَ ﴿٢﴾

**«Әлиф ләәәм миием. Ул – [пәйгамбәрләр (галәйһимуссәлам) хәбәр иткән] үзендә бер шик тә булмаган, мөттәкыйләр [Аллаһы рәхмәтен югалтудан куркучы тәкъвалар] өчен юл күрсәтә торган Китап».**

«Фатиха / Ачучы», 1:1-2

Уйлап карыйк, кайсы автор үзенең китабы турында 100% шундый гарантия бирә ала? Кем бу китапта бернинди ялгышлык юк дип әйтә ала? Кайсы китапны уку йөрәкләрне дәвалый, сукырларга күрү сәләтен, чукракларга ишетү сәләтен ача? Кайсы китапның авторы барча шагыйрь вә галимнәр турында, нинди генә гыйлем, булсын ул химия, физика, тыйб (медицина), психология, география, гомумән, нинди генә өлкәне алсаң да, шуларның барчасына да туры китереп, бер ялгышмый яза ала? Әлбәттә, бу – фикерләүчеләр өчен зур могҗиза.

Моннан тыш, Коръәни Кәримнең эчтәлегендә хәзерге замандагы меңләгән фәнни ачышлар хакында инде 1400 еллар элек китерелгән. Мәсәлән:

وَأَنَّهُ خَلَقَ الزَّوْجَيْنِ الذَّكَرَ وَالْأُنثَىٰ ﴿٤٥﴾ مِن نُّطْفَةٍ إِذَا تُمْنَىٰ ﴿٤٦﴾

**«Һичшиксез, Ул [һәртөрле җан иясен] пар итеп – ирне һәм хатынны яратты. [Ананың аналыгына] Атылган су тамчысыннан».**

«Ән-Нәҗм / Йолдыз», 53:45-46

Коръән иңгәнчегә хәтле гарәпләр баланың кыз булып тууы хатынкызга бәйле дип уйлаганнар. Аллаһы Тәгалә бу аять аркылы кешеләргә баланың малай яки кыз булып тууы ир-атның хромосомаларына бәйле булуы хакында хәбәр итә.

Фәнни яктан бу хакыйкать бары тик хромосомаларны ачкач кына билгеле була. Кешедә хромосомалар барлыгын 1882 елда Вальтер Флеминг исемле немец анатомигы ача. Әйткәнебезчә, Аллаһы Тәгалә 14 гасыр элек үк инде кешеләргә баланың җенесе ир-ат хромосомаларына бәйле булуы турында хәбәр итә.

Икенче бер мисални карап үтик.

هُوَ الَّذِي جَعَلَ الشَّمْسَ ضِيَاءً وَالْقَمَرَ نُورًا وَقَدَّرَهُ مَنَازِلَ لِتَعْلَمُوا عَدَدَ السِّنِينَ

وَالْحِسَابَ ۚ مَا خَلَقَ اللَّهُ ذَٰلِكَ إِلَّا بِالْحَقِّ ۚ يُفَصِّلُ الْآيَاتِ لِقَوْمٍ يَعْلَمُونَ ﴿٥﴾

**«Ул – кояшны бер яктылык, айны исә бер нур итеп Яратучы һәм [дини-дөньяви бик күп эшләрегезгә бәйле булган] елларның санын һәм [айларның, көннәрнең] хисабын белүегез өчен аларның һәрберенә [айлык һәм еллык сәфәрләрендә] тукталу фасылларын билгеләүче. Аллаһы боларны [хикмәт һәм файда китергән өстен максатларга юнәлгән] бер хак белән яратты. Ул [җиһанның яратылышындагы хикмәтләрне һәм иңдерелгән аятьләрдәге гыйлемнәрне] белүче кешеләр өчен аятьләрен тәфсилләп аңлата».**

«Юныс», 10:5

Аллаһы Тәгалә бу аятьтә кояшка карата «дыя» – ضِيَاءٌ, ә айга карата «нур» – نُورٌ дигән сүзләрне куллана. Гарәп телендә «дыя» – җылылык чыгаручы яктылыкны, ә «нур» – җылылыгы булмаган яктылыкны аңлата. Шушы аять аркылы Аллаһы Тәгалә кояшның кайнар җисем, ә айның салкын җисем булуы турында хәбәр итә. Астрономия фәненнән билгеле булганча, ай җир шарына кояштан килгән яктылыкны гына чагылдыра, ә кояшка килсәк, ул үзе яктылык белән җылылык чыганагы булып тора. Аның өслегендәге температура цельсий буенча 6000 градус. Аллаһының хикмәте чиксез.

Шулай ук Коръәннең хак китап булуын башка аятьләр дә раслый. Аллаһы Тәгалә «Әз-Зарият» сүрәсенең 7 нче аятендә кешеләргә галәмнең төзелеше турында хәбәр итә:

وَالسَّمَاءِ ذَاتِ الْحُبُكِ ﴿٧﴾

**«Юллар иясе булган күк белән ант итәмен».**

«Әз-Зарият / Таратучылар», 51:7

Әлеге аятьне тәфсир галимнәренең сүзләренә таянып, берничә мәгънәдә тәрҗемә итәргә була. Моның шулай булуы аятьтәге «Әл-Хүбүк» – الْحُبُكِ дигән сүзгә бәйле.

Мәсәлән, Мүкатил, Әл-Кәлби һәм Әд-Даххәк исемле галимнәр: «Хүбүк – ул йолдызларның хәрәкәт итү юлларын аңлата», – дип әйтәләр. Бу галимнәрнең сүзләренә таянсак, әлеге аять «Юллар иясе булган күк белән ант итәм», дигән мәгънәне аңлата.

Аллаһы Тәгалә безгә шушы аять аркылы галәмдәге галактикаларның, йолдызларның һәм планеталарның билгеле бер орбита буенча хәрәкәт итүләре хакында хәбәр итә.

VII гасырда беркем дә моның шулай икәнлеген белми иде. Тарихтан мәгълүм булганча, бу хакыйкатьне дөньяви галимнәр арасыннан иң беренче булып поляк астронавты Николай Коперник (1473-1543) ача. Ул җир шарының һәм шул исәптән, башка планеталарның да кояш тирәли әйләнүен исбатлый. Бу турыда ул «Күк җисемнәренең әйләнүе хакында» дип аталган китабында яза. 66 ел узганнан соң, моның шулай булуын итальян астрономы Галилео Галилейраслый.

Башка тәфсир галимнәре «Әз-Зарият» сүрәсенең бу аятен икенче мәгънәдә аңлаталар. Мәсәлән, Әл-Хәсән Әл-Басри: «Хүбүк дигән сүз – ул йолдызлар белән үрелгән күкне аңлата», – дип әйткән.

Гыйкримә исемле галим болай дип әйткән: «Синең кием тукучы кешене күргәнең бармы? Әгәр дә ул киемне бик оста итеп тукыса, аңа «хәбәкә», ягъни матур итеп тукыды, дип әйтәләр».

Бу очракта әлеге аять «Галактикалар белән үрелгән күк белән ант итәм», дигән мәгънәне аңлата.

Шушы аять аша Аллаһы Тәгалә галәмдәге галактикаларның берберсе арасындагы бәйләнешен сурәтли. Галәмне өйрәнүче галимнәр әйтүенчә, галәмдәге галактикалар бер-берсе белән пәрәвез оясы кебек үрелгәннәр. Алар моның шулай икәнлеген XX гасырда гына суперком-

пьютерлар ярдәмендә ачыкладылар, ә Аллаһы Тәгалә кешеләргә бу турыда 14 гасыр элек хәбәр итте.

Мөхтәрәм дин кардәшләрем! Һәр пәйгамбәр һәм илчегә пәйгамбәрлеген, илчелеген раслау өчен Аллаһы Тәгалә тарафыннан могҗиза бирелгән. Ул табигый һәм кабатланмас булган бер хәлдер. Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә бирелгән иң зур могҗиза – ул Коръәни Кәрим. Моннан да зур нигъмәт юктыр.

Әйтелә ки: Аллаһы Раббыбыз Коръәни Кәримне Җәбраил гәләйһиссәламгә иңдерде һәм ул иң бөек фәрештә булды. Коръән пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә иңдерелде һәм Пәйгамбәребез иң бөек пәйгамбәр булды. Коръәни Кәрим Рамазан аенда иңде һәм шул рәвешле, Рамазан ае иң шәрәфле ай булды. Коръән җомга көнне иңде һәм, җомга көн иң бөек көнгә әверелде. Кадер кичендә иңде – вә Кадер киче 1000 кичтән дә хәерлерәк кичә булды. Хөрмәтле мөселманнар, әгәр шушы Коръәни Кәрим күңелләребезгә кереп утырса, күңелебез нинди булыр? Җавабы билгеле.

Аллаһы Раббыбыз ошбу вәгазьләребездән разый булсын. Файдаланырга насыйп итсен. Кыямәт көнендә Коръәни Кәримнең безнең өчен шәфәгать итүен насыйп әйләсен һәм безгә каршы шаһитлык итүеннән сакласын. Күңелләребездәге барча начар сыйфатлардан арынырга насыйп әйләсен.

* * *

Фузаил бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул булына торган бер догам барлыгын белсәм, мин җитәкче өчен дога кылар идем», – дип әйткән.

Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә президентыбыз – Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып

яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядъкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең, телебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Динар Зыятдинов,*

*«Азан» радиосы редакторы*

*7 нче май вәгазе,*

*Рамазан аеның 25 нче көне, һиҗри исәп буенча 1442 ел*

# Коръәни Кәримне уку әдәпләре

Бөтен галәмне юктан бар итеп, тәрбия кылучы Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгаләгә хәмед-сәналәребез, барча мактауларыбыз булса иде. Сөекле пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә, аның хөрмәтле гаиләсенә, барлык сәхабәләренә күңелләребез түреннән чыккан сәламнәребез, салават-шәрифләребез ирешсә иде. Аллаһы Тәбарәкә вә Тәгалә ил-көннәребезгә иминлек, тынычлык, авыру-сырхауларга хәерле шифалар, имансызлыкта, тәүфыйксызлыкта йөргән бәндәләргә юлны табарга ярдәм итсә иде, аларны иманга китереп, тәүфыйк-һидаять, истикамәтләр насыйп әйләсә иде.

Мөхтәрәм дин кардәшләрем! Әссәләмү галәйкүм вә рахмәтуллаһи вә бәрәкәтүһ! Изге җомга көнебез һәркайсыбызга мөбарәк булсын. Аллаһы Тәгалә ике җомга арасында вафат булган дин кардәшләребезнең гөнаһларын ярлыкап, рухларын шатландырса иде. Аллаһы Раббыбыз изге җомга көнендә кылган догаларыбызны, игелекле гамәлләребезне кабул итеп, безне Үзенең чиксез рәхмәтенә ирештерсә иде.

Хакыйкатьтә, кешеләр арасында Коръәнне гәҗит сыман укучылар вә аның мөкатдәслеген аңлап бетермәүчеләр бар! Коръәни Кәрим Аллаһының мөкатдәс вә мөбарәк сүзләре булу сәбәпле, аны кадерләп тоту һәм хөрмәт итү тиешле. Мөселманнар өчен аннан да кадерлерәк китап юк, шуның өчен дә алар Коръәни Кәримгә генә хас булган әдәпләрне сакларга тырышалар. Бу әдәпләр ике төргә: тышкы һәм эчке (кальби) әдәпләргә бүленәләр.

**Коръәни Кәримне укыганда тышкы әдәпләр:**

1. Коръәни Кәримне укучының тәне госел-тәһарәтле, киеме гаурәтен каплаган һәм чиста булырга тиеш.

Аллаһы Раббыбыз Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

وَالسَّابِقُونَ السَّابِقُونَ ﴿١٠﴾

**«Пакьләнгәннәр генә аңа кагыла ала».**

«Әл-Вакыйга», 56:10

2. Тешләрне һәм авызны мисвәк белән пакьләү. Сүз һәм аваз чыга торган урын булганга без аны Аллаһы ризалыгы өчен чистартабыз, шул рәвешле Коръәни Кәримне олуглыйбыз.

3. Коръәни Кәримне мөмкин кадәр кыйблага юнәлеп уку.

4. Төрле шөгыльләр, эшләр комачау итәргә тиеш түгел.

5. Коръәни Кәримне уку алдыннан «Әгууҙү билләәһи минәш-шәйтаанир-раҗиим», дип башлау. Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

فَإِذَا قَرَأْتَ الْقُرْآنَ فَاسْتَعِذْ بِاللَّهِ مِنَ الشَّيْطَانِ الرَّجِيمِ ﴿٩٨﴾

**«[Расүлем!] Коръән укыган чагында ләгънәтле шәйтаннан Аллаһыга сыен».**

«Ән-Нәхл / Бал кортлары», 16:98

Ягъни «Әгууҙү билләәһи минәш-шәйтаанир-раҗиим», дип әйт.

6. «Әт-Тәүбә» сүрәсеннән кала һәр сүрә башында «Бисмилләһ»не әйтү кирәк.

7. Коръәни Кәримне тәҗвид кагыйдәләренә нигезләнеп, тыныч тавыш белән уку. Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

أَوْ زِدْ عَلَيْهِ وَرَتِّلِ الْقُرْآنَ تَرْتِيلًا ﴿٤﴾

**«Яки аңа өстә [һәм өчтән икесен гыйбадәттә үткәр]. Коръәнне тәртил белән [әкрен-әкрен, ачык итеп] укы».**

«Әл-Мүзәммил / Чорналган», 73:4

8. Коръәни Кәримне тәртибе белән уку, ягъни сүрәләрнең һәм аятьләрнең тәртибен саклап уку.

9. Укый башлаган сүрәне ахырына кадәр укып тәмамлау.

10. Коръәни Кәримгә хөрмәт йөзеннән, аның мосхафын, ягъни гарәпчәсен яткан хәлдә укымау. Ә менә яттан белгән сүрә яки аятьләрне яткан көе укуның гаебе юк.

11. Кеше мөрәҗәгатьләренә бүленмәү. Сәлам бирсәләр, сәламне кайтарып, Коръәни Кәримне укуны дәвам итү.

12. Яттан укыганчы мосхафка карап уку, чөнки Коръән аятьләренә карау – гыйбадәт (Искәрмә: намазда мосхафка карап уку ярамый).

13. Коръәни Кәримне матур тавыш белән бизәп уку, ягъни Коръән Кәримне көйләп, музыка белән укымау. Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм үзенең бер хәдисендә болай дип әйткән: «Коръәни Кәримне гарәп телендә, әдәби һәм олуглык ияләренең телендә укыгыз. Дөреслектә, миннән соң шундый кавемнәр килер, алар насараларга охшатып җырлап көйләрләр».

14. Сәҗдә аятьләре килсә, тиләвәт сәҗдәсе кылу.

15. Коръәни Кәримне укыганда еларга һәм хошугъ халәтендә булырга тырышу.

16. Коръәни Кәримне өйрәнү-укыту ниятеннән кала, каты тавыш белән укымыйча, пышылдап уку мөстәхәб.

**Коръәни Кәримне укыганда эчке (кальби) әдәпләр:**

1. Коръәни Кәримне бирелеп уку, мәгънәсенә төшенергә тырышу, фикерләп уку һәм гамәл кылырга тырышу. Раббыбыз Аллаһы Үзенең Изге Китабында болай дип әйтә:

كِتَابٌ أَنزَلْنَاهُ إِلَيْكَ مُبَارَكٌ لِّيَدَّبَّرُوا آيَاتِهِ وَلِيَتَذَكَّرَ أُولُو الْأَلْبَابِ ﴿٢٩﴾

**«[Коръәни Кәрим] Мөбарәк бер Китап ки, аны сиңа алар аның аятьләре хакында уйласыннар һәм [нәфесләренең бозык**

**теләкләреннән арынган] аек акылга ия булганнар үгетләнсен дип иңдердек».**

«Сад», 38:29

2. Коръәни Кәримне укыганда аның кеше сүзе түгел, Аллаһы Сүзе икәнлеген истә тотып уку.

3. Коръәни Кәримнең төп максатын белеп уку, ягъни бу Китап савапка ирешү һәм гыйбрәт өчен укыла.

4. «Мин инде Коръәни Кәримне шәп укыйм», – дип масаймау, тәкәбберләнмәү, бәлки киресенчә, түбәнчелек белән укып, нәфесеңне тәрбияләү.

5. Коръәни Кәримне укыган кешене тыңлаганда яисә ишеткәндә, сөйләшмәү, игътибар белән тыңлап калеб белән фикерләү. Коръәни Кәримдә Хак Тәгалә болай дип әйтә:

وَإِذَا قُرِئَ الْقُرْآنُ فَاسْتَمِعُوا لَهُ وَأَنصِتُوا لَعَلَّكُمْ تُرْحَمُونَ ﴿٢٠٤﴾

**«Коръән укылган чакта, аны тыңлагыз һәм дәшми торыгыз, – бәлки, сез [Аллаһы тарафыннан] рәхмәт ителерсез» .**

«Әл-Әгъраф / Киртәләр», 7:204

6. Коръәннән булдыра алган хәтле ятлау һәм ятлаганын онытудан саклану, чөнки Коръәни Кәримне ятлау – сөннәт гамәл, ә ятлаганыңны онытмау – вәҗиб.

7. Коръәни Кәримне укыганнан соң дога кылу.

* * *

Фузаил бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул булына торган бер догам барлыгын белсәм, мин җитәкче өчен дога кылар идем», – дип әйткән.

Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә президентыбыз – Рөстәм Нургали улының

саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядькәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең, телебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Тимергали хәзрәт Юлдашев,*

*«Саләх» мәчете имам-хатыйбы*

*13 май вәгазе,*

*Шәүвәл аеның 1 нче көне, һиҗри исәп буенча 1442 ел*

# Ураза гаете вәгазе

Әгуузү билләәһи минәш-шәйтаанир-раҗиим. Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим. Әлхәмдүлилләәһи Раббил гааләмиин әссаләәтү вәссәләәмү галәә расүлиһи Мүхәммәдин вә галәә әәлиһи вә әсхаабиһии әҗмәгыйн. Әссәләмү галәйкүм вә рахмәтуллаһи вә бәрәкәтүһ!

Барча мактау һәм олуглау Аллаһы Тәгаләгә һәм сөекле пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә чын күңелебездән салават-шәрифләребез булсын.

Әлхәмдүлилләһи, Аллаһы Тәгалә безне мөселман итеп бар итте, иман белән бүләкләде, Рамазан аен каршы алып, ураза тотарга, намазлар укырга, тәравих намазларында катнашырга, ифтарда бергә булырга насыйп итте. Аллаһы Тәгалә кылган гыйбадәтләребезне риясыз булган хәлдә кабул итсен. Аллаһының ризалыгына ирешеп, Фирдәвес исемле җәннәткә керергә насыйп булсын.

Әлхәмдүлилләһи, бүген Гает бәйрәме көне, әйе, ул үзе дә «бәйрәм» дигән сүз. Бу бәйрәм – Аллаһы Тәгалә каршында булган зур бурычны үтәп, төннәрен тәравих намазлары укып шәрәфләнгән бәндәләр өчен бигрәк тә шатлыклы зур бәйрәм, чөнки алар, Аллаһының әмеренә буйсынып, үз нәфесләрен ашау-эчүдән вә бөтен яман эшләрдән тыеп тордылар. Дөньяда булган һәр эшләребез өчен җавап бирәчәкбез, дип ураза тотып, гыйбадәтләр кылдылар. Шулай итеп, Аллаһы Тәгаләгә тагы да якынайдылар.

Ураза тоту белән без мәрхәмәтлелеккә, сабырлыкка, булганына ризалык белдерергә, мескеннәрнең хәлен белергә, ризыкның кадерен белергә өйрәнәбез.

Аллаһы Тәгалә көннәрне суытып, безгә ураза тотарга җиңеллек насыйп итте. Бу безгә карата Аллаһы Тәгаләнең рәхмәте, бәрәкәте, нигъмәте һәм бүләге. Элеккеге заманда Рамазан ае җәй көненә туры килсә дә, трактор, комбайн булмаган вакытта, әби-бабаларыбыз урак өстендә эшләп тә, уразаны калдырмадылар. Ни өчен? Ихласлыклары көчле булганы өчен.

Аллаһы Тәгалә болай дип әйтә:

يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا كُتِبَ عَلَيْكُمُ الصِّيَامُ كَمَا كُتِبَ عَلَى الَّذِينَ مِن قَبْلِكُمْ لَعَلَّكُمْ تَتَّقُونَ ﴿١٨٣﴾

**«Ий иман китерүчеләр! Сездән алда килеп киткәннәргә [фарыз булып] язылган кебек, сезгә дә [Рамазан аендагы] ураза [фарыз буларак] язылды. Бәлки, [ачлык ярдәме белән гөнаһлардан сакланып] тәкъвалык ияләреннән булырсыз!»**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:183

Аллаһы Тәгалә бу аятьтә иманлы булган бәндәләргә мөрәҗәгать итә. Кем дә кем ураза тотмас өчен аклана һәм сәбәп таба икән, димәк, аның ихласлыгы түбән, чөнки иманлы бәндәгә ураза тоту, намаз уку, изге эшләрне башкару – бәйрәм кебек.

Ураза тоту – ул күнекмә сыман. Ай буена таң атканнан алып, кояш баеганчыга кадәр хәләл ризыктан үзен тыйган кешегә харам ризыктан һәм гөнаһтан тыелу җиңел булыр.

Ураза тоткан кеше үзенә хаким булырга өйрәнә. Ул җаны ни теләсә, шуны ашап-эчеп йөрмәс. Нәфесе ни кушса, шуны эшләмәс, ягъни нәфесенең тоткыны булмас. Ирадәсе белән хәрәкәт итәр, сабыр булырга өйрәнер. Аш һәм сусыз калганда, кыенлыкларда ихтыяр көчен күрсәтер. Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Һәрнәрсәнең зәкяте бар. Гәүдәнең зәкяте – ураза. Ураза – сабырлыкның яртысы», – дигән.

Ураза кешеләрдә шәфкать һәм мәрхәмәт тойгыларын уята. Ач вә сусыз калып, ярлыларның хәлен аңларга, аларга ярдәм итәргә өйрәтә. Бүген дөньяның төрле җирләрендә бер телем икмәк кисәгенә мохтаҗ булып, ачлыктан үлүчеләр бар. Үз гомерендә ач һәм сусыз калмаган кешеләр аларның хәлләрен аңламаслар иде. Тикмәгә генә: «Ачның хәлен тук белмәс», – димиләр. Шуңа күрә исламда иң күп ярдәмләшү ае дип, Рамазан ае санала. Мөселманнар бу айда зәкят һәм садакаларын биреп, ярлыларны шатландыралар. Бу айда җәмәгать арасында якынаю һәм тынычлык арта.

Ураза кешене сабыр һәм чыдам булырга өйрәтә. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Бу ай – сабырлык ае», – дигән. Башка бер хәдисендә: «Сездән берегез уразалы булганда ямьсез сүз сөйләмәсен вә беркем белән дә хурлашмасын. Әгәр берәү сезгә бәйләнсә яисә әрләшергә теләсә: «Мин ураза тотам, яисә мин уразамын», – дисен вә аның белән талашып тормасын», – дип әйткән.

Икенче бер хәдисендә болай дип әйткән: «Фәрештәләр ураза тоткан кешенең гафу ителүе өчен, Рамазан ае буена көнен вә төнен дога кылырлар».

Рамазан аенда әхлаксызлык азая. Аракы эчү, отышлы уеннар уйнау, кеше үтерү, зина кылу кебек Аллаһының харам кылган эшләре бу айда бик аз эшләнә. Үткәрелгән тикшерүләр буенча, ислам мәмләкәтләрендә, Рамазан аенда бу начар эшләр эшләнмәгәнгә яки бик аз эшләнгәнгә күрә, мөселманнарга рәхәтлек һәм хозурлык килә.

Ураза гөнаһларыбызның кимүенә сәбәп була, кешене Аллаһы янында зур дәрәҗәләргә ирештерә. Аллаһының ризалыгын өмет итеп судан тыелып торган колына Аллаһы Тәгалә һич газап бирмәс, иншәАллаһ. Аллаһы ризалыгы өчен тотылган уразалар мәңгелек бәхетебезгә сәбәп булсын!

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Ураза тотыгыз, сау булырсыз (сәламәт яшәрсез)», – дип боерган. Унбер ай туктамыйча эшләгән эчке әгъзалар бу айда ял итә. Табибларның әйтүенчә, иң авыр вазифаны үтәгән әгъзаларның берсе – бавыр. Гомер буена туктамыйча эшләгән бавыр, әгәр Рамазан аенда ураза тотсак, һәр көн алты сәгать ял итә. Янә бу айда, еш ашап-эчмәгәнгә күрә, ашказаны вә эчәкләр дә хәл алалар. Ураза тоткан кешенең организмында бу айда зарарлы майлар кими төшә.

Ураза бары тик саулык өчен фарыз кылынган гыйбадәт кенә түгел, ә бәлки кешенең Аллаһыга якынаюы өчен, Аллаһы тарафыннан барлык милләтләргә фарыз кылынган зур бер гыйбадәт. Уразаның матди яктан да, мәгънәви яктан да бик күп файдалары бар. Ләкин без уразаны файдалары өчен генә түгел, Аллаһы кушканга күрә тотабыз. Аллаһы кешеләргә файдалы гыйбадәтләрне – фарыз, зарарлы эшләрне харам кылган.

Ураза тоту кешенең ихтыяр көчен булдыра. Кеше сабырлык һәм ихтыяр көчен булдыра алсын өчен, үзен камилләштерергә тырышырга тиеш. Бүген кеше зарлана, булганына риза түгел, авырлык килгәндә төшенкелеккә бирелә. Әлбәттә, дөнья булгач төрлесе килеп чыгарга мөмкин. Беренчедән, без монда кунакта һәм вакытлыча яшибез. Икенчедән, Аллаһы Тәгалә барыбызны да сыный. Кеше бәхетле булсын өчен, Аллаһы безгә Ислам динен бүләк итте.

Аллаһы Тәгалә болай дип әйтә:

لَا يُكَلِّفُ اللَّهُ نَفْسًا إِلَّا وُسْعَهَا... ﴿٢٨٦﴾

**«Аллаһы беркемгә дә көченнән килмәслек нәрсә йөкләми».**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:286

Пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Әгәр кеше бу Рамазан уразасыннан соң, шәүвәл аенда алты көн ураза тотса, ул кеше тулы елны ураза тоткан кебек саваплы булыр, чөнки безнең шәригатебездә бер изгелеккә ун өлеш саваптан ким савап булмас», – дип

әйткән. Хисапласак, утыз көнгә өч йөз көн ураза савабы булыр. Алты көнгә алтмыш көн ураза савабы булыр. Бу өч йөз алтмыш көн камил бер ел булыр».

Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дигән: «Кыямәт көнендә кешенең гамәлләреннән иң элек намаз турында хөкем ителер. Әгәр намаз кабул ителсә, ул кеше уңышка ирешер. Ә инде намаз кабул булмаса, ул кеше уңышсызлыкка ирешер. Фарыз намазларында җитешсезлекләр булса, Аллаһы Тәгалә фәрештәләргә: «Аның укылган нәфел (өстәмә) намазларына карагыз!» – дип әйтер. Фарыз намазларда булган кимчелекләр нәфел намазлары белән капланыр. Шулай ук башка гамәлләр (ураза, зәкят, хаҗ) белән дә хисапланырлар».

Бу хәдистән чыгып шуны әйтергә була: фарыз гамәлләрдә булган җитешсезлекләрне тулыландырыр өчен, безнең хисапта нәфел гамәлләр күп булырга тиеш. Кайбер кешеләр: «Фарызны гына кылсак, безгә җитә, нәфел гамәлләрне башкалар укысыннар», – дип әйтәләр. Әйе, фарызны үтәсәк, өстебездән вазифа төшә, ләкин фарыз тиешле дәрәҗәдә башкарылырга тиеш. Һәр гамәлне кылганнан соң, алдагы кимчелекләр өчен Аллаһы Тәгаләдән гафу сорыйбыз. Шуның өчен өстәмә нәфел гыйбадәтне үтәсәк кенә, камил сыйфатлы гамәлләргә ирешәчәкбез.

Бу дөнья сынау һәм имтихан йорты булып тора. Төрле кешеләрне Аллаһы Тәгалә төрлечә сыный.

Раббыбыз Аллаһы болай дип әйтә:

وَلَنَبْلُوَنَّكُم بِشَيْءٍ مِّنَ الْخَوْفِ وَالْجُوعِ وَنَقْصٍ مِّنَ الْأَمْوَالِ وَالْأَنفُسِ وَالثَّمَرَاتِ ۗ وَبَشِّرِ الصَّابِرِينَ ﴿١٥٥﴾

**«Без, һичшиксез, сезне бераз – курку белән, бераз – ачлык белән һәм малларыгызга, җаннарыгызга, [бакча-басуларыгызга афәтләр җибәреп] уңышларыгызга бераз зыян китерү белән**

**сыныйбыз. [Расүлем!] [Сынауларга] Сабыр итүчеләрне [җәннәт белән] сөендер!»**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:155

Бу коронавирус та безнең өчен Аллаһы Тәгаләдән бер сынау булды. Әлбәттә, иманлы кеше өчен бу дәресне үтүе җиңел, чөнки ул түбәндәгеләрне аңлый: беренчедән, бу имтихан Аллаһы Тәгаләдән, икенчедән, ул вакытлыча, өченчедән, кешедә Аллаһыга карата ихласлык арта, дүртенчедән, изге гамәлләр эшләнә, бишенчедән, бозыклыктан тыела, алтынчыдан, Аллаһыга якыная, җиденчедән, догасы кабул ителә, сигезенчедән, әҗер-савабы арттырыла, тугызынчыдан, җәннәттә дәрәҗәсе зуррак була.

Йә, Раббым, илләребезгә-көннәребезгә тынычлык-иминлек, халыклар арасында дуслык-татулык, ил башлыкларыбызга гаделлек һәм сабырлык, гаиләләребезгә бәхет-сәгадәт, балаларыбызга тәүфыйк-һидаять, диндә булмаганнарга туры юл, авыруларга шифа-сихәт насыйп итсәң иде.

Фузаил бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул булына торган бер догам барлыгын белсәм, мин җитәкче өчен дога кылар идем», – дип әйткән.

Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә президентыбыз – Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядькәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең, телебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит! Әмин!

*Камил хәзрәт Сәмигуллин,*

*Татарстан Республикасы мөфтие*

# Ураза гаете хотбәсенең гарәпчә укылышы

خطبة عيد رمضان

بِسْمِ اللهِ الرَّحْمَنِ الرَّحِيمِ

اَللّٰهُ أَكْبَرُ اَللّٰهُ أَكْبَرُ لَا إِلَهَ إِلَّا اَللّٰهُ وَاَللّٰهُ أَكْبَرُ اَللّٰهُ أَكْبَرُ وَلِلّٰهِ الْحَمْدُ ❁ سُبْحَانَ مَنْ نَوَّرَ قُلُوبَ الْعَارِفِينَ بِنُورِ الْمَعْرِفَةِ وَالْإِيمَانِ وَشَرَحَ صُدُورَ الصَّادِقِينَ بِشَرْحِ الْهِدَايَةِ وَالْعِرْفَانِ وَأَكْرَمَ عِبَادَهُ الْمُؤْمِنِينَ بِصِيَامِ شَهْرِ رَمَضَانَ ❁ اَللّٰهُ أَكْبَرُ اَللّٰهُ أَكْبَرُ لَا إِلَهَ إِلَّا اَللّٰهُ وَاَللّٰهُ أَكْبَرُ اَللّٰهُ أَكْبَرُ وَلِلّٰهِ الْحَمْدُ ❁ سُبْحَانَ مَنْ فَتَحَ عَلَى الصَّائِمِينَ أَبْوَابَ الرَّحْمَةِ وَالْغُفْرَانِ وَزَيَّنَ قُلُوبَ الْمُحِبِّينَ بِتِلَاوَةِ الْقُرْآنِ وَغَلَّقَ عَلَى الصَّائِمِينَ أَبْوَابَ النِّيرَانِ فِي شَهْرِ رَمَضَانَ ❁ وَعَدَ لِلصَّائِمِينَ دُخُولَ بَابٍ مِنْ أَبْوَابِ الْجِنَانِ كَمَا أَخْبَرَنَا نَبِيُّنَا نَبِيُّ آخِرِ الزَّمَانِ: إِنَّ لِلْجَنَّةِ بَابًا يُقَالُ لَهُ الرَّيَّانُ لاَ يَدْخُلُهُ إِلَّا الصَّائِمُونَ فِي شَهْرِ رَمَضَانَ ، شَهْرُ رَمَضَانَ الَّذِي أُنْزِلَ فِيهِ الْقُرْآنُ هُدًى لِّلنَّاسِ وَبَيِّنَاتٍ مِّنَ الْهُدَىٰ وَالْفُرْقَانِ ❁ اَللّٰهُ أَكْبَرُ اَللّٰهُ أَكْبَرُ لَا إِلَهَ إِلَّا اَللّٰهُ وَاَللّٰهُ أَكْبَرُ اَللّٰهُ أَكْبَرُ وَلِلّٰهِ الْحَمْدُ ❁ وَأَشْهَدُ أَنْ لَا إِلَهَ إِلَّا اللهُ وَحْدَهُ لاَ شَرِيكَ لَهُ ذُوالْعَفْوِ وَالْغُفْرَانِ وَأَشْهَدُ أَنَّ مُحَمَّدًا عَبْدُهُ وَرَسُولُهُ شَهَادَةً نَاطِقَةً بِالْحُجَّةِ وَالْبُرْهَانِ صَلَّى اللّٰهُ تَعَالَى عَلَيْهِ وَعَلَى آلِهِ وَأَصْحَابِهِ صَلَاةً مُوصِلَةً إِلَى دَارِ الْجِنَانِ خُصُوصًا مِنْهُمْ عَلَى أَبِي بَكْرٍ الصِّدِّيقِ وَ عُمَرَ الْفَارُوقِ وَ عُثْمَانَ ذِي النُّورَيْنِ وَ عَلِيٍّ الْمُرْتَضَى الأَئِمَّةِ رِضْوَانَ اللهِ عَلَيْهِمْ أَجْمَعِينَ ❁

أَمَّا بَعْدُ: أَيُّهَا النَّاسُ، أُوصِيكُمْ عِبَادَ اللهِ وَنَفْسِي أَوَّلاً بِتَقْوَى اللهِ ۞ أَعُوذُ بِاللهِ مِنَ الشَّيْطَانِ الرَّجِيمِ، بِسْمِ اللهِ الرَّحْمَنِ الرَّحِيمِ ۞ إِنَّ اللَّهَ مَعَ الَّذِينَ اتَّقَوا وَّالَّذِينَ هُم مُّحْسِنُونَ ۞ بَارَكَ اللهُ لَنَا وَلَكُمْ فِي الْقُرآنِ الْعَظِيمِ وَنَفَعَنَا وَإِيَّاكُمْ بِالْآيَاتِ وَالذِّكْرِ الْحَكِيمِ إِنَّهُ هُوَ الْغَفُورُ الرَّحِيمُ الْجَوَادُ الْكَرِيمُ الْعَلِيُّ الْعَظِيمُ السَّمِيعُ الدُّعَاءِ

## خطبة ثانية

إِنَّ الْحَمْدَ لِلَّهِ نَحْمَدُهُ وَنَسْتَعِينُهُ وَنَسْتَغْفِرُهُ وَنُؤْمِنُ بِهِ وَنَتَوَكَّلُ عَلَيْهِ وَنَعُوذُ بِاللَّهِ مِنْ شُرُورِ أَنْفُسِنَا وَمِنْ سَيِّئَاتِ أَعْمَالِنَا مَنْ يَهْدِهِ اللهُ فَلاَ مُضِلَّ لَهُ وَمَنْ يُضْلِلْهُ فَلاَ هَادِيَ لَهُ وَأَشْهَدُ أَنْ لاَ إِلَهَ إِلَّا اللَّهُ وَحْدَهُ لَا شَرِيكَ لَهُ وَأَشْهَدُ أَنَّ مُحَمَّدًا عَبْدُهُ وَرَسُولُهُ ۞ إِنَّ اللَّهَ وَمَلَائِكَتَهُ يُصَلُّونَ عَلَى النَّبِيِّ يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا صَلُّوا عَلَيْهِ وَسَلِّمُوا تَسْلِيمًا اَللَّهُمَّ صَلِّ وَسَلِّمْ عَلَيْهِ عَلَى جَمِيعِ الْأَنْبِيَاءِ وَالْمُرْسَلِينَ وَعَلَى مَلَائِكَتِكَ الْمُقَرَّبِينَ وَعَلَى عِبَادِكَ الصَّالِحِينَ وَعَلَى أَهْلِ طَاعَتِكَ أَجْمَعِينَ مِنْ أَهْلِ السَّمَاوَاتِ وَالْأَرَضِينَ ۞ اَللَّهُمَّ اغْفِرْ لِلْمُؤْمِنِينَ وَالْمُؤْمِنَاتِ وَالْمُسْلِمِينَ وَالْمُسْلِمَاتِ اَلْأَحْيَاءِ مِنْهُمْ وَالْأَمْوَاتِ وَارْحَمْنَا مَعَهُمْ وَاحْشُرْنَا مَعَهُمْ بِرَحْمَتِكَ يَا أَرْحَمَ الرَّاحِمِينَ ۞

# Ураза гаете хотбәсенең кириллицага транслитерациясе

## Беренче хотбә

Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахим

Аллаһу әкбәр, Аллаһу әкбәр, ләә иләәһә илләллаһу вәллааһу әкбәр, Аллаһу әкбәр, вә лилләәһил-хәмде. Сүбхәәнә мән нәввәра кулүүбәл-гаарифиинә би нуурил-мәгърифәти вәл-иимәән, вә шәрахә судүүрас-саадикыйнә би шәрхил-һидәәйәти вәл-гыйрфәән, вә әкрамә гыйбәәдәһүл-мү'миниинә би сыйәәми шәһри рамәдаан. Аллаһу әкбәрү, Аллаһу әкбәр, ләә иләәһә илләллаһу вәллааһу әкбәр, Аллаһу әкбәр, вә лилләәһил-хәмд. Сүбхәәнә мән фәтәхә галәс-саа'имиинә әбүәәбәр-рахмәти вәл-гуфраан, вә зәййәнә кулүүбәл мүхиббәйни битиләәвәтил Куръәни, вә галләка галәс-саа'имиинә әбүәәбән-нииraани фи шәһри рамәдаан. Вәгадә лис-саа'имиинә дүхуулә бәәбин мин әбүәәбил-җинәәни кәмәә әхъбәранәә нәбиййүнәә нәбиййү әәхириз-зәмәән: иннә лил-җәннәти бәәбән йүкаалү ләһүр-раййәән. Ләә йәдхулүүһү илләс-саа'имүүнә фии шәһри рамәдаан. Шәһрү рамәдаанәлләҙии үнзилә фииһил-Куръәәнү һүдәл-линнәәси вә бәййинәәтин минәл һүдәә вәл-фүркаан, Аллаһу әкбәрү, Аллаһу әкбәр, ләә иләәһә илләллаһу вәллааһу әкбәр, Аллаһу әкбәр, вә лилләәһил-хәмд. Вә әшһәдү әлләә иләәһә илләллаһу вәхдәһуу ләә шәриикә ләһуу ҙүл-гафьүи вәл-гуфраан, вә әшһәдү әннә Мүхәммәдән габдүһуу вә расүүлүһуу. Шәһәәдәтән нәәтыйкатән билхүҗҗәти вәл бүрһәәни. Салләллааһу Тәгаалә галәйһи вә галәә әәлиһи вә әсъхәәбиһи саләәтән-мүүсыйләтән иләә дәәрил-җинәән. Хусуусан минһүм галәә Әби Бәкринис-Сыйддикый вә Гумәрал-Фәәрукый вә Гусмәәнәз-ҙиннүрайни вә Галийинил-Мүртәдал ә-иммәти, ридъвәәналлааһи галәйһим әҗмәгыийнә.

Әммә бәгъде: әййүһәннәәс, үсыйкүм гыйбәәдәллааһи вә нәфсии әүвәлән-битәкъүәллааһ. Әгууҙу билләәһи минәш шәйтаанир-раҗиим, бисмилләәһир-рахмәәнир-рахим. Иннәллааһә мәгалләҙиинәт-тәкау

вәлләẓиинә һүм мүхсинүүн. Бәәракәллааһү ләнәә вә ләкүм фил-куръәәнил-газыйим, вә нәфәганәә вә иййәәкүм бил-әәйәәти үәẓẓикрил-хәкиим, иннәһуу һүәл-гафуурур-рахиимүл-җәүәәдүл-кәриимүл-галиййүл-газыйимү сәмиигуд-дүгаа'.

## Икенче хотбә

Иннәл-хәмдә лилләәһи нәхмәдүһуу вә нәстәгыйнүһу вә нәстәгъфируһу вә ну'минү биһии вә нәтәүәккәлү галәйһи вә нәгуузү билләәһи мин шүруури әнфүсинәә вә мин сәййиәәти әгъмәәлинәә мән йәһдииһилләәһү фәләә мүдыйллә ләһүү вә мән йүдълилһү фәләә һәәдиә ләһ. Вә әшһәдү ән ләә иләәһә илләллаһу вәхдәһуу ләә шәриикә ләһ, вә әшһәдү әннә Мүхәммәдән габдүһуу вә расүүлүһ. Иннәллааһә вә мәләә-икәтүһү йүсаллүүнә галәннәбиййи. Йәә әййүһәл-ләẓиинә әәмәнүү саллү галәйһи вә сәллимүү тәслиимәә. Аллаһүммә салли вә сәллим галәйһи вә галәә җәмигыйль-әнбийәә'и вәл-мүрсәлиин, вә галәә мәләә'икәтикәл-мүкаррабиин. Вә галәә гыйбәәдикәс-саалихыйн, вә галәә әһли таагатикә әҗмәгыйн, мин әһлис-сәмәүәәти үәл-арадыйн. Аллаһуммә-гъфир лилмү'миниинә вәл-мү'минәәт, вәл-мүслимиинә, вәл-мүслимәәт, әл-әхъйәәи минһүм вәл-әмъүәәт, вәрхәмнәә мәгаһүм. Үәхшүрнәә мәгаһүм бирахмәтикә йәә әрхәәмәр-раахимиин.

# Ураза гаете хотбәсенең татарчага тәрҗемәсе

## Беренче хотбә

Мәрхәмәтле, Шәфкатьле Аллаһы Тәгалә исеме белән.

Аллаһы бөек! Аллаһы бөек! Аллаһыдан башка илаһ юк. Аллаһы бөек! Аллаһы бөек! Аллаһыга гына мактау. Аллаһы Тәгаләгә якынаючыларның (гарифләрнең) күңелләрен (калебләрен) мәгъфирәт (ярлыкау) һәм иман нуры белән нурландырган, тугрыларның (садыйкларның) күңелләрен һидаять һәм белем белән ачкан, мөэмин колларына Рамазан ае уразасын бүләк иткән Зат барча кимчелекләрдән дә пакьтер. Аллаһы бөек! Аллаһы бөек! Аллаһыдан башка илаһ юк. Аллаһы бөек! Аллаһы бөек! Барча мактаулар Аллаһыга булсын. Рамазан аенда ураза тотучыларга рәхмәт һәм мәгъфирәт (гөнаһларны гафу итү) ишекләрен ачкан һәм ут ишекләрен бикләгән Зат барча кимчелекләрдән дә пакьтер. Ул (Аллаһы Тәгалә) ураза тотучыларга җәннәт ишекләренең берсе аша керүне вәгъдә иткәндер. Бу турыда безгә Пәйгамбәребез, ахырзаман Пәйгамбәре хәбәр иткән: «Чынбарлыкта, җәннәтнең бер ишеге бардыр, аңа «Раййән» диелә. Ул ишектән Рамазан аенда ураза тотучылардан башка беркем дә кермәс». Аллаһы Тәгалә Коръәндә болай дип әйтә: «Рамазан ае кешеләргә туры юл күрсәтә, ялганнан хакыйкатьне аера торган дәлилләр белән Коръән иңдерелә башлаган айдыр». Аллаһы бөек! Аллаһы бөек! Аллаһыдан башка илаһ юк. Аллаһы бөек! Аллаһы бөек! Барча мактаулар Аллаһыга булсын. Аллаһыдан башка илаһ юк, Ул берәү генә, Аның тиңдәше юк, Ул гафу Итүче һәм мәгъфирәт Иясе (гөнаһларны каплаучы) икәнлегенә гуаһлык бирәм. Шулай ук, Мөхәммәд – Аның колы һәм расүле икәнлегенә гуаһлык бирәм. Аңа, аның гаиләсенә, сәхабәләренә Аллаһы Тәгаләдән булган җәннәт йортларына илтә торган салават ирешсен. Әй кешеләр! Аллаһы Тәгаләнең коллары, сезгә һәм үземә дә тәкъвалы булырга васыять итәм.

Таш белән атылган шәйтаннан Аллаһы Тәгаләгә сыгынам. Рәхимле, Шәфкатьле Аллаһы исеме белән. Аллаһы Тәгалә Коръәндә болай дип әйтә: «Чынбарлыкта, Аллаһы Тәгалә тәкъвалылар һәм игелек кылучылар белән бергә». Аллаһы Тәгалә безгә һәм сезгә бөек Коръән аша бәрәкәт бирсен. Барыбызга да аятьләр һәм хикмәтле зикер аша файда китерсен. Чынбарлыкта, Ул (Аллаһы Тәгалә) гафу Итүче, Рәхимле, юмартлык Иясе, олуглык Иясе, бөек Зат һәм догаларны Ишетүче, кабул Итүче.

## Икенче хотбә

Чынбарлыкта, барча мактау Аллаһы Тәгаләгә, без Аны мактыйбыз, Аннан ярдәм сорыйбыз, Аннан гөнаһларыбызны гафу итүен сорыйбыз, Аңа иман китерәбез, Аңа таянабыз. Аллаһы Тәгаләгә үзебезнең начарлыкларыбыздан, гамәлләребезнең бозыклыкларыннан сыгынабыз. Кемгә Аллаһы Тәгалә һидаять бирсә – аны адаштыручы булмас, ә кемне адаштырса – аны туры юлга күндерүче булмас. Аллаһы Тәгаләдән башка илаһ юк, Ул берәү генә, Аның тиңдәше юк икәнлегенә гуаһлык бирәм. Шулай ук, Мөхәммәд – Аның колы һәм хак расүле икәнлегенә гуаһлык бирәм. Аллаһым, бөтен пәйгамбәрләргә, илчеләргә, Үзеңә якынайтылган фәрештәләреңә, Үзеңнең изгелек кылучы колларыңа һәм Сиңа итагать итүче әһелләрнең һәммәсенә – күк әһелләреннән һәм җир әһелләреннән булганнарының барчасына салават һәм сәлам ирештер. Аллаһым, мөэминнәрне вә мөэминәләрне, мөселманнарны вә мөслимәләрне, алар арасыннан исән вә вафат булганнарын мәгъфирәтең белән гафу ит. Алар белән берлектә безгә рәхимле бул һәм безне Үз рәхмәтең илә алар белән бергә булырга насыйп ит. Йә рәхимлеләрнең иң Рәхимлесе.

*14 нче май вәгазе,*

*Шәүвәл аенның 2 нче көне, һиҗри исәп буенча 1442 ел*

# Рамазаннан соң мөселманның халәте

Галәмнәрнең Раббысы булган Мәрхәмәтле һәм Рәхимле Аллаһы Тәгаләгә хәмедләребезне, олуглауларыбызны һәм шөкераналарыбызны җиткерәбез. Аллаһы Тәгаләнең Расүле, хаклыкны җиткерүче, Раббыбызның мостафасы Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә салават, сәламнәр әйтәбез.

Мөэмин-мөселман Рамазан аен ничек каршыласа, ягъни ураза тотса (намазларын мәчеттә укыса, тәравих намазларында катнашса, ифтар мәҗлесендә булса), шулай ук башка айларны да гамәлләр белән үткәрергә тиеш. Җомга көне нинди бәйрәм көне булса, башка көннәрне дә бәйрәм кебек уздыру зарур. Кадер кичәсе нинди мәртәбәле булган шикелле, башка кичәләр дә мәртәбәле һәм гыйбадәт белән бизәлергә тиеш.

Рамазан аенда гына тырыша-тырыша гамәлләр кылып, ә башка айларда ял итәргә дә ярый, дигән уй дөрес түгел, чөнки Рамазан ае ул ел буена гамәлләр кылу өчен этәргеч булып тора. Мисал итеп очкычны карыйк. Очкыч һавага очып китәр өчен, җирдә тизлеген ала. Һәм тизлеген арттырып югарыга, һавага очып китә. Шул рәвешле Рамазан аеның бәрәкәте дә ел буена таралырга тиеш. Бер гамәлдән икенчегә күчү, беренче гамәлнең кабул булуына ишарә ясый.

Әлбәттә, Рамазан аенда кешеләрнең ихласлыклары арта, чөнки бу айда шәйтаннар богауланалар. Ләкин, кызганычка, Рамазан ае бетү белән, мөселманнар ел буена «ялга» чыгалар. Моны ничек төзәтеп була?

Моның өчен Рамазан аенда һәр көнне һәм һәр төнне, гомумән әйткәндә, һәр мизгелне без тиешле рәвештә, файдалы итеп үткәрергә тиешлебез.

Пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән: «Кыямәт көнендә мөселманнар һәм мөселман булмаганнар да үкенечтә булырлар. Мөселман булмаганнар: «Нишләп без Ислам динен кабул итеп, мөселман булмадык», – дип, ә мөселманнар: «Нишләп без динне яхшылыбрак тотмадык?» – дип әйтәчәкләр».

Кешеләр дөньялык өчен ничек итеп тырышалар? Һәр эшне тиешле итеп, җитди рәвештә, җиренә җиткереп кылалар. Шулай ук һәр юнәлештә үсеш бара. Кешеләр үзләренә килгәндә, яхшы итеп эшлиләр; кибеттән әйбер алганда да сыйфатына карап сайлыйлар. Аллаһы Тәгалә дә безнең гамәлләрнең сыйфатына карый. Рамазан аеның уразасы, биш вакыт намаз, зәкят чыгару, хаҗ кылу һ.б. гамәлләрнең төп максаты – бездә тәкъвалык (Аллаһы Тәгаләдән курку) сыйфатын барлыкка китерү.

Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтте:

يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا كُتِبَ عَلَيْكُمُ الصِّيَامُ كَمَا كُتِبَ عَلَى الَّذِينَ مِن قَبْلِكُمْ لَعَلَّكُمْ تَتَّقُونَ ﴿١٨٣﴾

**«Ий иман китерүчеләр! Сездән алда килеп киткәннәргә [фарыз булып] язылган кебек, сезгә дә [Рамазан аендагы] ураза [фарыз буларак] язылды. Бәлки, [ачлык ярдәме белән гөнаһлардан сакланып] тәкъвалык ияләреннән булырсыз!»**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:183

اتْلُ مَا أُوحِيَ إِلَيْكَ مِنَ الْكِتَابِ وَأَقِمِ الصَّلَاةَ ۖ إِنَّ الصَّلَاةَ تَنْهَىٰ عَنِ الْفَحْشَاءِ وَالْمُنكَرِ ۗ وَلَذِكْرُ اللَّهِ أَكْبَرُ ۗ وَاللَّهُ يَعْلَمُ مَا تَصْنَعُونَ ﴿٤٥﴾

**«[Расүлем!] Сиңа вәхи ителгән Китапны [Аллаһы Тәгаләгә рухи яктан якынаю, сүзләрен ятлау һәм мәгънәләрен бик яхшы аңлау өчен] укы һәм [фарыз] намазны укы, чөнки [тышындагы һәм эчендәге бөтен шарт һәм әдәпләренә туры китереп, камил дәрәҗәдә укылган] намаз [зина кебек] әшәкелекләрдән дә, [шәригатьтә дә, акыл белән дә] гаеп саналганнардан да саклый. Аллаһыны зикер итү [өчен кабул ителгән һәм бөтене белән зикердән гыйбарәт булган намаз] исә [калган барлык гыйбадәтләрдән дә] өстенрәк. Аллаһы сезнең ни кылганнарыгызны белә».**

«Әл-Ганкәбут / Үрмәкүч», 29:45

لَن يَنَالَ اللَّهَ لُحُومُهَا وَلَا دِمَاؤُهَا وَلَٰكِن يَنَالُهُ التَّقْوَىٰ مِنكُمْ ۚ... ﴿٣٧﴾

**«Аларның итләре дә, каннары да Аллаһыга ирешәчәк түгел. Аңа сездән бары тәкъвалыгыгыз гына ирешә».**

«Әл-Хаҗ», 22:37

Бу аятьләрдә нәрсә күрә алабыз? Раббыбыз Аллаһы бездә тәкъвалык сыйфаты булуын тели, чөнки тәкъвалык ул барча изге гамәлләрнең тамыры булып тора. Тәкъва кеше иң көчле кеше булып санала.

Мисалга уразаны китерик. Аның хикмәте нәрсәдән гыйбарәт? Ураза тоту ул күнекмә кебек: ай буена таң атканнан алып, кояш баеганчыга кадәр хәләл ризыктан үзен тыйган кешегә харам ризыктан һәм гөнаһтан тыелу җиңел булыр. Ураза кешедә ихтыяр көчен булдыра. Хәзерге вакытта кешедә сабырлык һәм ихтыяр көче бик түбән дәрәҗәдә.

Ихтыяр көченә бер мисал китерәсем килә. Хайваннарның патшасы булган арыслан янына эт килгән дә: «Әй патша! Миңа эт исемем бер дә ошамый, башка исемне аласым килә», – дип әйткән. Арыслан бераз уйлап торгач: «Ярар, алырсың, ләкин бер шарт белән. Ит белән тулган кисмәкне

алдыңа куям һәм син ул итне кичкә кадәр ашамаска тиешсең», – дип әйткән. Эт сөенеп ризалашкан. Бер сәгать үтә, ике, өч, инде сабырлыгы калмагач, эт түзми: «Ярар, эт исеме дә яхшы әле», – дип тәлинкәдәге итне ашаган.

Бүген күп кеше зарлана, булганына ризалык белдерми, авырлык килгәндә төшенкелеккә бирелә. Әлбәттә, дөньяда төрлесе килеп чыгарга мөмкин. Беренчедән, без бу дөньяда кунак кына. Икенчедән, беркем дә безгә җиңел булыр дип әйтмәде. Өченчедән, һәрнәсәнең вакыты бар. Дүртенчедән, һичшиксез, авырлыктан соң җиңеллек киләчәк. Бишенчедән, Аллаһы Тәгалә барыбызны да сыный. Бәхетле булуыбыз өчен, Раббыбыз безгә Ислам динен бүләк итте.

Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Дөреслектә, Аллаһы Тәгалә болай дип әйтте: «Әй адәм баласы, Миңа гыйбадәт кылыр өчен вакытны тап. Мин синең йөрәгеңне бай кылырмын һәм фәкыйрьлектән азат итәрмен. Әгәр Миңа гыйбадәт кылу өчен вакыт тапмасаң, сиңа мәшәкатьләр бирермен һәм сине фәкыйрьлектән азат итмәм», – дип әйткән.

Күп кеше динне лаеклы ялга чыккач яки картайгач кына кирәк, дип уйлый. Шуның өчен дин тоту өчен вакыт юк, дип әйтә. Әмма дин – ул тормыш рәвеше һәм мәгънәсе. Аллаһы Тәгалә безгә динне авырлык килсен өчен түгел, ә киресенчә, яшәвебез җиңел булсын өчен бирде.

ا يُكَلِّفُ اللَّهُ نَفْسًا إِلَّا وُسْعَهَا...﴿٢٨٦﴾

**«Аллаһы беркемгә дә көченнән килмәслек нәрсә йөкләми».**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:186

Аллаһының Расүле салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән: «Дөреслектә, Ислам динен тотуы бик җиңел».

Әлбәттә, һәрнәрсәгә тырышлык куярга кирәк. Әби-бабаларыбыз: «Тырышкан табар, ташка кадак кагар», – дип юкка гына әйтмәгәннәр.

Шуның өчен Рамазан аенда бар көчебезне куеп тырышсак, калган айларда да изге гамәлләрне кылырга безгә җиңел булыр, иншәАллаһ.

* * *

Фузаил бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул булына торган бер догам барлыгын белсәм, мин җитәкче өчен дога кылар идем», – дип әйткән.

Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә президентыбыз – Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядькәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең, телебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Ибраһим хәзрәт Шаһимәрдәнов,*

*Питрәч районы, Көек авылы мәчете имам-хатыйбы,*

*ТҖ МДНнең Дәгъват бүлеге белгече*

*21 нче май вәгазе,*

*Шәүвәл аеның 9 нчы көне, һиҗри исәп буенча 1442 ел*

# Динем – Ислам

Барлык галәмнәрнең Раббысы булган, безне Үзенең төрле нигъмәтләре белән нигъмәтләгән Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгаләгә хәмед һәм сәналәр, барча мактауларыбыз, олуглауларыбыз булса иде. Аллаһы Тәбарәкә вә Тәгаләнең Хәбибе һәм Хак расүле, галәмнәргә рәхмәт булarak җибәрелгән сөекле пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләм хәзрәтләренә, аның хөрмәтле гаиләсенә, барлык сәхабәләренә сәламнәребез һәм салаватларыбыз булса иде.

Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

وَمِنْ آيَاتِهِ خَلْقُ السَّمَاوَاتِ وَالْأَرْضِ وَاخْتِلَافُ أَلْسِنَتِكُمْ وَأَلْوَانِكُمْ ۚ إِنَّ فِي ذَٰلِكَ لَآيَاتٍ لِّلْعَالِمِينَ ﴿٢٢﴾

**«Күкләрне һәм җирне яратуы да, телләрегезнең һәм төсләрегезнең төрлелеге дә – Аның билгеләреннән. Һичшиксез, монда [Аллаһы Тәгаләнең бөек сыйфатларын яхшы] белгәннәр өчен билгеләр бар».**

«Әр-Рум / Румлылар», 30:22

Дөньяда күпме милләтләр яши. Алар тән төсләре белән аерылалар һәм төрле телләрдә сөйләшәләр. Бу – Аллаһының хикмәте. Әгәр кешеләрнең тән төсе бер булып, бер телдә генә аралашкан булсалар, аның кызыклыгы булмас иде. Моны без матур бер бакча итеп күз алдына китерә алабыз. Шушы бакчада төрле җиләк-җимешләр үсә. Алар төрле төстә, һәм һәр җиләк-җимешнең аерым тәме бар. Әмма дөньяда

бер төрле генә җиләк-җимеш һәм аның тәме дә бер генә булса, аның да кызыклыгы калмас иде.

Һәр халыкның үз тарихы бар. Безнең әби-бабаларыбызда аеруча шундый сыйфатларга тап буласың: тырыш, уңган, эш сөючән, чисталыкны яратучы, хикмәтле, акыллы, җаваплы, зирәкле, йомшак, кунакчыл, батыр. Шушы сыйфатларга ия булганга күрә, безнең әби-бабаларыбызга Ислам динен кабул итүе дә җиңел булды. Алар акылга таянып, үз теләкләре белән динне кабул иттеләр.

Һәр кеше үзенең Ватанын һәм милләтен якын күрә, чөнки ул анда үсә һәм тәрбияләнә. Аллаһы Тәгаләнең Расүле, сөекле пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм үзенең бер хәдисендә болай дип әйткән: «Ватанны сөю – иманнан». Габдулла Тукайның шундый мәгънәле шигъри юллары бар:

*«Татар бәхте өчен мин җан атармын,*
*Татар бит мин, үзем дә чын татармын».*

Үз кадерен һәм кыйммәтен белмәгән кеше бүтәннәр тарафыннан хөрмәткә ирешә алмый. Шуның өчен без үз тарихыбызны белергә тиешбез; тарихны белү – ул элекке халыкның хатасын кабатламаска ярдәм итә. Тарихыбызга күз салсак, күп галимнәрнең, имамнарның, сәүдәгәрләрнең, байларның һәм зыялы кешеләрнең халыкка, милләткә, шулай ук дөньяга зур файда китерүләрен күрәбез. Алар мәдрәсәләр ачып, халыкка дин гыйлеме белән бергә дөньяви фәнне дә өйрәттеләр. Төрле илләрдә мәчет-мәдрәсләр ачтылар, мосафирлар өчен кунакханәләр төзеделәр. Аллаһы Тәгаләнең китабы Коръәни Кәрим 1803 елда Казанда китап рәвешендә бастырылды.

Татар сүзлегенә карасак, гарәп теленнән күп сүзләр кегәнен күрербез. Мәсәлән: каләм, дәфтәр, китап, мәктәп, галим, гыйлем, мәгариф, гасыр, заман, вакыт, сәгать, Ватан, җөмһүрият, рәис, гаскәр, мәхәббәт, саф, хәрәкәт, бәрәкәт, сәлам, нур, сандык, сабырлык һ.б. Шулай ук татар

хәрефләре арасында, гарәпчә яңгырашлы хәрефләр дә очрый. Бу мисалны без «Аллаһы» сүзендә күрәбез. Соңгы «һә» хәрефе моңа дәлил булып тора. Тагын шуны өстисе килә: тарихта әби-бабаларыбыздан татар телендә гарәп хәрефләре белән язылган язмалар да сакланган. Шулар арасында Шиһабетдин Мәрҗани, Каюм Насыйри, Ризаэтдин Фәхретдин, Галимҗан Баруди, Муса Бигиев, Сөнгатулла Бикбулат, Габдерәхим Утыз Имәни Әл-Болгари китаплары да бар.

Татар халкы тарафыннан Казанабызда – 75, ә Татарстан Җөмһүрияте буенча 1530 мәчет барлыкка килде. Тагын Казаныбызда «Госмания» урта белем бирү мәктәбе, «Ислам динен кабул итүгә 1000 ел исемендәге» мәдрәсә һәм «Мөхәммәдия» мәдрәсәләре, Рәсәй ислам Университеты, Болгар Ислам Академиясе һәм Татарстан буенча тагын күп мәдрәсәләр бар. Ләкин, кызганычка, халык соңгы арада бик каты кырысланды. Үзара көнләшү, бер-берсен күрә алмау, үз мәнфәгатьләрен генә алга куюһәм башка начар сыйфатлары барлыкка килде. Әлбәттә, үзеннән-үзе бернәрсә дә барлыкка килә алмый һәм үзгәрми. Шулай ук безнең өчен аны бер кем дә башкармас. Әгәр без бергә һәм бердәм булып, дин өчен тырышлыгыбызны куйсак, Аллаһы Тәгалә Үзенең рәхмәтен, ярдәмен, бәрәкәтен насыйп итәр.

Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

وَاعْتَصِمُوا بِحَبْلِ اللَّهِ جَمِيعًا وَلَا تَفَرَّقُوا ۚ وَاذْكُرُوا نِعْمَتَ اللَّهِ عَلَيْكُمْ إِذْ كُنتُمْ أَعْدَاءً فَأَلَّفَ بَيْنَ قُلُوبِكُمْ فَأَصْبَحْتُم بِنِعْمَتِهِ إِخْوَانًا... ﴿١٠٣﴾

**«Барыгыз бергә Аллаһының арканына [Китабына һәм диненә] ныклап ябышыгыз һәм [әһле китап кебек ихтилафка төшеп хакыйкатьтән һәм бер-берләрегездән] аерылмагыз. Аллаһының сезгә биргән [игелек һәм] нигъмәтен истә тотыгыз. Сез [җәһилият чорында бик озак еллар буена бер-берсе белән сугышкан] дошманнар булган чакта, Ул [сезне Ислам**

**дине белән шәрәфләндереп] күңелләрегез арасында [татулык һәм бер-берегезгә карата җылылык яратып] өлфәт бердәмлек барлыкка китерде, һәм сез Аның [бу] нигъмәте белән [бер-берләрен бик якын күргән] кардәшләр булдыгыз».**

«Әлү Гыймран / Гыймран гаиләсе», 3:103

Бу дөньяда безнең яшәвебез бик кыска, ләкин максатыбыз олы булып тора. Ул да булса Ислам дине буенча яшәү. Ислам сүзе «сәләм» тамырыннан килә, ягъни иминлек, тынычлык, сәламәтлекне аңлата. Хәзерге вакытта кешеләр дөньясында иминлек юк, бәндәләрнең күңелләрендә тынычлык беткән һәм шифаханәләр авырулар белән тулган. Халык дингә керү белән берьюлы 3 нигъмәткә ия булачак – ул да булса иминлеккә, тынычлыкка һәм сәламәтлеккә.

Шуңа күрә безнең тормышыбызда Ислам дине булсын өчен:

1. Ислам динен өйрәнергә; 2. Ислам дине буенча яшәргә;

3. Ислам динен сакларга; 4. Ислам динен башкаларга җиткерергә кирәк.

* * *

Фузаил бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул булына торган бер догам барлыгын белсәм, мин җитәкче өчен дога кылар идем», – дип әйткән.

Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә президентыбыз – Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядъкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең, телебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Ибраһим хәзрәт Шаһимәрдәнов,*

*Питрәч районы, Көек авылы мәчете имам-хатыйбы,*

*ТҖ МДНнең Дәгъват бүлеге белгече*

*28 нче май вәгазе,*

*Шәүвәл аеның 16 нчы көне, һиҗри исәп буенча 1442 ел*

# Балаларны яклау – аларга яхшы тәрбия бирү

Барлык галәмнәрнең Раббысы булган, безне Үзенең төрле нигъмәтләре белән нигъмәтләгән Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгаләгә хәмед һәм сәналәр, барча мактауларыбыз, олуглауларыбыз булса иде. Аллаһы Тәбарәкә вә Тәгаләнең Хәбибе һәм Хак расүле, галәмнәргә рәхмәт буларак җибәрелгән сөекле пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләм хәзрәтләренә, аның хөрмәтле гаиләсенә, барлык сәхабәләренә сәламнәребез һәм салаватларыбыз ирешсә иде.

Хөрмәтле җәмәгать, дин кардәшләрем, Аллаһы Тәгалә адәм баласын хөрмәтле һәм шәрәфле итеп яраткан. Адәм баласының дәрәҗәсе акыл һәм иман белән бәйле булса, аларның гамәли ягы кешенең әхлагы, тәрбиясе. Динебездә «тәрбияле булу» дигәндә – ул дөнья һәм Ахирәт тормышында бәхеткә, уңышка алып бара торган яшәү рәвеше күзаллана. Чыннан да, тәрбияле кеше үзенә дә, чит кешегә дә, җәмгыятькә дә файда, иминлек, тынычлык алып килә. Ә тәрбиясезлек, киресенчә, кешенең үзенә авырлык китерә һәм башкаларга да бәла була.

Аллаһы Тәгалә «Әт-Тәхрим» сүрәсендә болай дип әйтә:

يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا قُوا أَنفُسَكُمْ وَأَهْلِيكُمْ نَارًا

**«Ий иман китерүчеләр! [Әмерләрне тотып, тыюлардан тыелып] Үз-үзләрегезне һәм гаиләләрегезне уттан саклагыз».**

«Әт-Тәхрим / Тыю», 66:6

Ягъни, үзегез шәригать хөкемнәрен дөрес үтәп, җәмәгатьләрегезгә дә шәригать хөкемнәрен дөрес итеп өйрәтегез. Һәм бу Аллаһы Тәгалә боерган фарыз эшләрдән булып тора.

Раббыбыз «Ән-Нәхл» сүрәсендә болай дип әйтә:

وَلَتُسْـَٔلُنَّ عَمَّا كُنتُمْ تَعْمَلُونَ ﴿٩٣﴾

**«Кылган нәрсәләрегез турында, һичшиксез, [Кыямәт көнендә] соралачаксыз».**

«Ән-Нәхл / Бал кортлары», 16:93

Гаилә кору, балалар үстерү, аларны тәрбияләү, яхшылыкка яки яманлыкка гадәтләнү – бәндәнең кылган гамәлләреннән санала һәм алар турында Кыямәт көнендә соралачак.

Әлбәттә, балаларны яклау безнең аларны төрле бәладән саклап, җилкәбез артында гына тоту түгелдер. Асыл яклау дөрес тәрбия һәм дөньяда дөрес яшәү гыйлеме бирүдәдер, чөнки без гел алар янында булмабыз, ә биргән гыйлемнәребез һәм тәрбия һәрчак янәшәләрендә булыр. Тәрбия ана карынынннан алып, гомер буе бара дисәк тә, төп тәрбия бала балигълык яшенә җиткәнче барадыр.

Тәрбия яшьләрен карап үтик: балага карата искә алынган иң беренче яшь аралыгы – 2 яшь.

Аллаһы Тәгалә «Әл-Бәкара» сүрәсендә болай дип әйтә:

وَالْوَالِدَاتُ يُرْضِعْنَ أَوْلَادَهُنَّ حَوْلَيْنِ كَامِلَيْنِ ۖ

**«[Бала] Тудырган хатыннар балаларын тулы ике ел имезергә тиеш...»**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:233

Бу аятьтә Аллаһы Тәгалә аналарга сабый балаларын имезүне боера. Бүгенге көндә, кызганыч, күп аналар мөмкинлекләре була торып та,

сабыйларын күкрәк сөтеннән мәхрүм итәләр. Әлбәттә, җитди сәбәпләре булганнарга бу кагылмас. Сабый өчен иң зур бүләкнең берсе – ана сөтедер. Бала шуның белән ныгыр, кирәкле матдәләр алыр. Ярату, яклау хисен дә бала ана сөте аша аладыр.

Икенче мөһим яшь 4 яшь буладыр. Бу яшьтән балага оят хисе салынадыр. Әлеге яшьтән гаурәт мәсьәләсен төшендерү кирәктер. Ягъни гаурәт өлешләрен күрсәтмәү, башка кешенекенә карамау турында аңлату мөһим. Әти-әни баланы юындырганда (хәтта ир баланы ата юындырса да һәм кыз баланы әнисе юындырса да) әти-әнинең эчке кием киеп юынуы әдәп һәм оятка беренче дәрес булып торадыр.

Игътибарга лаек булган өченче яшь – 6 яшь. Элек-электән халкыбызда «Алтыдагысы – алтмышта» дигән әйтем булган. Тик сүз 6 яшьтә ятлаган шигырьләр турында бармый. Асылда, өйдә күргән тәрбия турында барадыр. Ягъни өендә булган әдәп-әхлакны үз эченә аладыр, чөнки кечкенә чактаа өйрәнгән кагыйдәләр гомер буена истә кала.

Дүртенче аралык: 7 яшьтән алып 10 яшькә кадәрдер.

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән: «Балаларыгызга җиде яшь тулгач, яныгызга намаз укырга бастырыгыз».

7 яшь тулу белән балаларыбызга 4 мөһим юнәлешне өйрәтү кирәктер. Алар:

1. Рухи мәсьәләләр (иман, намаз, ураза, зәкят, хаҗ, Аллаһыны зикер итү, хәләл-харам кебек мәсьәләләр).

2. Сәламәтлекне, тәнебезне кайгырту.

3. Гыйлем алу. Дөньяви гыйлем нигезләрен алудыр.

4. Финанс мәсьәләләре. Акча кайдан килүен аңлату. Хезмәткә кызыксыну уяту.

Шушы 4 юнәлеш баланың алдагы тормышында нигез булып торыр. Әлбәттә, 7 яшьтән бөтен нәрсәнең асылына төшенеп булмас, ләкин азазлап башлау кирәктер.

Болар хакында яшьтән аңлатылмаганга күрә, бик күп аянычлы хәлләр булуы мөмкин. Рухи дөньясы тулы булмаган кеше ни өчен туюын белмәс. Сәламәтлеген кайгыртмаганы чиргә сабышыр. Гыйлеме булмаганының тормышы кыенлык эчендә булыр. Матди финанс ягын дөрес тотмаганының әҗәттән башы чыкмас. Шуның аркасында, тормышын үзбелдеге белән яклар. Әлбәттә, без – әти-әниләр дә якларбыз, ләкин без вафат булгач та, балаларның үзләренең нигезле нык терәге, яклавы булырга тиеш.

Хәдиснең дәвамында 5 нче аралык турында искә алына: «Ә ун яшьләре тулгач, намаз укудан баш тартсалар, җиңелчә сугыгыз», – дип әйтелгән. Димәк, 10 яшьлек балага карата катгыйлык күрсәтү тиешледер. Сугу дигәндә кыйнау түгел, бәлки орышу тиешледер. Сугылган, кыйналган баланың читләшүе, нәфрәте уянуы бар. Шуңа күрә сак булу кирәк. Үзебез җиткерә алмаган мәлдә, хикмәт иясенә тәрбиягә бирү кирәктер.

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Динебездә көчләү юк», – дигән. Көчләп укытылган шәкелдә баланың бездән, динебездән читләшүе бик ихтимал. Әлбәттә, кайчанга хәтле дәвам итәр икән бу катгыйлык дигәндә, ата-ана гомер буе баласына сугып утыра алмас, диярбез. 18-20 яшендә булган үсмер сuктырып тормаска да мөмкин. Аллаһы сакласын, үз ата-анасына да кул күтәрүе бар. Шуңа да туктату балигъ булгач кирәктер, чөнки инде тәрбиянең бездән торганы китә бара. Күбрәк дусларга, якын тирәгә иярүе өстенлек ала. Халкыбызда электән әйтелгән хикмәт бар: «7 яшенә кадәр бала белән бала була бел, 7 дән алып, балигълык арасында ата була бел. Балигълыктан соң дус була бел», – диелгән.

Киләсе мөһим аралык: балигълыктан алып, 18 яше тулганчыдыр. Бу аралык үсмерлек яше (переходной возраст) аралыгыдыр. Ул күпчелек ата-ана өчен авыр чор булып тора. Бу аралыкта баланың тизрәк үсеп, бәйсез бер иркенлектә буласы киләдер. Бөтенесе дә җиңел генә булыр

кебек тоелу чоры ул. Ата-анага бу вакытта ярдәм итәрдәй гыйлем ияләре кирәктер. Бала үзе дә нишләргә кирәген белмәс, әти-әнисеннән дә кайтып сорарга ояла торган сораулары булыр. Шуңа да аларны яхшы киңәш бирерлек кешеләр белән таныштыру мөһим.

Киләсе чор: 25 яшькә кадәр дәвам итәр. 25 яшеннән соң кеше үсеше тукталыр. Бу – баш миенең формалашып беткән чорыдыр. Шуңа күрә күпчелек балаларда бу яшькә җиткәнче алдан күрүчәнлек тойгысы оешмаган була. Ата-ана бу яшенә кадәр балага: «Нәрсә уйлыйсың син, башың эшләмиме әллә инде, бернинди кызыксынуың юк», – дип, бик күп тапкырлар әйтсә дә, бала олылар кебек уйлый белми, уйларлык сәләте дә юк. Бу яшьтә бала оешып бетмәгән һәм бу ялгышларны төзәтү чорыдыр.

Бер хикмәтле әтинең вакыйгасын сөйләп китәм. 2000 еллар башында 15 яшендә булган малае белән бер ата машина маен алыштыра икән. Әти кеше кулланылган майны агызып алгач, иске майны савыты белән машина кырыенда калдыра. Үзенең башка эше чыгып, малаена: «Улым, майны салырсың әле», – дип әйтеп китә. Яшүсмер, әлбәттә, анымоны уйламыйча, кулланылган шул иске майны двигательгә кире сала. Бераздан әтисе килә дә:

– Салдыңмы улым? – ди.

– Әйе, әти – дип җавап бирә бала.

Әти кеше яңа майның шул килеш торганың күреп, гаҗәпләнеп, улыннан йомшак кына итеп:

– Улым син кайсысын салдың соң? – дип сорый.

– Син агызганын, – дип җавап кайтара малае.

Күпчелек әтиләр бу очракта ачы итеп орышыр иде. «Башың кайда соң синең?! Кеше төсле булмадың», – дип әрләр иде. Үз балаларын кыйнаучылар да бар. Тик сабыр, түзем ата улының җилкәсеннән кагып, яратып елмаеп:

– Афәрин, улым, майны дөрес урынга салгансың, – дип, баласын үсендерә.

Бала да үз чиратында: «Әти, син ул майны ник агыздың соң?» – дип сорый. Әти кеше янә елмаеп: «Яңасын салыр өчен», – дип җавап бирә.

Тагын бер майны агызу һәм яңасын салу берни тормый. Ләкин баланың күңелен төшереп, эштән биздерү яхшы гамәл булмас иде. Ул алдагы тормышта үзен булдыксыз итеп тоеп, ялгышса да төзәлергә хакы барлыгы хисен югалтыр иде.

Бала чактагы шушындый кечкенә вакыйгалар эш сөю, динебезне сөю хисләренә нигез саладыр. Баланың нинди булырга тиешлеген һәрберебез белә, ләкин ул халәткә ни рәвешле җиткерергә итеп тәрбияләргә икәнен өйрәнмибез. Өйдәге диалог та бары тик: «Син тиеш!» – дигән сүз белән чикләнә. Тиеш, әмма ничек тиеш булуын аңлату – безнең – ата-аналар өстендәге бурычыдыр.

Балаларны сөю, аларның дөрес тәрбияле булулары бездән торадыр. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең бер хәдисендә: «Һәр бала фитри иман белән туадыр. Тик ата-анасы гына аны яки насара, яки яһүди, яки мәҗүси итәдер», – дип әйтелгән. Бәлки безгә дә җаваплылыкны үз өстебезгә алып, дөрес тәрбия бирергә вакыттыр. Замана чиренә сылтап, үзебездән торганын үтәмичә берни дә үзгәрмәс.

Раббыбыз Аллаһы балаларыбызны, Кыяматкәчә булган киләсе нәселләребезне, иман әһеленнән кылып, кушканнарын үтәүче, тыйганыннан тыелучылар белән сөендерсен. Әмин.

* * *

Фузаил бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул булына торган бер догам барлыгын белсәм, мин җитәкче өчен дога кылар идем», – дип әйткән.

Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә президентыбыз – Рөстәм Нургали улының

саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядъкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең, телебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Райнур хәзрәт Газизов,*

*Кукмара шәһәре,*

*«Нәсыйхәт» мәчете имам-хатыйбы*

*4 нче июнь вәгазе,*

*Шәүвәл аеның 23 нче көне, һиҗри исәп буенча 1442 ел*

# Әйләнә-тирә мохитне саклау

Барча галәмнәрне юктан бар кылып, тәрбияләп торучы Аллаһы Тәгаләгә мактауларыбыз булсын. Галәмнәргә рәхмәт итеп җибәрелгән, динне аңлаткан, өйрәткән, безгә үрнәк булган пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә күңел түрләребездән чыккан салават-шәрифләребез ирешсен. Аллаһы Тәгалә изге җомга көнендә мәчеткә килеп кылган гыйбадәтләребезне кабул кылсын, мәчеткә атлап килгән адымнарыбыз әҗер-савапларыбыз артуга, гөнаһ-хаталарыбыз кичерелүгә сәбәп булсын. Ниндидер җитди сәбәпләр килеп чыгу аркасында гына мәчеткә килеп җитә алмаган мөселман кардәшләребезгә күңелләрендә булган изге ниятләренә, изге теләкләренә карап әҗер-савaплары насыйп булсын. Аллаһы Тәгалә безгә вәгазьләнеп, дөнья өчен, Ахирәт өчен файдалы сүз, файдалы фикер аңларга насыйп кылсын.

Ислам дине – бу дөньяны һәм Ахирәтне дә үз эченә алган камил дин. Ислам – дин кушканча яшәгән кешене дөньяда да, Ахирәттә дә бәхетле итә торган диндер. Аллаһы Тәгалә кешеләргә дөньяда яшәгәндә кулланма буларак пәйгамбәрләре аркылы китапларын иңдерде. Иң соңгы китабы – Коръәни Кәримдә Аллаһы Тәгалә «фикерләгез», «уйлап карамыйсызмы?», «акылыгызны эшләтмисезме?» дигән сүзләр белән еш мөрәҗәгать итә. Ул бу сүзләрне Коръәндә калган буш урыннарны тутыру өчен әйтми. Ә кешеләрне фикерләргә, уйларга, гыйбрәт алырга чакыра. Коръәни Кәримнең түбәндәге аятьләрендә Аллаһы Тәгалә болай дип әйтә:

إِنَّ فِي خَلْقِ السَّمَاوَاتِ وَالْأَرْضِ وَاخْتِلَافِ اللَّيْلِ وَالنَّهَارِ وَالْفُلْكِ الَّتِي
تَجْرِي فِي الْبَحْرِ بِمَا يَنفَعُ النَّاسَ وَمَا أَنزَلَ اللَّهُ مِنَ السَّمَاءِ مِن مَّاءٍ فَأَحْيَا
بِهِ الْأَرْضَ بَعْدَ مَوْتِهَا وَبَثَّ فِيهَا مِن كُلِّ دَابَّةٍ وَتَصْرِيفِ الرِّيَاحِ وَالسَّحَابِ
الْمُسَخَّرِ بَيْنَ السَّمَاءِ وَالْأَرْضِ لَآيَاتٍ لِّقَوْمٍ يَعْقِلُونَ ﴿١٦٤﴾

**«[Әгәр синнән Аллаһы Тәгаләнең берлеге мәсьәләсендәге бәяннарның дөреслеген раслый торган бер дәлил сорасалар, менә аларга күпме дәлил] һичшиксез, күкләрнең һәм җирнең ятатылышында, төн белән көннең бер-бер артлы килүендә, кешеләргә файдалы [азык-төлек, кием-салым һәм ягулык кебек] нәрсәләр белән [йөкләнеп] диңгездә йөргән көймәләрдә, Аллаһы күктән яудырган суда һәм [шул сулары белән] үлгәненнән соң җирне терелтүендә, анда хәрәкәт итә алган төрле хайваннар таратуында, җилләрнең [бер яктан бер якка] үзгәрүендә һәм җир белән күк арасында [Аллаһының яудыру әмеренә] буйсындырылган болытларда, [акыл күзе белән карап яхшылап төшенеп, хакыйкатьне] аңлый алган кешеләр өчен, әлбәттә, билгеләр бар».**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:164

الَّذِينَ يَذْكُرُونَ اللَّهَ قِيَامًا وَقُعُودًا وَعَلَىٰ جُنُوبِهِمْ وَيَتَفَكَّرُونَ فِي خَلْقِ
السَّمَاوَاتِ وَالْأَرْضِ رَبَّنَا مَا خَلَقْتَ هَٰذَا بَاطِلًا سُبْحَانَكَ فَقِنَا عَذَابَ النَّارِ
﴿١٩١﴾

**«Алар [акыл ияләре] аякта торганда да, утырган килеш тә, янтыкларында килеш тә Аллаһыны зикер итәләр һәм күкләр белән җирнең яратылышы турында фикерлиләр: «Ий Раббыбыз! Син**

**моны юкка яратмадың. Син [юкка нәрсә дә булса яратудан һәм юк-бар белән шөгыльләнүдән] пакьсең! Безне Ут газабыннан сакла!»**

«Әлү Гыймран / Гыймран гаиләсе», 3:191

Аллаһы Тәгалә адәм баласын җиргә хәлифә, башлык итеп урнаштырды һәм кешеләргә җирдәге булган нәрсәләрне, файдалансын, куллансын, саклап тотсын өчен, әманәт итеп тапшырды. Һәм кеше, үз чиратында, Аллаһы биргән шушы нәрсәләрне җаваплылык тоеп, исраф кылмыйча кулланырга тиеш. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Дөнья матур һәм яшел. Чынлыкта, Аллаһы сезне анда хәлифә итеп куйды. Ул сезнең кылганнарыгызны күрә», – дип әйткән. Җирдә кешегә, матур, тыныч яшәү өчен, бөтен мөмкинлекләр тудырылган. Ләкин кешенең тирә-юньгә, табигатькә, кошларга, хайваннарга зыян китерергә хакы юк. Бернәрсәгә дә зыян китермәү һәм тирә-юньгә файда китерү – Ислам диненең төп кагыйдәләреннән. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм походта булган чакта сәхабәләренә агачларны кисмәскә, игеннәрне, кырларны яндырмаска кушкан. Хәтта дошманныкы булса да бу эшләр тыела. Шуңа күрә мөэмин-мөселман бу дөньяда яшәгәндә күбрәк файдалы эшләр эшләргә тырыша, чөнки дөнья – Ахирәтнең кыры. Дөньяда нәрсә чәчсәң, Ахирәттә шуны урырсың, ягъни бу дөньяда кылган изге гамәлләре кешенең җәннәткә керүенә сәбәб була ала. Шулай ук дөньяда кылган начар гамәлләре кешене җәһәннәмгә кертә ала. Шуңа күрә кеше бу дөньяда җаваплылык тоеп, һәр гамәле өчен җавап бирәсен белеп яшәргә тиеш.

Мөэмин-мөселман гамәлләре өчен әҗер-савап алуына, шул сәбәпле гөнаһлары кичерелүенә ышана. Бер хәдистә болай дип риваять ителә: сәфәрдә барганда бер кешенең бик нык эчәсе килә. Ниһаять, ул бер коега барып җитә һәм коега төшеп су эчә. Менгәч, сусаган һәм әлсерәгән бер этнең кое янында телен салындырып торганын күрә. Мин дә шушы эт кебек сусаган хәлдә идем дип, аны кызгана, хәленә керә. Су алырга бернәрсә

дә булмау сәбәпле, аяк киеменә салып, коедан су алып менә һәм шуның белән эткә су эчерә. Аллаһы Тәгалә, шушы эткә мәрхәмәтлек күрсәтеп, ихлас кылган шул гамәле өчен, аның гөнаһларын кичерде, диелә. Бу хәдистә хайваннарга шәфкатьле, мәрхәмәтле булу хакында әйтелә. Читлекләрдә ябып кошлар асрау, хайваннарны вакытында ашатмый-эчертми тору, тарта алмаслык йөк төяү һәм урынсыз кыйнау, тиешсез җирләренә сугулар – һәрберсе гөнаһтыр. Бу гамәлләр кешенең җәһәннәмгә керүенә сәбәп булырга мөмкин. Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи вә сәлләм әйткән: «Бер хатын мәче өчен газап кылынды. Ул мәчене ябып тотты, аңа ашарга, эчәргә бирмәде. Мәче үзе ризык тапсын дип чыгарып та җибәрмәде, аның ачтан үлүенә сәбәпче булды». Кеше җан ияләренә булган мөнәсәбәте, изгелеге яки начарлыгы өчен генә түгел, хәтта җансыз нәрсәләргә мөнәсәбәте өчен дә савап яки гөнаһ алырга мөмкин. Мөэмин-мөселман утырткан агач, үстергән ашлык өчен әҗер-савап аласын аңлый. Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән: «Әгәр мөселман агач утыртса яки ашлык чәчсә, аннары шушыларның җимешләрен кеше, хайван яки кош ашаса, аңа садака булып, изгелек булып языла. Хәтта кеше вафат булгач та, дөньяда чагында эшләп калдырган изгелегенең савабы килеп торачак. Ягъни, кеше исән чагында башкаларга файда китерә торган нәрсәләр калдырса, үлгәч тә аңа саваплары килеп торачак. Кеше исән чагында җәмгыятькә файдалы гамәлләр эшләп калдырса, башкакешеләр шул әйберне кулланганда, үлгән кешегә саваплары барып торачак. Мәсәлән, кеше исән вакытында бер җимеш агачы утыртып калдырган булса, шул агачның җимешләрен берәр кеше, хәтта берәр кош яки хайван ашаса да, үлгән кешегә савабы барып торачак. Чишмә, кое казытса, төзекләндерсә, шул эшләрдә ярдәм итеп, үзеннән күпмедер өлеш кертсә, шул чишмәдән, коедан кулланганда, аның суын эчкәндә, ярдәм иткән кешеләргә саваплар барып торачак. Елга аша чыгарга күпер салдырса, шул эштә ярдәм итсә, шул күпердән йөргәндә, кулланганда бу изгелектә сәбәпче булган кешеләргә саваплар күчеп тора-

чак. Берәү мәчет, мәдрәсә төзергә ярдәм итсә, шунда белем алганда, намаз укыганда, шул эштә сәбәпче булган барча кешеләргә саваплар үлгәч тә гамәл дәфтәрләренә күчеп барачак. Бу дөньяда кешеләргә файдалы булган нәрсә генә эшләсәк тә, моның файдаларын күрәчәкбез, савапларына ирешәчәкбез, иншәАллаһ. Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм, ахырзаман җиткән очракта да, кешеләрне файдалы эшләр эшләп калырга өндәгән. Аллаһының Расүле болай дип әйткән: «Әгәр Кыямәт көне башланса, сезнең кулыгызда агач үсентесе булса, аны утыртсын, аның өчен дә әҗер-савап алыр». Бу эшеңне ташла да, дога кыл яки намаз укы, дип әйтми, ә агачны утыртырга куша. Мөхтәрәм җәмәгать, уйлап карасак, чынлыкта, ул агачның җимеше инде булмаячак, ул үсә алмаячак, чөнки дөнья бетәчәк. Ләкин Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Утырт, аның өчен дә савап алырсың», – дип әйтергә теләгән. Моннан кеше нинди генә яхшылык эшләсә дә, аның өчен савап алачак икәнлеге аңлашыла.

Мөселман кешесе табигатьне саклый, аны пычратмаска тырыша. Табигатьне чүпләрдән чистарта, чөнки ул гамәле дә аны савапка, җәннәткә илткән изгелек икәнен тоя. Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм бу хакта болай дип әйткән: «Юлда кешеләргә комачаулаган ташны, агачны алып куйса, ул садака була». Икенче бер хәдистә: «Комачаулаган нәрсәне юлдан алып куйган өчен, Аллаһы Тәгалә шул кешегә рәхмәт әйтте һәм гөнаһларын кичерде», – дип әйтелә.

Мөэмин-мөселман бөтен кылган изге гамәле белән үзенә җәннәтне кәсеп итә. Тагын бер хәдистә: «Эшләп, арып йокларга ятучының гөнаһлары кичерелә», – дип әйтелә. Әлбәттә, хәләл хезмәттә эшләүче икәнен истә тотарга кирәк. Шулай булганда гына динебезгә туры килер. Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм бервакытны бер сәхабәнең каралып, ярылып беткән кулларын тотып: «Бу кул иясе җәһәннәмгә кермәс», – дип әйткән. Җәһәннәмгә кермәгәч, ул җәннәткә керә дигән сүз була, чөнки ике генә урын бар: җәннәт яки җәһәннәм. Аның куллары намаз укудан,

дога кылудан түгел, ә эш эшләүдән каралган, ярылган бит. Аның тырышып эшләве, гамәл кылуы җәннәткә керүгә сәбәп була ала. Әлбәттә, мөхтәрәм дин кардәшләрем, кеше нинди генә изге гамәлләр эшләсә дә, иң беренче чиратта, Аллаһы хакын үтәү кирәк. Аллаһының кушканнарын үтәү, тыйганнарыннан тыелып яшәү тиешле. Биш вакыт намазларыбызны үтәп, Аллаһы Тәгалә кушканча дөрес итеп яшәсәк, нинди генә эш-гамәл кылсак та, саваплы гыйбадәттән китәчәк, дип ышанырга була. Аллаһы Тәгалә Үзенә буйсынып, табигатьне саклап, җирдәге хайваннарга һәм кошларга, агачларга да мәрхәмәтле булып яшәүне насыйп итсен. Дөнья тормышын яхшыртуга өлешебезне кертеп яшәүчеләрдән кылсын. Файдалы гамәлләр кылып, шуларның хәерле нәтиҗәләрен, савапларын бу дөньяда да һәм Ахирәттә дә күреп сөенергә насыйп итсен. Мәчетебездә күрешкән кебек җәннәтләрдә дә шулай күрешергә, бер-берләребезне күреп шатланырга насыйп кылсын. Әәмин.

* * *

Фузаил бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул булына торган бер догам барлыгын белсәм, мин җитәкче өчен дога кылар идем», – дип әйткән.

Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә президентыбыз – Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядькәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең, телебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Рифат хәзрәт Ибраһимов,*

*Кукмара районының Зур Сәрдек авылы имам-хатыйбы,*

*Кукмара мәдрәсәсе мөгаллиме*

*11 нче июнь вәгазе,*

*Зөлкагъдә аеның 1 нче көне, һиҗри исәп буенча 1442 ел*

# Зөлкагъдә ае – харам айларның берсе

Барча галәмнәрне барлыкка китереп, аларны тәрбия кылучы, безне нигъмәтләндереп торучы, мөэмин-мөселманнар өчен каберне җәннәтнең бер бакчасы итеп кылучы, имансыз бәндәләр өчен каберне җәһәннәмнең бер утлы чокыры итүче Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгаләгә хәмед вә сәналәребез булса иде! Аның хак хәбибе, кешелеккә туры юлны өйрәтеп калдырган, мөселманнарны җәннәт белән сөендергән вә имансызларны җәһәннәм белән кисәткән, галәмнәргә рәхмәт буларак җибәрелгән сөекле пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә күңелебезнең иң түрләреннән чыккан салават-шәрифләребез булса иде!

Кадерле җәмәгать! Матур итеп кенә Рамазан ае үтеп китте. Инде хаҗ аена, ягъни зөлхиҗҗәгә якынлашабыз, Аллаһыга шөкер. Менә бүгеннән һиҗри җәдвәл буенча зөлкагъдә аена аяк бастык, бүген – аның беренче җомгасы. Аллаһы Тәгалә бу көннәребезне бәрәкәтле, имин кылса иде.

Вәгаземне һиҗри айларны санап китү белән башлыйм. Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

إِنَّ عِدَّةَ الشُّهُورِ عِندَ اللَّهِ اثْنَا عَشَرَ شَهْرًا فِي كِتَابِ اللَّهِ يَوْمَ خَلَقَ السَّمَاوَاتِ وَالْأَرْضَ

**«Һичшиксез, Аллаһы хозурында айларның саны Аллаһының күкләрне һәм җирне яраткан көндәге [катгый карарын белдергән] язуында [Ләүхүл-Мәхфүздә] – уникe».**

«Тәүбә», 9:36

Шулай итеп, исламда айның тулып кимүенә карап, ел унике айдан тора. Болар: мөхәррам, сафәр, рабигыль-әүвәл, рабигыль-ахыр, җөмәдәл-әүвәл, җөмәдәл-ахыр, раҗәб, шәгъбан, Рамазан, шәүвәл, зөлкагъдә, зөлхиҗҗә. Мөселман бу айларны белергә тиеш, чөнки ислам динендәге нинди генә истәлекле датаны алсак та, алар барысы да шушы җәдвәлгә корылган: Мигъраҗ, Бәраәт кичәсе, Рамазан ае уразасы, Мәүлид, хаҗ һ.б. Һиҗри җәдвәл – айга карап, милади кояшка карап билгеләнә, шуңа да ай елы кояш елыннан ун көнгә кимрәк. Ел саен ун көн күчеш булганга, хаҗ һәм ураза кайчак кышка, кайчак җәйгә туры килә.

Дөреслектә, Аллаһы Тәгалә кайбер айларны һәм көннәрне калганнары арасыннан сайлап алды һәм дәрәҗәләрен югары кылды. Шулай ук, Раббыбыз кайбер айларны Үзенең хикмәте белән харам итеп билгеләде, шушы 12 айның 4се харам айлар булып санала. Харам айларда кылынган гөнаһның да, изге гамәлнең дә авырлыгы зуррак. Моның турында Аллаһы Тәгалә әле генә укыган аятьнең дәвамында болай дип әйтә:

مِنْهَا أَرْبَعَةٌ حُرُمٌ ۚ ذَٰلِكَ الدِّينُ الْقَيِّمُ ۚ فَلَا تَظْلِمُوا فِيهِنَّ أَنفُسَكُمْ ۚ

> **«Шуларның дүртесе – харам [айлар]. Бу – [рәвешле елның уникe ай булып, шуларның дүртесенең харам кылынуы турындагы хөкем Ибраһим һәм Исмәгыйль галәйһимүссәлам] калган] хак дин. [Моннан соң бернинди айда да, бигрәк тә] Боларда [гөнаһ эшләү һәм гыйбадәтләрне кире кагу белән җаныгызны җәһәннәмгә атып] үз-үзегезгә золым итмәгез».**

«Тәүбә», 9:36

Бу 4 ай: раҗәб, зөлкагъдә, зөлхиҗҗә һәм мөхәррам. Пәйгамбәребез дә бу хакта: «… Ел уникe айдан тора, шуларның дүртесе – харам айлар. Өчесе – зөлкагъдә, зөлхиҗҗә һәм мөхәррам бер-бер артлы киләләр, ә дүртенчесе – җөмәдәл-ахыр белән шәгъбан арасындагы раҗәб ае», – дигән.

Зөлкагъдә – мөселман тәкъвименең 11 нче ае. Гарәпчәдән бу сүз «утырып тору», «бер урында тору», «утраклык ае» дип тәрҗемә кылына. Намазда да кагъдә – утырып тору бар. Бу айда гарәпләр үзләренең күченеп йөрүләрен тәмамлаганнар һәм хәрби походларын туктатып торганнар. Зөлкагъдә харам айларның берсе, дип әйтеп уздык. Әмма харам ай булганга гына бу айларда гөнаһларның авырлык дәрәҗәсе шулай югары түгел. Гарәп теленнән кергән ихтирам сүзенең дә тамыры харам сүзенең тамыры белән бер бит. Икенче төрле әйткәндә, бик тә хөрмәтле айлар булганга, бу айда гөнаһлар кылу да ярамас.

Зөлкагъдә, калган һиҗри айлар кебек, бик фазыйләтле, хөрмәтле айлардан санала. Аның турында, бер яктан караганда, мәгълүмат та күп түгел кебек. Шул ук Рамазан аен алып карасак, бу айда ураза буласын бар дөнья белә кебек. Ураза һәм Корбан гаетләре белән дә эш шулайрак тора. Ә сез пәйгамбәрләребез Ибраһим һәм Гайсә галәйһимүссәламнәр дә шушы айда туганнарын белә идегезме? Яки зөлкагъдә аеның харам ай икәнен?

Зөлкагъдә – утырып тору, утрак тормыш, дип әйттек. Утырып тору, ягъни дөнья куып, арлы-бирле чабудан туктап тору, утырып уйланып алу, бу дөнья һәм Ахирәт хакында фикер йөртү. Нәфесебезне тәрбияләү, якынлашып килә торган хаҗ турында гыйлемнәр алу – болар барысы да зур бер форсат булып тора бит. Әмма нәфес – ул кешенең аерылгысыз бер өлеше. Кемдер нәфесне начар бер әйбер дип күз алдына китерергә мөмкин. Әмма, җәмәгать, нәфес булмаса, без, гади генә әйткәндә, акча эшләргә, ризык эзләргә дә иренеп утырган булыр идек. Нәфесне гаепләү, аны гөнаһка илтә торган бер әйбер дип кабул итү – бераз хата да. Үзеңне, гаиләңне тәэмин итү – ир-атның турыдан-туры вазифаларыннандыр. Нәфесне галимнәр берничә төргә бүлеп карыйлар. Әмма аларның иң яхшысы – сине Аллаһыга якынайта торган нәфес: тынычлап гыйбадәт тә кылдыра, тынычлап эшләтә тә. Кеше, нәфесенә карап, әллә ниләр эшләргә омтылып яши, ник әле шул нәфеснең омтылышын җәннәткә керергә

юнәлдермәскә, ди? Тормышта бик күп юллар бар, әмма ат та бит, дилбегә кайсы якка тарта, шул якка борыла. Нәфесебезне һәрдаим тәрбияләп торсак, аны йөгәнләп, изге гамәлләр эшләргә юнәлдерсәк, тормыш юлыбыз да, иншәАллаһ, хәерле җирләргә генә илтер.

Зөлкагъдә аенда махсус гыйбадәтләр, әлбәттә, каралмаган. Һәрвакыттагыча игелекле эшләр башкарырга, гыйбадәтләребезне арттырырга, намаз укырга, садака бирергә, Коръән укырга, холкыбызны яхшыртырга һәм гөнаһлардан ерагаерга омтылырга кирәк. Имам Әбү Давыд рахмәтуллаһи галәйһи китергән бер хәдистә бик тә мөһим сүзләр әйтелгән: «...тыелган айларда ураза тот һәм авыз ач, тыелган айларда ураза тот һәм авыз ач...» Ошбу хәдисләрдә харам айларның һәр көнен уразада булырга кирәк, дигән мәгънә ятмый, динебездә Рамазан аеннан кала көн саен ураза тота торган айлар юк. Әмма ураза гыйбадәт кылуның иң мөһим төрләренең берсе булып тора. Ураза тоту яшерен савапка ия икәнен онытмасак иде, ягъни ураза турында ураза тотучы кеше үзе һәм Аллаһы Тәгалә генә белә. Шуның белән дә ул калган гыйбадәтләрдән аерылып тора.

Әбү Һөрайра радыяллаһу ганһедән китерелгән хәдистә болай дип әйтелә: «Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәллам болай дип әйтте: «Адәм балаларының гамәлләре Аллаһы Тәгалә хозурына дүшәмбе һәм пәнҗешәмбе көннәрендә китерелә. Һәм мин гамәлләрем Раббым каршына китерелгәндә уразалы булырга телим».

Пәйгамбәребезнең сөннәте булган дүшәмбе һәм пәнҗешәмбе уразалары, һәр һиҗри айның уртасында – 13, 14, 15е көннәрендә тотылган сөннәт уразалары бу айда да тотылса, хөрмәтле, ихтирамлы ай булганга күрә, савабы тагын да артыграк булыр, иншәАллаһ.

Зөлкагъдә аеннан соң зөлхиҗҗә ае килә. Ислам диненең бер баганасы, фарыз булган олуг гыйбадәт – хаҗ ае һәм вәҗиб булып торган корбан

чалу ае. Зөлхиҗҗә аенда да ураза тоту турында күпләребезнең ишеткәне бардыр. Ә аңа әзерлек итеп шушы ай тора.

Хаҗга бырырга, корбан чалырга ниятләгән һәр кешегә Аллаһы Тәгалә җиңеллекләрен бирсен! Безнең кылган изге гамәлләребезне кабул итсен! Барчаларыбызга да Аның яраткан колларыннан булып яшәргә насыйп вә мияссәр кылсын. Әәмин!

* * *

Фузаил бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул булына торган бер догам барлыгын белсәм, мин җитәкче өчен дога кылар идем», – дип әйткән.

Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә президентыбыз – Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядъкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең, телебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Шамил хәзрәт Әхмәтгалиев,*

*Арча районы, Хәсәншәех авылы имам-хатыйбы*

*18 нче июнь вәгазе*

*Зөлкагъдә аеның 18 нче көне, һиҗри исәп буенча 1442 ел*

# Туган илне яратуның әһәмияте

Адәм баласына иксез-чиксез нигъмәтләр биреп, бер генә мизгелгә дә Үз рәхмәтеннән ташламаучы, ата-анабызга караганда да җитмеш мәртәбә ныграк яратучы Аллаһы Раббыбызга дан вә мактаулар булсын. Барча галәмнәргә рәхмәт өчен җибәрелмеш булган, калебләребезнең табибы һәм нуры булып торучы пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә күңелләребезнең иң түрләреннән чыккан салават-шәрифләребез булса иде.

Безнең калебебезне Хак Тәгалә шундый киң, матур һәм тирән итеп яраткан. Шуңа да без бөтен дөньяны яратырга мөмкинбез. Раббыбыз безгә, иң беренче чиратта, Аны, пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмне, ата-анабызны, күрше, туганнарыбызны һәм кардәшләребезне яратырга куша. Шулай ук һәр кеше үз йортын, туган җирен, илен ярата. Әйе, җир йөзендә безне Раббыбыз төрле милләт, төрле тел, төрле тән төсләре белән халык кылды. Әмма шуңа да карамастан, без – кешеләр, ягъни адәм балалары. Ә инде Аллаһының соңгы Расүленә ышанып, аны пәйгамбәр итеп таныган һәр кеше мөселман була. Аллаһы Тәгалә иңдергән Коръәни Кәрим нәрсә әйтә соң? Аллаһы Тәгалә Коръәндә бик күп аятьләрдә, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм хәдисләрендә төрле милләт, дин, тел, тән төсе кешеләренә карата татулык, яхшылык, ярдәм күрсәтү хакында хәбәр ителә. Мәсәлән, Коръәни Кәримнең «Әр-Рум» сүрәсенең 22 нче аятендә Аллаһы Тәгалә болай дип әйтә:

وَمِنْ آيَاتِهِ خَلْقُ السَّمَاوَاتِ وَالْأَرْضِ وَاخْتِلَافُ أَلْسِنَتِكُمْ وَأَلْوَانِكُمْ ۚ إِنَّ فِي ذَٰلِكَ لَآيَاتٍ لِّلْعَالِمِينَ ﴿٢٢﴾

**«Күкләрне һәм җирне яратуы да, телләрегезнең һәм төсләрегезнең төрлелеге дә – Аның билгеләреннән. Һичшиксез, монда [Аллаһы Тәгаләнең бөек сыйфатларын яхшы] белгәннәр өчен билгеләр бар».**

«Әр-Рум / Румлылар», 30:22

Без кайсы милләт, кайсы тән төсе, кайсы җирдә тууны сайлап ала алмыйбыз. Аллаһы Тәгалә безгә кайсы җирдә дөньяга килүне насыйп кылса, шул җирдә туып, шөкер итеп, изгелек кылып яшәргә тиешбез. Һәр кеше туган илен чын күңелдән яратып, ихластан туган илен, телен, милләтен, диненең кыйммәтләрен саклауда үз өлешен кертергә тиеш. Кайвакыт диннең асылын аңлап бетермәгән кешеләр: «Исламда милләтләр, илләргә бүлү юк», – дип әйтә. Әгәр без тарихка күз салсак, төрле милләт вәкилләре Ислам динен кабул иткәч, берсе дә үз милләтеннән, туган җиреннән баш тартмаган. Ә киресенчә, үз телләрендә китаплар язганнар. Туган илне яклау, саклау, ярату ул олы йөрәкле, зирәк зиһенле кешегә генә бирелә. Зур галимнәрнең язмаларына карасак, анда без динне саклауда милләт һәм гореф-гадәтнең никадәр мөһим булуын күрәбез, чөнки әгәр бер милләтнең туган җире булмаса, милләт кыйммәтләре дә юкка чыга. Ә инде милләте һәм кыйммәтләре юкка чыккан халыкның дине дә юкка чыга.

Әгәр җирлегебезнең тарихына карасак, төрле милләт, раса вәкилләре кылган күп батырлыклар хакында белә алабыз. Безнең мөселман дине вәкилләрен генә алсак та, таң калырлык батыр гамәлләр бар, чөнки туган йортын, якыннарын, туып үскән җирен саклау һәр мөселманның зур бурычы булып тора. Аллаһы Тәгалә җир йөзендә безләрне бер хуҗа итеп

билгеләде. Шушы җирдә кан коймыйча, изгелек кылып, күркәм холык һәм әдәп белән яшәргә әмер итте. Без туган илгә ярату белән карарга, туган якны онытмыйча яшәргә тиеш, чөнки нәкъ менә шушы җирдә без беренче мәртәбә аваз салганбыз, безнең беренче сәҗдәләребез дә – шушы җирдә. Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләм дә Мәккә шәһәрен бик сагына торган булган. Ничек кенә булмасын, нинди генә булмасын, туган якка булган мәхәббәт хисе йөрәккә бик тирәнгә кереп утыра.

Туган якны ярату бик мөһим, чөнки күңеле мәхәббәткә, изгелеккә ачык булган, кыйммәтләрне аңлый белгән кеше генә бәхетле була ала. Бер-беребезгә – мәхәббәт, хөрмәт, ә туган якка ярату белән карыйк. Шул очракта гына без зур дәрәҗәгә ирешә алабыз. Үзебез яшәгән җир өчен без үзебез җаваплы. Шушы җаваплылыкны сизеп, Аллаһы ризалыгына ирешерлек итеп яшәсәк иде. Әәмин.

* * *

Фузаил бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул булына торган бер догам барлыгын белсәм, мин җитәкче өчен дога кылар идем», – дип әйткән.

Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә президентыбыз – Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядькәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең, телебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Алмаз хәзрәт Галимҗанов,*

*Саба районы имам-мөхтәсибенең яшьләр белән эшләү буенча ярдәмчесе,*

*Сатыш авылы имам-хатыйбы*

*25 нче июнь вәгазе*

*Зөлкагъдә аеның 15 нче көне, һиҗри исәп буенча 1442 ел*

# Харам матдәләрне куллануның зыяны

Галәмнәрне юктан бар итеп, аларны Үзенең хикмәте белән тәрбияләп торучы, безне, шушы дөньяга төрле сынаулар белән сыналыр өчен, җибәргән Аллаһы Тәгаләгә дан-мактауларыбыз булса иде. Шул сынауларны дөрес итеп үтәргә өйрәтер өчен җибәрелгән, мөэминнәрне җәннәт белән сөендергән, имансыз һәм монафикъларны җәһәннәм белән кисәткән Аллаһының Расүле Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә күңел түрләребездән чыккан салават-шәрифләребез булса иде.

Аллаһы Тәгалә Ислам динен, Шәригатьне безгә акны карадан, хәләлне харамнан аерыр өчен җибәрде. Бүгенге вәгазебез харам матдәләрне куллануның зыяны турында булачак. Ә нәрсә соң ул хәләл? Һәм нәрсә ул харам?

Кызганычка, безнең тирәлектә бу сүзләрнең мәгънәләре бик кыска формада гына таралган. Харам дип әйткәч, иң беренче, ризык күз алдына килә. Ризыктан да фәкать дуңгыз ите һәм эчемлекләрдән исә спиртлы эчемлекләр генә ярамый, дип уйлый халык. Ләкин бу төшенчеләр бик зур мәгънәгә ия.

Мал суйганда, тиешле кагыйдәләр үтәлмәгән булса, бу ит тә куллаyыр өчен харам була ала. Мөселман кешесе хайванны чалган вакытта: «Бисмилләһи, Аллаһү әкбәр», – дип әйтә икән, ягъни Аллаһы Тәгалә ризалыгын өмет итеп, Аның исеме белән чала икән, бу ит хәләл була. Коръәндә Аллаһы Раббыбыз болай дип әйтә:

قُل لَّا أَجِدُ فِي مَا أُوحِيَ إِلَيَّ مُحَرَّمًا عَلَىٰ طَاعِمٍ يَطْعَمُهُ إِلَّا أَن يَكُونَ مَيْتَةً أَوْ دَمًا مَّسْفُوحًا أَوْ لَحْمَ خِنزِيرٍ فَإِنَّهُ رِجْسٌ أَوْ فِسْقًا أُهِلَّ لِغَيْرِ اللَّهِ بِهِ ۚ فَمَنِ اضْطُرَّ غَيْرَ بَاغٍ وَلَا عَادٍ فَإِنَّ رَبَّكَ غَفُورٌ رَّحِيمٌ ﴿١٤٥﴾

**«[Расүлем!] Әйт: «Үләксә, йә [чалынган чакта сиптереп] аккан кан, йә дуңгыз ите, чынлыкта, ул – бер нәҗес; йә [ялгышлык белән түгел, ә белә торып] Аллаһыдан башка берәүнең исеме телгә алынган [булганлыктан] бер шакшыдан тыш, [Коръәндә] миңа вәхи ителгәннәр арасында [ир белән хатынга аермыйча] ашаучы өчен, ашавы харам кылынган бернәрсә дә тапмыйм». Әмма [шуның белән бергә] кем дә кем [үзе кебек авыр хәлдә калган берәүгә ташланып] бозыклык кылмыйча һәм [үлмәслек кадәр генә ашау яраган] чикне ашмыйча, [югарыда тыелулары турында әйтелгәннәрдән нәрсәне дә ашарга] мәҗбүр булса, һичшиксез, синең Раббың бит – [гөнаһларны күпләп] Гафу итүче, Рәхимле».**

«Әл-Әнгам / Терлек», 6:145

Ислам динебездә барлык тыелган нәрсәләр «харам» дигән термин белән атала. Барлык тыюлар Изге Коръән һәм пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең сөннәте – исламның чыганакларында язылган ачык һәм бәхәссез дәлилләргә нигезләнгән. Харам сүзе кешенең эшен, ашау-эчүен, хәтта сөйләшүен дә үз эченә ала.

Мөселманнар өчен нәрсә харам булып санала? Коръәндә Аллаһы Раббыбыз болай дип әйтә:

حُرِّمَتْ عَلَيْكُمُ الْمَيْتَةُ وَالدَّمُ وَلَحْمُ الْخِنزِيرِ وَمَا أُهِلَّ لِغَيْرِ اللَّهِ بِهِ وَالْمُنْخَنِقَةُ وَالْمَوْقُوذَةُ وَالْمُتَرَدِّيَةُ وَالنَّطِيحَةُ وَمَا أَكَلَ السَّبُعُ إِلَّا مَا ذَكَّيْتُمْ وَمَا ذُبِحَ عَلَى

النُّصُبِ وَأَن تَسْتَقْسِمُوا بِالْأَزْلَامِ ۚ ذَٰلِكُمْ فِسْقٌ ۗ

**«[Чалмыйча җаны чыккан] Үләксә, [хайванны чалган чакта агып чыккан] кан, дуңгыз ите, Аллаһыдан башкасы өчен [яисә, җаны чыкканчы өлгереп, Ислам кушканча] чалынганнардан тыш, буылган [һәм үлгән], [таш, агач кебек әйберләр белән] кыйналган [һәм үлгән], [биектән яки кое кебек бер җиргә] егылып төшкән [һәм үлгән], [башка бер хайван тарафыннан] сөзелгән [һәм үлгән], ерткыч хайван ашап, [җаны чыкканчы өлгереп] чалынганнан тыш, [табынила торган] торараташлар [һәм потлар өчен корбан китерелә торган урыннарда] бугазланганнар һәм фал уклары белән багучылык итүегез сезгә харам кылынды. Бу [харамнардан файдалануыгыз] – бер гөнаһкярлык».**

«Әл-Маидә / Табын», 5:3

Шулай итеп, мөселманнарга үләксә, кан, дуңгыз ите, Аллаһы исеме белән суелмаган мал-туар, буып яки башка хайван тарафыннан үтерелгән хайван, югары электр көчәнеше, каты сугу яки биектән егылып төшү сәбәпле үлгән хайван, ерткыч хайваннар һәм ерткыч кошлар ите – харам.

Кеше шундый сорау бирергә мөмкин: ни өчен Аллаһы Тәгалә шушы әйберләрне безгә харам кылды? Җавабы шушы булачак: Аллаһы Тәгалә тыйган нәрсәләрдә кешеләр өчен бик күп зыян бар.

Беренчесе, Аллаһы тыйган һәрнәрсә сәламәтлегебезгә зыян китерә. Аллаһы Коръәндә болай дип әйтә:

يَأْمُرُهُم بِالْمَعْرُوفِ وَيَنْهَاهُمْ عَنِ الْمُنكَرِ وَيُحِلُّ لَهُمُ الطَّيِّبَاتِ وَيُحَرِّمُ عَلَيْهِمُ الْخَبَائِثَ

**«Ул аларны [иман һәм гыйбадәтләр кебек] яхшылыкка өнди, [көферлек һәм гөнаһлар кебек] начарлыклардан тыя, пакь**

**нәрсәләрне [Аллаһы исеме белән чалынган хайваннарны һәм нәҗес булмаган бөтен ризыкны] аларга хәләл итә, [кан, үләксә һәм риба кебек матди һәм рухи] кабахәт нәрсәләрне исә аларга харам кыла, авыр йөкләрен һәм моңарчы өсләрендә [муенна-рына салынган] булган богауларны [авыр җаваплылыкларны] алардан ала».**

«Әл-Әгъраф / Киртәләр», 7:157

Харам дип, бары тик ярамаган ит ризыклары гына түгел, ә гомумән алганда, кеше организмына зыян сала торган барлык төр ризыкларны да атарга кирәк, чөнки хәзерге заман галимнәре дуңгыз итенең һәм мөселманча чалынмаган итләрнең составында зыянлы матдәләр барлыгын фәнни яктан да ачыкладылар. Шуңа күрә хәләл дигәч тә, без кеше сәламәтлегенә зыян салмый торган барлык төр ризыкларны да күз алдында тотарга тиеш. Икенчесе, харам матдәләрне куллану гыйбадәтебезгә зыян китерә. Бер хәдистә Пәйгамбәребез сәлләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән: «Кешенең карынына харам керсә, 40 көн буе кылган догасы кабул булмас». Уйлап карагыз, җәмәгать, мисал өчен, әгәр дә бер мөселман кешесе харам казылык ашаса һәм аннары Аллаһы Тәгаләгә ялварып дога кылса, Аллаһы Тәгалә ошбу бәндәнең догасын кабул итмәс. Бу – бик куркыныч хәл, шуңа күрә безгә бик игътибарлы булырга кирәк: без нәрсә ашыйбыз, нәрсә эчәбез, бу хәләл әйберме яисә хараммы? Һәрберебез үзенә шундый сорау бирергә тиеш.

Өченчесе, харам ризык ашау һәм куллану нәселебезгә зыян китерә. Әгәр балабызга харам ризыклар ашатып үстерсәк, аның ихласлыгы да зәгыйфь булачак. Харам кергән карын авыру була, йөкле чакта харам ашаган ананың баласына начар тәэсир кучә. Шуның өчен дә гаилә коргач, ир кешенең иң беренче бурычы – гаиләсен хәләл ризык белән тәэмин итү. Хәләл ризык ашау – Аллаһы Тәгалә кушканны үтәү, ягъни гыйбадәткә тиң гамәл. Шуның хакта бер гыйбрәтле кыйсса сөйлисем килә.

VI гасырда бер Мөбарәк исемле изге кеше яшәгән. Ул шушы заманындагы бөек патшаның колы булган. Һәм бер көнне шушы патша төш күргән: аның янына бер фәрештә килеп: «Әй, патша, үз кызыңны шушы Мөбарәккә кияүгә бир», – дип әйткән. Патша уянгач шаккатып: «Ничек инде мин үземнең кызымны шушы колга бирим?» – дип әйткән. Тагын йокыга киткәч, шушы фәрештәнең тавышын кабат ишеткән. Аннары тагын бер мәртәбә шул тавышны ишеткәч, үзенең кызын шул Мөбарәк исемле тәкъва егеткә кияүгә биргән. Ике ай үткәч, ул кызы янына барып гаилә хәлләре хакында сораштырган. Кызы әтисенә болай дип җавап биргән: «Барысы дә әйбәт, ләкин менә бер ай инде ул төннәрен минем яныма килми». Патша Мөбарәктән ни өчен төннәрен ул аның кызы янына килмәвен сораган. Мөбарәк аңа болай дип җавап кайтарган: «Сез – патша, сезгә бик күп бүләкләр һәм төрле ризыклар бирәләр һәм чынлыкта, бу ризыкларда шөбһәле әйберләр дә бар. Һәм сез шушы шөбһәле әйберләр белән үзегезнең кызыгызны ашаткансыз. Ә мин, чистарыныр өчен, аңа 40 көн хәләл ризык ашаттым, чөнки мин үз нәселемнең тәкъвалы булуын телим. Һәм шушы гаиләдә мәшһүр галим, факиһ һәм хәдис белгече Габдулла бине Мөбарәк туган. Шуңа күрә, газиз дин кардәшләрем, Аллаһы Тәгаләдән хәләл тормыш сорыйк. Аллаһы Тәгалә шушы сөйләгәннәрдән файда алып, тормышыбызда фәкать хәләл ризык, хәләл кәсеп кенә булып, харамнан тыелып яшәүне насыйп кылса иде.

* * *

Фузаил бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул булына торган бер догам барлыгын белсәм, мин җитәкче өчен дога кылар идем», – дип әйткән.

Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә президентыбыз – Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып

яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядъкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең, телебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Айназ Зарипов,*

*ТҖ МДНнең «Хәләл» стандарт комитеты белгече*

# Әңгәмә

# «Хәләл – ул безнең тормышыбыз»

*Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Кеше тәненә харам керсә, 40 көн буе кылган догасы кабул булмас», – дип әйткән.*[1]

*Без еш кына хәләл ризык, хәләл ит төшенчәләрен дөрес аңлап бетермәү күренешен күзәтәбез. Үзебезнең дә, балаларыбызның да хәләл белән генә тукланып яшәвебезне теләсәк тә, кайбер авырлыклар алдында калырга мөмкинбез.*

*Хәләл белән харамны ничек бутамаска? Ни өчен хәләл ризыкка өстенлек бирү мөһим? Харам ризык ашауның куркынычы нидә? Бу һәм башка сораулар белән ТР МДНнең Хәләл комитеты җитәкчесе, Казан шәһәренең Габдрәхим Утыз Имәни мәчете имам-хатыйбы Ирек хәзрәт Җиһаншинга мөрәҗәгать иттек.*

## Хәләл мәсьәләсен хәл итеп була

**– Хәзрәт, әссәләмү галәйкүм вә рахмәтуллаһи вә бәрәкәтүһ. Әңгәмәбезне күпләрне борчыган актуаль сораудан башларга булдык: балалар бакчаларында, мәктәпләрдә хәләл туклану мәсьәләсе ничек хәл ителә?**

– Әгууҙү билләәһи минәш-шәйтаанир-раҗиим. Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахииим. Әлхәмдүлилләһи Раббил гааләмиин. Вә әл-гакибәтуль лил-мүттәкыйн. Вә ләә гудуәәнә иллә галәҙ-ҙаалимиин. Вәссаләәтү вәссәләәмү галәә расүлинә Мүхәммәдин вә галәә әәлиһи вә әсхаабиһи әҗмәгыйн.

Галәмнәрнең Раббысы булган Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгаләгә хәмде-сәналәребез, мактауларыбыз булса иде һәм дә Аның сөекле хәбибе – Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм хәзрәтләренә салават-

---

1 Имам Әт-Табәрани хәдисләр җыентыгыннан.

шәрифләребез ирешсә иде. Барыгызны да Аллаһының сәламе вә рәхмәте белән сәламлим. Әссәләмү галәйкүм вә рахмәтуллаһи вә бәрәкәтүһ.

Без, хәләл комитеты буларак, «Азык-төлек һәм социаль туклану департаменты» дигән оешма белән эш алып барабыз. Шул эш барышында кешеләрдән: «Хәзрәт, без балаларыбызны балалар бакчасына, мәктәпкә бирергә телибез. Әйтегез әле, анда ризык хәләлме икән?» – дигән сораулар килә. Без шулай дип җавап бирәбез: балаларын бакчага, мәктәпкә бирергә теләгән ата-ана андагы вәзгыятьне карарга тиеш. Хәләл туклану мәсьәләсен хәл итүдә, ата-аналар комитеты әгъзаларының балалар бакчасы мөдиренә, хәләл туклануны булдыруны сорап гариза язулары кирәк. Имзалар никадәр күп булса, шулкадәр яхшырак, билгеле. Әйтик, әгәр сез балагызны балалар бакчасына биргәндә, бары тик үзегез генә туклануның хәләл булуын телисез икән, моны үз көчегез белән генә булдыру четерекле мәсьәлә булып кала. Шуңа күрә, никадәр күбрәк ата-аналар бу сорауны күтәреп чыгып: «Әйдәгез әле, моны бергәләп хәл итик», – дип тотынса, балалар бакчасы мөдиренә мөрәҗәгать итеп, имзалар җыйса, шулкадәр җиңелрәк һәм хәерлерәк булачак. Һәм шул мөрәҗәгать нигезендә, балалар бакчасы мөдире Мәгариф идарәсенә чыгарга, «Безнең шәһәрнең яки муниципалитетның балалар бакчасына хәләл ризыкларны булдыруыгызны үтенәбез», – дип гариза язарга һәм монда ата-аналарның имзаларын куярга тиеш. Мәгариф идарәсе: «Әлеге балалар бакчасында хәләл ризык булдыруыгызны сорыйбыз», – дип, Департаментка мөрәҗәгать итә. Әлеге хат Мәгариф министрлыгына да җибәрелсә яхшы булыр.

Шунысы кызганыч: һәрбер балалар бакчасына, мәктәпкә дә хәләл ризык килми.

«Азык-төлек һәм социаль туклану департаменты»нда бөтен эшләр тендер юлы белән башкарыла. Мәсәлән, авыл-хуҗалыгында эш алып бара торган фермерлар, ит комбинатлары тәкъдим иткән бәяләр арасыннан

Департамент иң арзан дигәнен сайлап ала. Һәм шул азык-төлек – балалар бакчаларына, мәктәпләргә җибәрелә.

Ярымфабрикатларның ясалу рәвешен дә карап үтик. Әйтик, бездән таныклык алган чимал җитештерү оешмасы, үзләренең продукциясе белән Департаментка килә. Департаменттан безгә – Хәләл комитетына шалтыратып, иртәгә чималны эшкәртәчәкбез, дип хәбәр итәләр. Безнең намаз укый торган мөселман технологыбыз анда барып, бөтен тәртипне: чисталыкны, өстәлләрне, җиһазларны карап, тикшереп, килгән чималны эшкәртә башларга рөхсәт бирә. Мәсәлән, сөяктән аерылган, туңдырылган рәвештә сыер ите китерелә, аны яңадан эретеп ярымфабрикатлар: фарш, гуляш өчен әзерлекләр ясыйлар. Һәм аларны Хәләл комитеты тамгасы куелган пакетларга тутырып, мәктәпләргә, балалар бакчаларына җибәрәләр.

## «Бисмилләһи Аллаһү әкбәр», – дип чалынуы мөһим

– «Безнең балалар бакчасында, мәктәпләрдә хәләлме икән?» – дигән сорауны безгә еш бирәләр. Әлеге сорауга без бу рәвешле җавап бирәбез: «Хөрмәтле әти-әниләр, әби-бабайлар, балаларыгыз, оныкларыгыз йөргән мәктәпләргә, балалар бакчаларына барыгыз. Андагы ашханәнең мөдире, пешекчесе белән күрешеп, сөйләшеп, минем балам бу мәктәпкә яки балалар бакчасына йөри. Монда дөрестән дә хәләлме икән?» – дип сорагыз, белешегез дип әйтәбез. Әгәр алар: «Әйе, дөрестән дә менә безгә «Азык-төлек һәм социаль туклану департаменты»ннан «Хәләл» тамгасы булган ризыклар килә», – дип әйтсәләр, ата-аналар тынычланып кала.

Безгә бик күп мөрәҗәгатьләр килеп тора: «Хәзрәт, безнең балалар бакчасында, мәктәптә дә хәләл туклану булса иде», – дип сорыйлар. Ләкин чимал җитми, продукция тендер юлы белән алына. Хәләл комитеты буларак, без үзебезнең фермерларыбызны, шул чималны җитештерүчеләрне тәкъдим итәбез, ләкин алар билгеле бер бәя кысаларына керә алмый.

Шул сәбәпле, иң беренче чиратта, татар компоненты булган балалар бакчасына, мәктәпләргә һәм гимназияләргә генә хәләл ярымфабрикатлар китерелә.

Шуны әйтергә кирәк: Департамент әзерләгән ризыкларда дуңгыз һәм сарык ите юк, чөнки балаларның рационында дуңгыз һәм сарык ите авыр ризык булып санала. Шуңа күрә сыер йә тавык итләре генә китерелә. Әмма, белүебезчә, аларны да карарга кирәк. Мәсәлән, сыер ите дә, тавык ите дә «Бисмилләһи Аллаһү әкбәр», – дип чалынмаса, харам була. Без әлеге мәсьәләләргә карата игътибарлы булырга тиеш.

## Халык хәләл турында аз белә

**– Хәзрәт, тагын шундый сорауга да җавап бирсәгез иде: ризык хәләл булсын өчен, нинди шартлар үтәлергә тиеш?**

– Кызганычка, халык хәләл белән бәйле булган мәсьәләләрне бик аз белә. Шуңа күрә дә, без – хәзрәтләр төрле очрашуларда хәләл турында сөйләргә тырышабыз. Мәсәлән, Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгалә Коръәни Кәримнең «Әл-Маидә» сүрәсендә безгә биш әйберне харам кылганлыгы турында әйтә.

**Беренчесе:** безгә үләксә итен ашау харам кылынган. Мәсәлән, сыер, тавык, үрдәк – нинди хайван булса да, үз үлеме белән яки егылып төшү аркасында үлгән икән, яки ток белән бәреп үтерелгән икән, бу хайваннарның ите үләксә була һәм аны ашау катгый рәвештә тыелган.

**Икенчесе:** Раббыбыз безгә кан ашауны, кан белән бәйле ризыкларны харам кылды. Әйтик, балаларга кечкенә вакытларында әниләр, дәү әниләр гематоген бирәләр иде. Гематоген үгез каныннан ясала. Шуңа күрә, ул харам булып санала. Әгәр дә без балаларыбызның намаз, Коръән укырга өйрәнүләрен, догалар белүләрен, дөрес фикер йөртүләрен телибез икән, аларны бары тик хәләл булган ризыклар белән тукландырырга кирәк.

**Өченчесе:** Раббыбыз безгә, дуңгыз итен һәм аның белән бәйле булган ризыкларны харам кылды. Дуңгызның ите, тиресе нәҗес булып санала. Әгәр дә бу хайванга карасак, кызыклы фактка тап булабыз: башка хайваннар тирләгән вакытта, аларның 90% тирләре бүленеп чыгып, 10%ы организмында кала. Ә менә дуңгызда бу процесс киресенчә: аның 90% тире тәнендә кала, бары тик 10 %ы гына бүленеп чыга. Һәм шул тирләү процессы яхшы узсын өчен, ул үзенең пычракларында ауный. Хикмәт буларак бары тик бер хайван: дуңгыз гына әлеге үзенчәлеккә ия. Димәк, аның барлык зарарлы матдәләре, пычраклары тәнендә кала. Бу итне ашаган кешеләрнең үзләренә күпме зыян салуын күз алдына китерик.

**Дүртенчесе:** Раббыбыз безгә Аллаһы Тәгалә исеме белән чалынмаган хайваннарның итләрен харам кылды. Әлбәттә безгә сыер ите дә, каз ите дә, тавык ите дә, дөя ите дә ашарга ярый. Әмма әгәр бу хайваннар «Бисмилләһи Аллаһү әкбәр» дигән сүзләр белән, мөселман кешесе тарафыннан, үткен пычак ярдәмендә чалынмаса – бу ит безгә харам була. Бүгенге көндә без – хәзрәтләр, мәҗлесләргә барган вакытта, күп очракта, бу ит хәләлме, дип сорыйбыз. Безгә апалар, әбиләр: «Без бу итне авылдан алып килдек», – дип әйтәләр. Әмма шунысын белик: авылдан алып килгән һәр ит тә хәләл дигән сүз түгел. Аны кем чалган? «Бисмилләһи, Аллаһү әкбәр», – дигән сүзләрне әйткәнме? Кулындагы пычагы үткен булганмы? Боларның барысы да мөһим. Әгәр, дөрестән дә, бу тәртипләр үтәлгән булса, тыныч күңел белән, әйе, бу ит хәләл дип, әйтә алабыз.

Кызганычка, бүгенге вакытта җитештерүчеләр тарафыннан бик күп алдаулар була. Кайбер апалар мондый очракларда: «Хәләл булмаса, гөнаһысы саткан кешегә булыр, безгә булмас», – дип әйтә. Әмма бу ялгыш фикер. Әлбәттә, алдаган кешегә гөнаһысы булыр. Әмма бу харамны ашаган кешенең 40 көн буена кылган догасы кабул булмас.

Димәк, әгәр хайванны чалу рәвеше харам рәвештә башкарылса, бу ит хәләл була алмый. Әгәр мөселман кешесе хәмер эчеп хайванны чалса,

бу ит харам була. Шулай ук «Бисмилләһи, Аллаһү әкбәр» сүзләрен тавыш белән әйтмәсә дә, бу ит харам була. Боларны белү мөһим.

Без һәрдаим шуны күңелебездә тотарга тиешбез: без беркөнне бу дөньяга килдек, ике тамчы судан барлыкка китерелгән идек һәм билгеле бер көн җиткәч, бу дөньядан китәчәкбез.

**Бишенчесе:** Раббыбыз безгә ерткыч хайваннарның һәм кошларның итен харам кылды. Мәсәлән, аю, бүре, төлке кебек хайваннарның, бөркет кебек үткен тырнаклы кошларның итләре безгә харам булып тора.

Мәсәлән, аучылар ауга барып, аюны, бүрене, төлкене үтереп, шул хайваннарның итләрен ашаса, молекуляр дәрәҗәдә шул хайванга әвереләләр, ягъни үзләре дә ерткыч кебек булалар. Әгәр дә кеше дуңгыз итен ашаган булса, ул молекуляр дәрәҗәдә аңа әверелә. Югарыда Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең хәдисен искә алган идек. Пәйгамбәребез: «Әгәр кеше белеп, харам ризыкны ашаган булса, Аллаһы Тәгалә 40 көн дәвамында аның кылган догасын кабул кылмый», – дип әйткән. Бу – намаз укучыларга, ураза тотучыларга, изге гамәл кылучыларга аяныч хәл һәм без бу мәсьәләгә бик җитди карарга, ашаган ризыгыбызга бик игътибарлы булырга тиешбез. Димәк, без нәрсә ашыйбыз – шуңа әвереләбез.

## لذيذ «Ләẓиẓ» хәләл дигән сүз түгел

Хәләл лайфстайл, хәләл тормыш рәвеше, дип сөйлибез. Мәсәлән, иртән торып суыткычыбызны ачуга, андагы ризыкның хәләл булуы тиешле. Шул ук сырларның составында «сычужный фермент (сычуг) животного происхождения» дигән язу булып, анда «Хәләл» тамгасы тормаса, әлеге сыр харам санала. Әгәр инде сырда «фермент (сычуг) микробного происхождения» дип язылган булса, димәк, хәләл. Боларны белү мөһим. Казылыклар белән дә шулай ук. Аларны сайлаганда да игътибарлы булу кирәк. Казылыкның тышлыгында «мөселманча» яки «ләẓиẓ», дип языл-

ган тамгалар яисә анда ай рәсеме, манара рәсеме куелу аның хәләл булуын аңлатмый. Бары тик «Хәләл» тамгасы булган очракта гына казылыкны шикләнмичә алырга мөмкин.

## Харам ризыкны ташларга ярый

Кайбер әбиләр: «Хәзрәт, менә мин намаз укыйм, әмма белмичә кибеттән харам булган казылыкны сатып алып кайтканмын. Аны нишләтергә инде?» – дип сорыйлар. Һәм кайберләре: «Хәзрәт, менә ялларда оныкларым кайталар, аларга бирәм инде, намаз укыгач, миңа харам ризык ашарга ярамый», – дип, бик тә ялгыш фикер йөртәләр. Бу – бигрәк тә зур хата. Кеше үзе намаз укыгач, балаларының, оныкларының да намаз укуын теләргә тиеш. «Ул балалар намаз укымый, димәк аларга ашатырга ярый. Ташлаганчы, аларга ашатабыз», – дип әйтү – ялгыш фикер. Әмма шуны белик: бу ризык харам һәм аны ташларга ярый, ә башка кешегә бирү катгый рәвештә тыелган гамәл. Бу ризыкны йә ташларга, йә, берәр хайван алып китәр әле, дип, кеше күрми торган җиргә куярга кирәк. Хәтта ул харам ризыкны йорт хайваннарыбызга да ашатырга хакыбыз юк. Бары, безгә харам булган ерткыч хайваннарга гына бирә алабыз.

Кызганычка, шундый хәлләрне дә ишетергә була. Бер әби килеп: «Хәзрәт, менә мин базардан арзанга гына тавык ите алган идем, әмма ул хәләл түгел иде. Мин өйгә кайттым да өч тапкыр, «Бисмилләһи», – дип, пычак белән шул тавыкны кисеп алдым. Болай эшләсәм, хәләл буламы?» – дип сорыйлар. Без бу очракта: «Бу ит хәләл була алмый, ул – харам. Әлеге ит хәләл булсын өчен, ул тавыкны «Бисмилләһи, Аллаһү Әкбәр», – дип чалулары кирәк иде», – дип җавап бирәбез.

## Хәләллек ризыкка гына кагылмый

Кайвакытта бездән алкогольсез сыралар хакында сорыйлар. Кызганычка, кайбер «псевдохәләл» оешмаларның сыраны хәләл дип әйтүләре дә булды. Шуңа алданып, кешеләр анда алкоголь 0% дип тора, димәк, эчәргә ярый, диләр. Беренчедән, алкоголь бөтенләй юк, дип язсалар да, анда барыбер күпмедер күләмдә ул булачак. Икенчедән, гореф-гадәтебез буенча, бу бер дә матур күренеш түгел. Күз алдына китерегез, әгәр берәр хәзрәтнең кулында мондый сыра күрсәгез, кайсыгызның аны үз өенә ашка чакырасы килер икән? Яки кайсыгыз аның артына басып намаз укырга теләр?

Хәләл ризыкка гына кагылмый. Хәләл – ул бөтен тормышыбыз, яшәү рәвешебез. Хәтта яшьләр никахлашканда да, алардан хәләл җефетлеккә риза булып бардыңмы, риза булып алдыңмы, дип сорала.

## Харам ашасак, догабыз кабул булырмы?

Хәләл белән генә тукланып яшәү мөһим, чөнки бу соңгы сулышларыбызның нинди булуына да бәйле. Кайвакытта безгә шалтыратып: «Хәзрәт, менә ашыгыч ярдәм машинасы килеп китте, якыныбызга берни белән дә ярдәм итә алмыйбыз, килегез», – диләр. Килсәк, үлем түшәгендә ятучы кеше йортым, машинам, акчаларым кемгә кала дип, җан бирә алмыйча ята.

Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Ләә иләәһә илләллаһ Мүхәммәдүр-расүлуллаһ» сүзләрен әйтүче җәннәткә керер», – дип әйткән. Без, йортыбызга кергәндә, аны ачкыч белән ачып керәбез. Машинага утыргач, кузгалып китәр өчен, ачкыч кирәк. Нәкъ шулай ук җәннәтнең һәм гүрнең дә үз ачкычы бар. Ул «Ләә иләәһә илләллаһ Мүхәммәдүр-расүлуллаһ» сүзләре.

Соңгы сулышларыбызда әлеге сүзләр булуын телибез икән, ул вакытта безнең ризыгыбыз, киемебез, әйткән сүзләребез хәләл булырга тиеш. Расүлебез бер хәдисендә болай дигән: «Бер кеше чүлдә кулларын күтәреп «Йә Рабби, йә Рабби», – дип дога кыла, Аллаһыга ялвара, әмма аның догасы кабул булмый, чөнки ашаган ризыгы – харам, кигән кием – харам. Ничек Аллаһы Тәгалә аның догасын кабул итсен?» Әгәр без Аллаһының рәхмәтенә, бәрәкәтенә ирешергә телибез икән, ризыгыбыз да, гамәлләребез дә, фикерләребез дә, сүзләребез дә хәләл булырга тиеш, иншәАллаһ.

Вә салләллаһу галәйһи сәййидинә Мөхәммәдин вә галә әәли әсхаабиһи вә әҗмәгыйн. Вә әлхәмдүлилләһи раббил галәмиин.

**– Ирек хәзрәт, файдалы һәм бик актуаль әңгәмәгез өчен, Аллаһының рәхмәте булсын. Сезгә эшегездә уңышлар телибез. Аллаһы Тәгалә башкарган хезмәтегездән риза булып, ике дөнья бәхетенә ирешүегезне насыйп кылсын.**

*Әңгәмәне Айсылу Юлдашева оештырды*

# Үрнәк затлар

# Сәгъд бине Әби Вәккас радыяллаһу ганһе

## Тууы

Сәгъд бине Әби Вәккас радыяллаһу ганһе якынча 595 елда Мәккә шәһәрендә, Әбү Вәккас Мәлик гаиләсендә дөньяга килгән. Җәннәт белән шатландырылган ун сәхабәнең берсе.

## Тулы исеме

Сәгъд бине Әби Вәккас Мәлик бине Вукайб бине Габдеманәф бине Зәһра.

## Нәселе

Сәгъд бине Әби Вәккас радыяллаһу ганһе Мәккәнең мәшһүр гаиләсендә туган. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм белән дә аны туганлык җепләре бәйләгән. Әйткәнебезчә, аның әтисе – Әбү Вәккас, ләкин бу аның куньясе (кушаматы) гына. Аның чын исеме – Мәлик бине Вәһиб бине Габдеманәф бине Зәһра бине Киләб. Аның шәҗәрәсе Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең шәҗәрәсендәге Киләб нәселенә барып тоташа. Пәйгамбәребезнең әнисе Әминә бинте Вәһеб чыгышы белән Бәну Зәһра нәселеннән. Шул рәвешле, Сәгъд бине Әби Вәккас радыяллаһу ганһе – Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең әнисе Әминәнең ике туган абыйсы, ә Пәйгәмбәребезгә әнисе ягыннан абзасы килеп чыга.

Җәбир бине Габдулла радыяллаһу ганһедән китерелгән риваятьтә әйтелә: Сәгъд бине Әби Вәккас кергән чагында, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм горурлык белән: «Ул – минем әнием ягыннан ту-

ганым һәм тагын кайсыгыз Сәгъд кебек абзасы белән горурлана ала?» – дип әйтә торган булган.

## Ислам динен кабул итүе

Сәгъд бине Әби Вәккас радыяллаһу ганһе ислам динен 19 яшендә (ә кайбер чыганакларда 17 яшьтә) кабул иткән. Бу – Ислам диненең яңа гына тарала башлаган вакыты, шуңа да динне кабул иткән мөселманнар саны бик аз булган. Шунлыктан, аларны һәр җирдә киртәләр, авыр сынаулар сагалаган.

Сәгъд бине Әби Вәккас радыяллаһу ганһенең кызы Гайшә, әтисенең сөйләүләре буенча, аның Ислам динен кабул итүе хакында түбәндәгеләрне риваять кылган.

Бервакыт Сәгъд бине Әби Вәккас радыяллаһу ганһе могҗизалы төш күргән. Әйтерсең лә, ул бер караңгы бүлмәдә икән һәм анда бернинди дә яктылык кермәгән. Көтмәгәндә каяндыр бик якты ай нуры барлыкка килгән һәм Сәгъд бине Әби Вәккас шул ай яктылыгына таба атлый башлаган. Шул чагында ул үзеннән алда айга таба баручы кешеләрне күргән. Алар арасында Әбү Бәкер Әс-Сиддыйк, Гали, Зәйд бине Харрис радыяллаһу ганһүмәләр булган. Белүебезчә, хатын-кызлар арасында беренче булып Ислам динен Хәдичә радыяллаһу ганһә, балалар арасында – Гали, аннан соң, ирекле булган кешеләрдән – Әбү Бәкер радыяллаһу ганһе, ә коллар арасында Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең тәрбиясендә үскән Зәйд бине Харрис булган. Сәгъд бине Әби Вәккас алардан кая барулары хакында сораштыргач, алар Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең килүе һәм кешеләрне ислам диненә чакыруы турында әйткәннәр. Алар аны да Ислам динен кабул итәргә һәм үзләре артыннан барырга чакырганнар.

Икенче көнне Сәгъд бине Әби Вәккас Әбү Бәкер радыяллаһу ганһене күргән. Әбү Бәкер радыяллаһу ганһе аны мөселманнарның яшерен җыела

торган урыннарына – Әркамә йортына килергә чакырган. Монда Сәгъд бине Әби Вәккас радыяллаһу ганһе пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм белән очрашкан һәм ислам динен кабул иткән.

Сәгъд бине Әби Вәккас ислам динен кабул иткәч, тормышы авырлаша. Бигрәк тә якын туганнары моңа каршы булганнар. Улының ислам динен кабул итүе хакында белгән әнисе аңа бик нык ачуланган. Яраткан улының бу гамәлен нәселләренә хыянәт итү дип санаган һәм ризасызлыгын белдереп болай дип әйткән: «Әгәр дә син яңа динеңне ташламасаң, мин үлгәнче үземә ашау-эчүне харам кылам. Син үкенечкә калып кешеләр алдында хур булырсың». Улы әнисенә: «Әнием, болай эшләмә, мин барыбер үз динемнән ваз кичмәм», – дип әйтсә дә, әнисе үз сүзләрендә нык торган. Берничә көн дәвамында ул бернәрсә дә ашамаган һәм эчмәгән, бик нык хәлсезләнгән. Улы Сәгъд аны күпме юатырга тырышса да, әнисе бу гамәленнән туктамаган, тыңламаган. Улы: «Ий әнием, сине күпме яратсам да, әмма Аллаһыга һәм Пәйгамбәрем салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә ратуым көчлерәк. Мин үз динемнән беркайчан да баш тартмам», – дип әйткән.

Әнисе улының үз карарында нык торганлыгын аңлап, улына карата йомшарган һәм тамагына ризык каба башлаган.

Сәгъд бине Әби Вәккас радыяллаһу ганһе Коръәни Кәримдәге «Локман» сүрәсенең түбәндәге аятьләре нәкъ менә аның очрагына бәйле һәм аның кебекләр хакында иңдерелгән дип әйтә торган булган.

وَوَصَّيْنَا الْإِنسَانَ بِوَالِدَيْهِ حَمَلَتْهُ أُمُّهُ وَهْنًا عَلَىٰ وَهْنٍ وَفِصَالُهُ فِي عَامَيْنِ
أَنِ اشْكُرْ لِي وَلِوَالِدَيْكَ إِلَيَّ الْمَصِيرُ ﴿١٤﴾ وَإِن جَاهَدَاكَ عَلَىٰ أَن تُشْرِكَ
بِي مَا لَيْسَ لَكَ بِهِ عِلْمٌ فَلَا تُطِعْهُمَا ۖ وَصَاحِبْهُمَا فِي الدُّنْيَا مَعْرُوفًا ۖ وَاتَّبِعْ
سَبِيلَ مَنْ أَنَابَ إِلَيَّ ۚ ثُمَّ إِلَيَّ مَرْجِعُكُمْ فَأُنَبِّئُكُم بِمَا كُنتُمْ تَعْمَلُونَ ﴿١٥﴾

**«Без кешегә ата-анасына игелек кылырга васыять иттек. Анасы аны зәгыйфьлек өстенә зәгыйфьлек белән йөрткән. Аны имүдән аеруы исә ике ел эчендә. Миңа ата-анаңа шөкер кыл, чөнки кайту – Миңа. Әмма ул икәү синең бернинди гыйлемең булмаган [потлар һәм гаҗиз] нәрсәләрне [күрә торып] Миңа ширек кылуың өчен сине көчли калсалар, аларга итагать итмә. Әмма дөньяда ул икәү белән яхшы күрелгән рәвештә бергә бул. Ләкин син [ата-анаңның юлына түгел, тәүхид һәм ихлас белән] Миңа юнәлгәннәрнең юлына ияр. Соңыннан [барыгызның да] кайтуыгыз Миңа [булачак], Мин исә сезгә ни кылганнарыгызны хәбәр итәчәкмен».**

«Локман», 31:14-15

## Төп сыйфатлары

Сәгъд бине Әби Вәккас радыяллаһу ганһе бик юмарт булуы белән аерылып торган. Тапкан барлык малын Аллаһы юлына тоткан. Бервакыт Сәгъд бине Әби Вәккас нык авыртып киткән. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм аның хәлен белешергә килгәч, ул болай дип әйткән: «Ий Аллаһының Расүле! Минем бердәнбер кызымнан кала башка балаларым юк, ләкин минем байлыгым шактый күп. Бар байлыгымны да Аллаһы юлына тотарга рөхсәт ит!» Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм аның бу теләгенә каршы килгән. Шуннан соң Сәгъд бине Әби Вәккас байлыгының яртысын садака буларак тарату мөмкилеге хакында сораган. Аллаһының Расүле моңа да ризалашмаган. Шуннан соң ул байлыгының $^1/_3$ өлеше хакында сораган. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм аңа болай дип әйткән: «$^1/_3$ өлеше дә күп әле. Үз варисларыңны ярлылыкта калдырганчы, байлыкта калдыруың хәерлерәк. Син шуны яхшы бел, әгәр син, Аллаһының ризалыгы өчен үз малыңнан нәрсә булса да тотсаң, хәтта

хатыныңа ризык өчен булса да, һичшиксез, син Аллаһыдан бу гамәлең өчен әҗерен алырсың». Ахырда өстәп болай дип тә әйткән: «Аллаһының рәхмәте белән син савыгырсың һәм мөэминнәргә – күп файда, ә Ислам диненә каршы булган дошманнарга зыян салырсың». Чыннан да, бу хәлләрдән соң Сәгъд бине Әби Вәккас радыяллаһу ганһе якынча тагын 40 ел яшәгән.

Шуны да искәртеп үтик, Сәгъд бине Әби Вәккасның бар байлыгы хәләл юл белән, үз тырышлыгы белән табылган. Нәкъ шул сыйфаты аңа җәннәт белән шатландырылучылар рәтенә керергә ярдәм дә иткән. Бервакыт Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм үзенең сәхабәләре белән утырган вакытта болай дип әйткән: «Җәннәтле кешене күрәсегез килсә, хәзер монда керүчегә карагыз». Барысы да бу бәхетле кешене күрергә теләгәннәр. Шул чагында Сәгъд бине Әби Вәккас радыяллаһу кергән. Ул чагында әле яшь булган Габдулла бине Гомәр үзеннән әллә ни аерылмаган Сәгъд бине Әби Вәккастан нинди сыйфатлары сәбәпле җәннәт белән шатландырылуы хакында сораган. Сәгъд бине Әби Вәккас радыяллаһу ганһе аңа болай дип җавап биргән: «Мин – гади кеше, үзенчәлекле эшләр дә башкармыйм, ләкин мин һәрвакытта да өч әйберне чисталыкта тотарга тырышам. Болар – минем телем, йөрәгем һәм байлыгым. Мин беркайчан да чит кешеләр хакында начар сүз сөйләмәдем, беркемгә дә явызлык теләмәдем һәм үземнең бар байлыгымны да бары тик хәләл юл белән генә тупладым».

Сәгъд бине Әби Вәккас бозыклыктан, гөнаһлы эшләрдән ерак торган. Яраткан шөгыльләре ук һәм җәя ясау булган. Шуңа да ул оста сугышчы һәм укчы булуы белән аерылып торган. Бәдер, Өхед, Хандакъ сугышларында катнашкан. Өхед сугышында Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмне яклаган ун сәхабә арасында булган. Җәядән атып, ул мөшрикләрнең һөҗүмнәренә каршы торган. Пәйгамбәребез саләллаһу галәйһи вә сәлләм аның шулай дошманнарга каршы оста каршы торган-

лыгын күреп, Сәгъд бине Әби Вәккас радыяллаһу ганһегә кулланылмаган укларны тапшырып болай дип әйткән: «Сәгъд, Аллаһы синнән разый булсын. Менә боларны ал да һәм алардан да ат». Сәгъд бине Әби Вәккас Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең сүзләренә каршы килмәгән. Үзенә бирелгән уклардан атып, бер-бер артлы дошманны юк иткән. Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм аңа мактау сүзләр белән болай дип әйткән: «Әй батыр егет, минем әти-әнием синең өчен фида булсыннар, угыңнан ат». Мондый сүзләрне пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм үз сәхабәләренең берсенә дә әйтмәгән.

Әбү Бәкер һәм Гомәр радыяллаһу ганһүмәләр идарә иткән вакытларда хәлифәтне ныгытуда зур хезмәтләр куйган. Рум һәм Иранга каршы гаскәр башлыгы булган. Аның җитәкчелегендә Кадисия сугышында җиңү яуланган.

Сәгъд бине Әби Вәккас радыяллаһу ганһенең тагын бер аермалы сыйфаты – аның барлык догалары да Аллаһы тарафыннан кабул ителүе.

Өхед сугышы алдыннан пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм, Аллаһы Тәгалә Сәгъд бине Әби Вәккасның догаларын кабул кылсын дип, Раббыбызга дога белән мөрәҗәгать иткән. Шуннан соң, Сәгъд бине Әби Вәккас кайчан гына Аллаһыга мөрәҗәгать итсә дә, Раббыбыз аның догаларын кабул кылган. Шуңа да сәхабәләр аны үпкәләтүдән бик курыкканнар. Бер мисал гына китереп үтик. Бервакыт, Сәгъд бине Әби Вәккас радыяллаһу ганһе Куфада башлык булган чагында, берәү аның янында Гали бине Әби Талиб радыяллаһу ганһене каһәрли башлаган. Сәгъд бине Әби Вәккас радыяллаһу ганһе ул кешегә: «Галигә сүз тидерәсе булма, юкса мин синең үзеңне каһәрләрмен», – дип әйткән. Ләкин теге бәндә каһәрләвеннән туктамаган. Шуннан соң Сәгъд бине Әби Вәккас радыяллаһу ганһе бу кешегә карата бәддога кылган. Озакламый

халык арасында, шәһәргә бер котырынган дөя кергән һәм ул Гали бине Әби Талибны каһәрләгән кешене таптап үтергән, дигән сүзләр таралган.

## Сәгъд бине Әби Вәккас – мөхәддис

Сәгъд бине Әби Вәккас радыяллаһу ганһе пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнән барлыгы 270 хәдис тапшырган. Ул Пәйгамбәребездән килгән хәдисләрне сөйләргә яраткан, ләкин Аллаһының Расүле хакында ышанычлы булмаган мәгълүматлар таралудан куркып, ул барлыгы 270 хәдис кенә тапшырган. Бервакыт Гомәр бине Әл-Хаттаб болай дип әйтеп тә куйган: «Әгәр Сәгъд бине Әби Вәккас берәр хәдис тапшырса, бшкалардан аның дөреслеге хакында сорарга да кирәк түгел».

## Вафаты

Сәгъд бине Әби Вәккас радыяллаһу ганһе 674 елда, 83 яшендә вафат булган. Үз васыяте буенча, Сәгъд бине Әби Вәккасны, Бәдер сугышында мөшрикләргә каршы сугышканда кигән йон җөббәсенә (ефәк яки ефәккә охшаган тукымадан тегелгән япма) төреп, Мәдинәдән 10 миль ераклыктагы бер җирлектә җирләгәннәр.

# «Нәрсә?
# Кайда?
# Кайчан?»

# ГЫЙНВАР

## Болгарда Диния нәзарәтнең «30/40» җыены узды

2-6 нчы гыйнвар көннәрендә Шәһре Болгарда узган «30/40» форумында Татарстан район һәм шәһәрләре, Казан, Мәскәү, Чиләбе, Екатеринбург, Кемерово өлкәсе һәм Мордовия Республикасыннан 60 кеше – 30-40 яшьлек мөселманнар, шулай ук гаиләле мөселман парлары да катнашты. Әлеге чараны үткәрүнең төп максаты – урта яшьтәге мөселманнарга рухи һәм физик камилләшү, дини белемнәрне арттыру өчен мөмкинлекләр тудыру.

## Татарстан мәчетләре халыкны «Син оныгың белән нинди телдә сөйләшәсең?» дигән язулар белән каршылый башлады

Җөмәдел-ахыр аеның 1 нче көнендә (14 нче гыйнварда), Нәзарәттә ТР Дәүләт Советы Рәисе урынбасары, ТР Президенты каршындагы Татар телен саклау һәм үстерү комиссиясе рәисе Марат Әхмәтов Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин белән очрашты. Мөхтәрәм кунаклар мәчетләр һәм имамнар өчен махсус бастырылган «Татарча әлифба» һәм татар телендә сәнгатьле чыгыш ясарга өйрәтә торган ярдәмлек китапларын, шулай ук саллы тиражда бастырылган милли үзаң тәрбияләүгә юнәлтелгән эчтәлекле плакатлар һәм истәлекле тамгалар тапшырды. Әлеге материалларны файдаланып, республика имамнары балалар арасында милли-дини үзаңны тәрбияләүгә юнәлтелгән чаралар уздыра, мәчетләр исә халыкны «Син оныгың белән нинди телдә сөйләшәсең?» дигән язулар белән каршылый.

## БИА ректоры вазифаларын башкаручы билгеләнде

Җөмәдәл-ахыр аеның 2 нче көнендә (15 нче гыйнварда), Болгар ислам академиясенең Гамәлгә куючылар советы утырышы узды. Киңәшмә академияне гамәлгә куючылар Советы рәисе, Татарстан мөфтие урынбасары Илфар хәзрәт Хәсәнов җитәкчелегендә һәм Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин катнашында узды. Көн тәртибендә төп сорау – Болгар ислам академиясе ректоры вазифаларын башкаручыны билгеләү мәсьәләсе каралды. Совет утырышында катнашучылар әлеге функцияләрне академиянең фәнни эшчәнлек буенча проректоры Айнур Тимерхановка тапшырдылар.

## Татарстан мөфтияте татар телендә беренче онлайн-мәдрәсә эшләтеп җибәрде

Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елы кысаларында, Татарстан мөфтияте һәм «Хозур» нәшрият йорты тиңе булмаган зур яңа проект – татар телендә беренче онлайн-мәдрәсә булдырды. Хәзер планетабызның төрле почмакларында яшәүче милләттәшләребезнең туган телдә Ислам нигезләре буенча гыйлем алу мөмкинлеге барлыкка килде. Моннан тыш, уникаль гыйлем мәйданчыгы Татарстанда ислам мәгарифенең беренче баскычын – мәчет каршындагы курсларны да сыйфат ягыннан яңа югары дәрәҗәгә күтәрде. Онлайн-мәдрәсә мәчетләре булмаган яисә мәчет каршындагы курслар оештырылмаган җирлекләрдә яшәүче татарларга яки вакыты кысынкы булган милләттәшләргә дини белем алырга ярдәм итәчәк.

## Татарстанда Мөселман яшьләре форумы узды

Шәһре Болгарда егетләр өчен, мәркәзебез Казанда кызлар өчен Мөселман яшьләре форумы узды. Җыенга 120 кеше килде. Алар «Нәфес һәм йөрәкнең рухи авырулары» темасына вәгазьләр тыңлады, остазлардан үгет-нәсыйхәтләр алды, хәрәкәтле уеннарда, квестта, төрле мастер-классларда катнашты. Әлеге форум яшьләргә белемнәрен ныгытырга гына түгел, шулай ук берләшергә, танышырга, рухи яктан баерга һәм үзләренең социаль башлангычларын тормышка ашырырга мөмкинлек бирә.

## Мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллин Татарстан Президенты белән очрашты

Җөмәдәл-ахыр аеның 13 нче көнендә (26 нчы гыйнварда), Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнеханов Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте рәисе, мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллин белән күреште. Очрашу Рөстәм Миңнехановның Татарстан Республикасы Хөкүмәте йортындагы эш кабинетында узды. Әңгәмә барышында быел һәм киләсе елларда уздырылачак чараларны, шул исәптән, 2022 елда Идел буе Болгар дәүләтендә ислам дине кабул ителүнең 1100 еллыгы һәм башка вакыйгаларны әзерләү һәм оештыру мәсьәләләре буенча фикер алышынды.

## Татарстан мөфтие мөселман яшьләре – I’MAN проектында катнашучылар белән очрашты

Җөмәдәл-ахыр аеның 15 нче көнендә (28 нче гыйнварда), Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин мөселман яшьләре вәкилләре – Нәзарәтнең I’MAN исемле ир-атлар проекты катнашучылары белән очрашты. Очрашу яшьләр белән даими рәвештә, бигрәк тә формаль бул-

маган шартларда аралашып тору кирәклеген раслады, ул яшьләрнең төрле караштa булуларына да карамастан, көндәлек тормышта барлыкка килә торган барлык кызыксындырган сорауларына җавап алырга мөмкинлек бирә.

# ФЕВРАЛЬ

## Ачык лекторийда хәләл ризык турында сөйләделәр

Җөмәдәл-ахыр аеның 28 нче көнендә (10 нчы февральдә), Казанда Диния нәзарәте яшьләр өчен чираттагы лекторий уздырды. Ачык дәрес хәләл ризык темасына багышланды. Татарстан мөфтиятенең «Хәләл» стандарты буенча комитеты белгечләре лекция укып кына калмады, катнашучыларның белемнәрен тикшерде, азык-төлек кибетләрендә мөселманнарга рөхсәт ителгән ризыкларны сайлап алу буенча киңәшләрен бирде, җәмәгать туклану урыннарында хәләл таләпләрнең үтәлеше буенча тикшерүләр үткәрү турында сөйләде.

## Нәзарәтнең Коръән мәгънәләре тәрҗемәләре мобиль кушымталар рәвешендә чыкты

Диния нәзарәтенең «Хозур» нәшрият йорты дин кардәшләребезнең күпсанлы үтенечләрен истә тотып, Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елы кысаларында «Калям Шариф. Перевод смыслов» һәм «Кәлам Шәриф. Мәгънәви тәрҗемә» басмаларын бушлай мобиль кушымта рәвешендә чыгарды. Димәк, теләгән һәркем басмаларны кесә телефонына бушлай күчереп алып, аны теләсә кайсы урында һәм вакытта укый ала! Мобиль кушымталар уңайлы интерфейста, күңелгә ятышлы дизайнда һәм аңлаешлы итеп эшләнгән.

## Татарстан мөфтияте хатын-кызлар өчен «Затлы мәҗлес» проектын башлап җибәрде

17 нче февральдә Казанның Галиев мәчетендә «Затлы мәҗлес»нең беренче очрашуы узды. Әлеге проектны ТР мөселманнары Диния нәзарәте мөслимәләр өчен төрле темаларга әңгәмәләр һәм фикер алышу мәйданчыгы буларак оештырды һәм аны дәвам иттерәчәк. Беренче кичәнең темасы «Йөрәк – ул савыт, аны Коръән белән тутыр» дип аталды. Казандагы «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе мөгаллиме, остаз Ландыш Ибраһимова Коръәнне өйрәнүнең мөһимлеге, һәр мөселман тормышында юл күрсәтүче Коръән турында сөйләде.

## Алабугада «Изге Коръән дөньясында» күргәзмәсе ачылды

Алабуга дәүләт музей-тыюлыгының Сирәк тупланмалар галереясендә Татарстан мөфтияте белән берлектә оештырылган Коръәннәр күргәзмәсе ачылды. Күргәзмә Татарстанда игълан ителгән Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елына багышлап, Идел буе Болгар дәүләте тарафыннан Ислам кабул итүнең 1100 еллыгына әзерлек уңаеннан оештырылды. «Изге Коръән дөньясында» күргәзмәсе төп ике шәхси коллекциядән тупланды – күпчелек Коръәннәр Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин һәм Коръәннең кулъязма вариантларын күчереп язучы, реставратор Дамир Әхмәтгалиев тарафыннан җыелды. Мондый күргәзмә Алабуга шәһәрендә беренче тапкыр оештырылды. Күргәзмәдә VII гасырдан алып XXI гасырга кадәр таралган Коръәннәрне һәм Коръән битләренең күчермәләрен күрергә мөмкин.

## Чирмешәндә төзекләндерүдән соң мәчет ачылды

Чирмешән районы Әмир авылында төзекләндерүдән соң мәчет ачылды. Күпләгән кунаклар, рәсми җитәкчеләр, дин әһелләре, иганәчеләр, мәхәллә халкы әлеге күркәм вакыйганың шаһитлары булдылар. Аларның куанычын Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин да уртаклашты. 1991 елда салынган мәчетне зурайту бурычы килеп баскач, авыл халкы белән киңәшләшеп, шул җирлектән чыккан иганәчеләр Фазыл һәм Миндар Әгъләмовлар изге эшкә алыналар – алар финанс ярдәме күрсәтеп, мәчетне фундаменттан ремонтлап, стеналарын, тышкы өлешен матурлап, түбәләрен яңадан ябып, манараны өстәп ясатып, эчләрен яңадан төзекләндереп, янкорма корып, бөтен тирә-янын яңартып чыгалар.

## «Динем – ислам, милләтем – татар» журналистлар бәйгесенә йомгак ясалды

Раҗәб аеның 13 нче көнендә (25 нче февральдә), Галиев мәчетендә Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте тарафыннан журналистлар өчен махсус игълан ителгән «Динем – ислам, милләтем – татар» дип исемләнгән иҗади эшләр бәйгесенә нәтиҗәләр ясау тантанасы үтте. Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин җыелган журналистлар белән аралашты, сорауларына җавап бирде һәм җиңүчеләрне бүләкләде. Очрашуда тагын бер күркәм традиция башлап җибәрелде – озак еллар дәвамында Ислам дине кыйммәтләрен киң катлам халык арасында тарату белән шөгыльләнүче берничә журналистка Диния Нәзарәтенең «Бердәмлек» медале тапшырылды.

## Мөселман яшьләре «Чиста мәчет» акциясен башлап җибәрде

Татарстан Республикасы мөселманнары Дания нәзарәте волонтерлары «Чиста мәчет» акциясе кысаларында Рамазан ае алдыннан республика мәчетләрендә җыештыру-чистарту эшләренә кереште.

## «Мөхәммәдия»дә Габделхак хәзрәт Каюмовны искә алдылар

Раҗәб аеның 16 нчы көнендә (28 нче февральдә), «Мөхәммәдия» мәдрәсәсенең кичке бүлегендә белем алучы шәкертләр тарафыннан Габделхак хәзрәт Каюмовны искә алу кичәсе үткәрелде. Очрашуда хәзрәтнең шәкертләре, туганнары, балалары, оныклары катнашты. Оештыручылар тарафыннан яшь буын остазларыбызны, укытучыларны белсеннәр, мирасны онытмасыннар, дигән максат куелды. Быел Габделхак хәзрәт Каюмовның (1921-1999) тууына 2 нче март көнне 100 ел тулды. Ул мөселман мәгарифе өлкәсенә зур өлеш керткән шәхесләребезнең берсе иде. Габделхак хәзрәт 1965 елда ук төркем җыеп, ислам нигезләрен өйрәтә башлый. Анда белем алучыларның күбесе танылган имамнар, дин әһелләре булып китәләр.

## Мөфтият Коми, Ульяновск һәм Саранскида яшәүче милләттәшләргә Коръәннең татар телле мәгънәви тәрҗемәләрен бүләк итте

Үткән айларда Дания нәзарәте Коръәннең татар телендәге «Кәлам Шәриф. Мәгънәви тәрҗемә» басмаларын тапшыруны дәвам итте. Бу юлы кадерле басма Коми Республикасы мөселманнары Дания нәзарәтенә юлланды, шулай ук Саранск шәһәренә (Мордовия Республикасы Халыклар йортына) һәм Ульяновскида мөселманнарга җибәрелде. Соңгы

ике шәһәрдә китаплар Татарстанның баш казые Җәлил хәзрәт Фазлыев һәм Казанның Ислам динен кабул итүгә 1000 ел исемендәге мәдрәсәсе җитәкчесе Ильяс хәзрәт Җиһаншин тарафыннан җәмәгатьчелеккә тәкъдим ителде һәм милли-дини үзаң турында вәгазьләр сөйләнде, әңгәмәләр үткәрелде. Моңарчы китаплар Чувашия Educational Диния нәзарәтенә, Пенза өлкәсе мөселманнары Диния нәзарәтенә һәм Рәсәйнең башка 15 мөфтиятенә һәм татар милли оешмаларына җибәрелгән иде.

# МАРТ

## Нурлат мөхтәсибәте мохтаҗларны бушлай ашата башлады

Нурлат мөхтәсибәтендә диненә һәм милләтенә карамастан, авыр тормыш хәлендә булган мохтаҗларга ярдәм итәләр. Һәр көнне иртәнге сәгать 11дән көндезге икегә кадәр ланч-боксларга салынган кайнар ризыкны 30-40 кешегә өләшәләр. Ашамлыкларны, итне садакага җыелган акчага сатып алалар. Нурлат мөхтәсибәте район хакимияте һәм социаль хезмәткәрләр белән бергәлектә эшли.

## «Хузур ТВ» Рәсәйдә беренче тапкыр «Хәлид бин Вәлид» сериалын күрсәтә башлады

2 нче марттан, Рәсәйдә беренче тапкыр зәңгәр экраннарга «Хәлид бин Вәлид» сериалы чыкты. Ул пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең җиңелмәс гаскәр башлыгы һәм сәхабәсе турында. Кинокартинаны Татарстан мөфтиятенең «Хузур ТВ» телеканалы трансляцияли. Рәсәйнең беренче мөселман телевидениесе аны рус теленә тәрҗемә итте, актерларның сөйләмен тавышландырып, «Әл-Маха» (Күвәйт) халыкара компаниясеннән сериалны тарату өчен рөхсәт алып, эфирга әзерләде.

## Казанда «Яшь килен» проектының яңа сезоны ачылды

11 нче марттан Казанда мөселман яшьләре арасында зур популярлык казанган «Яшь килен» проектының яңа дүртенче сезоны үз эшен башлап җибәрде. Бу проект яшь мөслимәләрне сөекле хәләл җефет, кадерле әни һәм күркәм килен булу, бәхетле татар-мөселман гаиләсе төзү серләренә, татар халкының иң матур гаилә традицияләренә өйрәтүе белән үзенчәлекле.

Быел ул Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елы кысаларында милли яктан баетылды. Кияүдәге һәм кияүдә булмаган яшь мөслимәләр өчен булдырылган бу мәйданчыкта катнашырга Казаннан гына түгел, Рәсәйнең башка төбәкләре һәм районнарында яшәүче гүзәл затлар да теләк белдерде. Шуңа күрә проект оффлайнда гына түгел, онлайн форматта да үткәрелде.

## Казанда Бөтенрәсәй фәнни-методик семинар узды

11-13 нче мартта Казанда «Мәгариф өлкәсендә яңа РФ законнары таләпләре нигезендә югары уку йортында белем бирү процессын оештыру» дигән Бөтенрәсәй фәнни-методик семинар үтте. Фәнни-методик семинарны Фәнни белем бирү теология ассоциациясе (НОТА) Мәгариф һәм фән өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәт белән бергәлектә оештырды. Семинарны оештыруда быел Рәсәй Федерациясенең Ислам мәгарифе буенча советы да катнашты. Әлеге чарада Рәсәйнең барлык төбәкләреннән ректорлар, проректорлар, теология кафедралары мөдирләре, белем бирү программалары җитәкчеләре, Теология юнәлеше

буенча белем бирү программалары җитәкчеләре, югары белем бирү оешмалары белгечләре катнашты.

## Нәзарәт тарихта беренче тапкыр «Зөбдәтел-Бохари» («Зубдатуль-Бухари») җыентыгын русчага тәрҗемә итте

Шәгъбан аеның 14 нче көнендә (27 нче мартта) Махачкалада Татарстан һәм Дагыстан мөфтиятләре бергә әзерләгән яңа саллы фәнни хезмәт тәкъдим ителде. Җәмәгатьчелекне XIX гасырда яшәгән галим Гомәр Дияветдин Әд-Дагыстаниның «Сахих Әл-Бохари» хәдисләр җыентыгы нигезендә төзегән «Зөбдәтел Бохари» хезмәтенең русчага тәрҗемәсе белән таныштырдылар. Моңарчы әлеге китапның рус теленә тәрҗемә ителгәне булмады.

## Мөхтәсибәтләрдә Туган тел елы уңаеннан төрле чаралар уздырыла

Татарстан Республикасында игълан ителгән Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елы кысаларында мөхтәсибәтләр балалар, яшүсмерләр өчен бәйгеләр, викториналар, интеллектуаль уеннар, спорт ярышлары уздыра. Мисал өчен, Бөгелмәнең «Подлесный» бистәсе мәчетендә «Туган тел көне» дип исемләнгән балалар бәйрәме узды. Кукмара мәдрәсәсендә татар теле елына багышланган викторина үтте. Чистай шәһәренең мәчет каршындагы курсларда белем алучылар өчен «Камалия» ял һәм үсеш үзәге коллективы тарафыннан балалар өчен «Милләтеңне сакла» дип исемләнгән мавыктыргыч күңел ачу программасы үткәрелде. Туган телебезне, милли традицияләрне, гореф-гадәтләрне саклауга багышланган чаралар ел дәвамында башка мөхтәсибәтләрдә дә киң колач алачак.

# Тарих

# Төркиядәге «Әфәнде Күпере» татар авылының барлыкка килүе



**Төркиядә татар авылының барлыкка килү тарихы**

Татарларның Төркиягә күченеп китүе язучы Мәхмүд Галәүнең (1886-1937) (чын исеме Мәхмүд Галәветдин улы Мәрҗани) «Мөһаҗирләр» («Переселенцы») романында җентекләп тасвирланган. Роман 1933 елда язылган булган. Аның нигезен күченеп китеп, Төркия авылында нигезләнгән Сафа Миңлебайның сөйләгәннәре тәшкил итә. Күченеп киткәннән соң, яңа урында аның хатыны Сәҗидә вафат була. Моннан соң ул икенче хатыны артыннан кабат туган авылына кайта. Тормыш иптәше йөкле булганга күрә, аны үзе белән алып китә алмый.

«Әфәнде Күпере» («Эфенди Кёпрюсю») авылы кешеләре әби-бабалары күченеп киткән авылларның исемнәрен саклап калганнар. Бу Сарабиккулово (Сарабиккул) авылының икенче исеме Эби (Әби), Шугурово (Шөгер), Каркали (Керкәле), Старый Иштеряк (Иске Иштирәк), Новый Иштеряк (Яңа Иштирәк), Куакбаш, Каратай, Карабаш, Яхшы Каран һ.б. Аларның барысы да диярлек 1920 елларга кадәр Самара губернасының

Бөгелмә өязенә һәм Уфа губернасының Минзәлә өязенә кергән була. Хәзер алар Татарстан Республикасының Лениногорск, Бөгелмә, Сарман районнарына керә.

Татарларның Төркиягә күчеп китүләре император Александр III нең (идарә итү еллары 1881-1894) Идел буе һәм Урал мөселманнарына карата кырыс сәясәт алып баруы белән бәйле. Ул идарә иткән чорларда мөселманнарга каршы барган эшчәнлек һәм миссионерлар ярдәме белән татарларны христианлаштыру омтылышы көчәйгән. Татарлар арасында актив эшчәнлекне Николай Ильминский (1822-1891) һәм Евфимий Малов (1835-1918) алып барган.

Иң беренче император Николай II (идарә итү еллары 1894-1917) шушы ук сәясәт буенча эш итә. 1897 елда Рәсәй хакимияте тарафыннан Рәсәй тарихында беренче тапкыр халык санын алу оештырыла. Татарлар арасында бу хәбәр борчылуларга китерә. Халык арасында, бу эшләрнең максаты: мөселманнарның исәбен белү, ә аннары аларны чукындырырга теләүләре аркасында оештырыла, дигән сүзләр тарала. Идел буе авылларының күпчелегендә бунтлар һәм буйсынмау очраклары кабынып китә.

Кайбер авылларда халык санын язарга дип килүчеләрне кыйнап, куып җибәрү очраклары да булган. Төп проблема шунда була: хакимияттәгеләр тарафыннан мөселманнарга халык санын алу максатлары хакында сөйләнми. Бу бик күп имеш-мимешләр барлыкка килеп, бунт кузгалуга китерә. Хәтта моннан соң да хакимияттәгеләр халыкны тынычландырырга ашыкмый, ә хәрби көчләрне күрсәтергә булалар. Халык санын алуда катнашырга теләмәгән авылларга казаклар һәм жандармнар җибәрелә һәм авылларда яшәүчеләр җәзага тартыла.

Иң кайнар киеренкелек учакларының берсе Бөгелмә өязенең татар авылларында була. Бирегә казаклар һәм жандармнар килә. Һәм кешеләрдән берәм-берәм сорау алулар оештырыла. Тәртипсезлекләрдә

гаепле дип табылганнарны богаулар белән суд тикшерүе өчен Казанга җибәрәләр. Аларның кайберләре җәзага тартыла, ә калганнары Себергә каторга эшләренә сөрелә.

Авылларда яшәп калучылар да авырлыкларга дучар ителә: аларны баганаларга бәйләп куеп, кыйный торган булалар. Әмма жандармнар һәм казаклар халыкны бу рәвешле җәзалау белән генә канәгатьләнми. Алар йорт хайваннарын: сыерларны, сарыкларны, кәҗәләрне һәм кошкортны тартып ала башлый. Малның бер өлеше белән берничә ай шушы авылларда яшәгәндә туклансалар, калган өлешен үзләре белән алып китәләр. Бу хәлләр күпчелек татарларны Госманлы империясендә сыену урыны эзләргә мәҗбүр итә. Шул рәвешле, 1898 елда качып китүчеләр Госманлы империясенә килеп, анда «Әфәнде Күпере» исемле авылга нигез сала.

# Хәбибрахман Шакир: меңләгән күлләр иленә сикәлтәле юл

## Кызлар өчен эшләгән Мәккәдәге беренче Коръән мәктәбенең татар имамы белән бәйле булуы



**Әлеге мәкалә Тампере шәһәрендәге финнар җәмәгатьчелегенең иң танылган кешеләренең берсе булып торган Хәбибрахман Шакир (1903-1975) исемле кеше турында булыр. Без аның кызыклы язмышына һәм эшчәнлегенә багышланган мәкаләләр циклын багышларга булдык.**

Хәбибрахман Шакир шулай ук Хәбибрахман Болгари исеме белән билгеле. Ул 1903 елны дөньяга килә. Төгәл кайсы җирдә туганы мәгълүм түгел. Әмма «Болгари» сүзенә караганда, аның Урта Идел буенда, Казан губерниясе җирлегендә туганы аңлашыла. Тампере татар диаспорасы әһелләре аның, җәмәгатьчелекнең күпчелеге кебек, Түбән Новгород татар-мишәре булмавын, ә Казан татарлары арасыннан булуын билгеләп үтә.

Туган илендә башлангыч белемне алганнан соң, ул вакытта татарлардагы гадәт буенча, ул Бохарага китә. Ун ел дәвамында Бохара, Ташкент һәм Урта Азиянең башка күренекле ислам үзәкләрендә үзенең гыйлемнәрен камилләштерә. Ташкенттагы укулары вакытында ул Урта Азия һәм Казахстан мөселманнары Диния нәзарәтенең киләчәктә булачак икенче мөфтие Зыятдин Бабахан (1908-1982) белән таныша. Алар шактый еллар дустанә мөнәсәбәттә аралашып торалар. Хәбибрахман Ша-

кир бик гыйлемле кеше була. Туган теленнән тыш, ул гарәп, үзбәк, таҗик, төрек, урду һәм фарсы телләрен дә белгән.

1917 елгы революция вакытында Хәбибрахман Шакир Әфганстанга күченеп китәргә мәҗбүр була. Сүз уңаеннан, Әфганстан XX гасырның беренче яртысында алга киткән, шактый үсеш алган мөселман илләреннән була. Ул вакытта Кабул, Совет хакимиятеннән качып килгән мөселманнар өчен бик тә мөһим эмиграция үзәге булып хезмәт итә. Әфганстан үзәгендә Хәбибрахман Шакир танылган татар дин эшлеклесе Шәмсулла Вәлиулла (1867-1930) гаиләсе белән таныша. Бу танышу аның киләчәктәге тормышында зур роль уйный.

Шәмсулла хәзрәт Вәлиулла 1867 елны Иске Турай авылында (Башкортстанның хәзерге Йәрмәкәй районы) татар гаиләсендә туа. Дини гыйлемне авылларындагы мәдрәсәдә ала, Тукай һәм Түбән Бишинде авылларында мулла вазифасын үти. Революциягә кадәр Идел-Уралның күп кенә мәдрәсәләрендә дәрес бирә һәм дини сораулар буенча күп кенә китаплар яза. 1928 елда, хакимияткә большевиклар килгәннән соң, гаиләсе белән Троицк шәһәренә сөргенгә җибәрелә. Атып үтерелүгә дучар булудан аны элекккеге укучылары коткарып кала. Соңрак ул гаиләсе белән яшерен рәвештә Урта Азиягә, ә аннары Әфганстанга качып китә. Шәмсулла хәзрәт үзенең гаиләсендә бары гарәп телендә генә сөйләшү гадәтен кертүе игътибарга лаек. Шуңа күрә дә аның барлык балалары кечкенәдән гарәп телен яхшы белгән.

1930 елда, 63 яшендә Шәмсулла хәзрәт Кабул шәһәрендә малярия авыруыннан вафат була. Аның зур гаиләсе: 9 улы һәм 3 кызы кала. Шуларның берсе – Бибирәйхана киләчәктә Хәбибрахман Шакирның хәләл җефете була. Күпмедер вакыттан соң язмыш Шәмсулла хәзрәтнең гаиләсен бөтен дөнья буйлап тарата: уллары Садид (1912-1999) һәм Мотыйгулла (1917-1981) Австралиядә, ә Ришад (1910-1980) Пакыстанда төпләнеп кала, Нәсих (1915-2005) исемле улы әниләре белән бергә Мәккәгә китә.

Күпмедер вакыттан соң Шәмсулла хәзрәтнең бер кызы Бәбиджа Изге Мәккә шәһәрендә кызлар өчен беренче булган Коръән мәктәбенә нигез сала.



*Хәбибрахман Шакир хатынының абыйлары белән. Әфганстандагы 1930 еллар. Сулдан уңга утыручылар: Ришад (1910-1980), Хәбибрахман Шакир (1903-1975), билгесез башкорт, Чиләбе мулласының улы. Сулдан уңга басып торучылар: Садид (1912-1999), Мотыйгулла (1917-1981), Нәсих (1915-2005).*

*Мөхсин Нурулла язмалары,*
*islam-today.ru сайтыннан тәрҗемә*

# Ураза

# Рамазан – сабырлык ае

Аллаһы Тәгалә кешелек дөньясына күп төрле бүләкләр биргән. Шулар арасында, әлбәттә, Рамазан ае. Ә ул айның иң төп бүләге – ураза. Ураза сүзе гарәп телендәге «саум» – тыелып тору сүзеннән алынган. Шуңа күрә дә ураза тоткан һәр кеше бу айда бөтен төр бозыклыклардан, яман сүзләр сөйләүдән, аларны тыңлаудан, тел гөнаһларыннан (гайбәт, боһтан сөйләү), кеше рәнҗетүдән һәм, әлбәттә, ашау-эчүдән тыелып торырга тиеш.

Аллаһының расүле Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм бер вәгазендә мондый сүзләр әйткән: «Әй кешеләр, сезгә изге ай килде. Бу айда мең төннән дә хәерлерәк булган Кадер кичәсе бар. Аллаһы Тәгалә бу айда ураза тотуны – фарыз, ә төннәрен намаз белән үткәрүне сөннәт итеп кылды. Кем дә кем Аллаһыга бер нәфел гамәл эшләп якынайса, калган айларда фарыз гамәлне кылган кебек булыр, ә фарыз гамәл кылган кеше – 700 фарыз гамәл кылган кебек булыр. Бу – сабырлык ае, ә әҗерсавабы – җәннәт. Бу – тынычлык ае, кешенең ризыгы да күп тапкыр арта торган ай... Бу айның башы – рәхимлелек, уртасы – гөнаһларны гафу итү, азагы – ут газабыннан азат ителүдер. Шуңа күрә бу айда 4 төрле әйберне күбрәк эшләгез: икесе Аллаһы Тәгалә сездән разый була торган, ә икесе – үзегезгә бик кирәкле гамәлләр. Беренче ике гамәл – шәһадәт китерү һәм тәүбәләр кылу. Икенче ике гамәл – Аллаһыдан җәннәт сорап, Аңа ут газабыннан сыенудыр».

Һәр кеше бу айда күбрәк изгелекләр кылырга ашкынырга тиеш. Рамазан аенда кылына торган гыйбадәтләр саны күп булган кебек, аларны кылганда туган сораулар да байтак.

## Ураза буенча гомум сораулар

**Сорау:** Рамазан аенда ураза тоту кемнәргә фарыз?

**Җавап:** Ураза тотуның кайбер шартлары бар:

1. Мөселман булырга.
2. Үз акылында булырга.
3. Балигъ булырга.

Үз акылында булган һәм балигълык яшенә җиткән һәр мөселман (ир һәм хатын-кыз) Рамазан аеның уразасын тотарга бурычлы (фарыз).

**Сорау:** Балигълык яшенә җитмәгән бала нинди хөкемдә була?

**Җавап:** Балигълык яшенә җитмәгән балага ураза тоту мәҗбүри түгел. Әмма һәр гыйбадәткә кече яшьтән ияләштерү күркәм гамәл. Бу очракта баланың физик мөмкинлекләрен истә тотарга кирәк. Яшь организмга зыян салынырга тиеш түгел.

**Сорау:** Хатын-кызлар хәез (күрем) көннәрендә намаз да, ураза да тотмыйлар. Шулай ук, укылмаган намазларын да каза кылмыйлар. Ураза каза кылынамы?

**Җавап:** Хатыннар хәез көннәрендә һәм бала тапканнан соң чистарыну көннәрендә ураза тотмыйлар, ләкин бу көннәр узгач, калдырган ураза көннәрен каза итеп тотып бетерергә тиеш булалар.

**Сорау:** Әгәр хәез хәле ахшам намазына берничә минут кала башланса, ураза бозыламы?

**Җавап:** Әйе, ураза бозыла, ул көнне каза итеп тотасы була.

**Сорау:** Ураза вакытында дару эчсәң, ураза бозыламы?

**Җавап:** Әйе, ураза бозыла. Уразаны түбәндәге дүрт төрле эш боза:

1. Борчак кадәр генә булса да берәр ризык яки дару йоту.

2. Бер тамчы кадәр генә булса да су яки дару йоту.

3. Якынлык кылу.

4. Авыз тутырып косу.

**Сорау:** Ризыкны йотмыйча, телне тидереп карау уразаны бозамы?

**Җавап:** Бу гамәл уразаны бозмый, әмма мәкруһ (шелтәле) гамәл булып санала. Ураза вакытында көндезен түбәндәге эшләрне кылу мәкруһ (шелтәле) санала:

1. Файдасыз һәм әдәпсез сүзләр сөйләү.

2. Ризык һәм сагыз чәйнәү.

3. Берәр азыкка телне тидереп татып карау.

4. Иреннән үбү.

5. Авыз ачмыйча, ике көн рәттән ураза тоту.

6. Авыруының артачагын белә торып, ураза тоту.

7. Сатып алыначак малны (ризыкны) татып карау.

Ураза тоткан кешегә түбәндәге эшләрне башкару дөрес санала:

1. Балага ризык чәйнәп бирү (баланың ризыкны башкача кабул итү мөмкинлеге булмаганда).

2. Күзгә сөрмә тарту.

3. Тәһарәт вакытында мисвәк белән тешләрне пакьләү. Әмма чистарткан вакытта бүленеп чыккан төкерекне һәм мисвәкнең кисәкләрен йотарга ярамый.

4. Кан алдыру.

5. Сөлек салдыру.

6. Госел коену.

**Сорау:** Уразаның тәнебезгә файдасы бармы, яки ул бер гыйбадәт буларак кына барамы?

**Җавап:** Ураза – гыйбадәт, ул Аллаһы Тәгалә өчен башкарыла. Әмма Аллаһы Тәгаләнең өстебезгә йөкләгән һәр гыйбадәтендә тәнебезгә дә, рухи халәтебезгә дә файда бар.

Ураза ризык кабул итүдән генә тыелу түгел, безнең уй-фикерләребез дә уразада. Рамазан аенда кеше төрле начар фикерләрдән, гайбәт сөйләүдән тагын да күбрәк тыелып тора. Шулай ук тәнебез дә пакьләнә: ашказаныбыз ел дәвамында җыелган зыянлы, токсинлы матдәләрдән арына.

Ураза – ул Аллаһы Тәгалә биргән нигъмәтләр өчен шөкер итү. Шөкер итү акыл ягыннан да, шәригать буенча да фарыз.

Ураза фәкыйрьләргә мәрхәмәтле булырга өйрәтә. Байларга ел буе ач торган фәкыйрьләрнең хәленә төшенергә ярдәм итә.

Ураза шәһвәтне (җенси теләкләрне) тыя, чөнки күзгә матур булып күренгән нәрсәләр җенси теләкләрне уята. Ач торганда исә тыелып калып була.

**Сорау:** Онытылып берәр нәрсә ашау уразаны бозамы?

**Җавап:** Юк, бу очракта уразагыз бозылмый, дәвам итеп тотып бетерергә кирәк. Әмма уразалы булуыгыз исегезгә төшү белән, ашаудан туктарга кирәк.

**Сорау:** Организмда су балансын саклар өчен, ифтарны (авыз ачуны) ничек башкарырга кирәк?

**Җавап:** Авыз ачуны су белән башлый аласыз. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Су – пакьләндерә», – дип әйткән. Башта җиңел ризык, намаз укыгач кына авыррак ризык кабул итегез.

**Сорау:** Йокыдан уянганда мәни (ир-атларның орлыгы) чыкканын белдем. Миңа уразаны каза кыласы буламы?

**Җавап:** Төшләнү, ягъни поллюция уразаны бозмый. Госел коенып, уразаны дәвам итәргә кирәк.

**Сорау:** Тәһарәт алганда, яки госел коенганда ялгыш кына су йотылса, уразаны дәвам итәргә ярыймы?

**Җавап:** Бер тамчы су йоту уразаны боза. Ялгышлык белән кылынганлыктан, бу көннең уразасын каза кылырга тиешле. Уразаның әдәбе буенча, ифтарга кадәр көнне уразадагы кебек, ашамыйча үткәрү мөстәхәб гамәл булып тора.

**Сорау:** Тәравих намазыннан арып кайтып, иртән сәхәргә йоклап калганбыз. Сәхәр ашамыйча гына уразага керергә ярыймы?

**Җавап:** Бик арылган көннәрдә кеше сәхәр вакытында уяна алмыйча, иртәнге намаз кергәч кенә торырга мөмкин. Бу вакытта сәхәр ашарга ярамый. Әмма ул кеше барыбер ниятләп, уразага керә. Сәхәрсез ураза авыррак тотылачак, чөнки Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Сәхәр ашагыз, дөреслектә, сәхәрдә бәрәкәт бар», – дип әйткән. Әмма Аллаһыдан җиңеллек сорап, бу көнне ураза тотарга тырышырга кирәк, чөнки Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Кем Рамазан аеның бер көн уразасын калдырса, ул аны ел буе тотып та тутыра алмаячак», – дип әйтә. Әмма бу хәдис, казага калган уразаны тотмаска кирәк, дигәнне аңлатмый. Пәйгамбәребез шушы хәдисе белән Рамазан ае уразасының бик фазыйләтле икәнлегенә игътибар иткән.

**Сорау:** Мин намаз укымыйм, әмма ураза тотам. Андый ураза кабул кылынамы?

**Җавап:** Ислам дине 5 баганага нигезләнгән. Намаз һәм ураза – алар икесе ике гыйбадәт. Шуңа күрә, сез намаз укымасагыз да, уразагыз, иншәАллаһ, кабул булачак.

**Сорау:** Авыз ачу кайчан башкарыла: азан әйткәч яки ахшам намазын укыгач?

**Җавап:** Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Минем өммәтем авыз ачуны ашыктырган вакытта бәрәкәттә булачак», – дип әйткән. Димәк, авыз ачуны ашыктыру, ягъни азан әйтүгә башкару – сөннәт.

**Сорау:** Рамазан аенда берәр шәһәргә командировкага җибәрсәләр, уразаны тотмасаң буламы?

**Җавап:** Аллаһы Тәгалә мосафир булган кешеләргә кайбер җиңеллекләр биргән, шуларның берсе – Рамазан уразасын тотмыйча, казага калдыру. Рамазан ае тәмамлангач, сәфәрдә вакытта тотмыйча калган уразаларны каза кылырга кирәк булачак. Әгәр дә сәфәр кылу кешегә авырлыклар китерми икән, уразаны тотсаң була. Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә: «Ураза тотуыгыз сезнең өчен хәерлерәк, әгәр белсәгез» , – дип әйтә.

**Сорау:** Рамазан аенда никах мәҗлесләре үткәрергә (никах укытырга) ярыймы?

**Җавап:** Рамазан аенда шәригатебезгә муафыйк һәр гамәлне башкарырга була (никах, баланы сөннәткә утырту һ.б.), әмма бәйрәм табынын авыз ачу вакытына әзерләргә кирәк. Бу очракта икеләтә савап: ифтар кылу мәҗлесенә никах мәҗлесе савабы да өстәлә.

**Сорау:** Уразалы килеш спорт төрләре белән шөгыльләнү (бик каты тирләү) уразаны бозамы?

**Җавап:** Уразаны боза торган гамәлләрдән кала башка гамәлләр белән шөгыльләнү уразаны бозмый. Спорт белән үзегезгә авырлык китермәсәгез, шөгыльләнергә була. Ураза сезгә авырлык булып тоелмасын өчен, спорт белән шөгыльләнүне, организмны талчыктыра торган авыр хезмәтләрне ураза вакытында калдырып торырга киңәш ителә.

**Сорау:** Уразалы килеш сагыз чәйнәргә ярыймы?

**Җавап:** Уразалы килеш сагыз чәйнәү – мәкруһ (әмма бу очракта сагыздан шикәр кебек тәмләткечләр, яки сагызның кисәкчәләре бүленеп чыкмаска тиеш. Сагызда нинди генә булса да тәм, ис сизелсә, ул очракта ураза бозыла). Шунысын да истә тотарга кирәк: буш карынга сагыз чәйнәү медицина күзлегеннән караганда да хупланмый: сагыз чәйнәгәндә ашказаны согы бүленеп чыга. Бу исә төрле авырулар барлыкка килүгә сәбәп булырга мөмкин.

**Сорау:** Уразалы килеш мисвәк кулланырга ярыймы?

**Җавап:** Мисвәк куллану уразаны бозмый, киресенчә, сөннәт булып тора. Әмма вак кисәкләрен, бүленеп чыккан согын йоту – уразаны боза. Шуңа күрә мисвәкне тәһарәт алганда куллану һәм авызны яхшылап чайкау хәерлерәк.

**Сорау:** Уразада авызны теш пастасы белән чистартырга ярыймы?

**Җавап:** Бу – мәкруһ гамәл. Теш пастасын кулланган очракта, авызда аның тәме беткәнчегә кадәр су белән чайкатырга кирәк булачак.

**Сорау:** Укол ясатуның хөкеме нинди?

**Җавап:** Туклыклы матдәләре булмаган (глюкоза, физраствор) уколлар уразаны бозмый.

**Сорау:** Тырнак һәм чәч кистерергә ярыймы?

**Җавап:** Уразалы килеш тырнак кисергә дә, чәч кистерергә дә ярый. Бу гамәлләрне госел алдыннан эшләү тагын да хәерлерәк була.

**Сорау:** Уразалы килеш кан алдыру ярыймы (хиджама)?

**Җавап:** Кан алдыру уразаны бозмый, чөнки Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм уразалы килеш, ихрамда чакта да кан алдыра торган булган.

**Сорау:** Уразалы килеш тәнгә крем сөртергә ярыймы?

**Җавап:** Әйе, тәнгә крем яки майлар сөртү уразаны бозмый. Шулай ук душка керү, күзгә дару салу да бу хөкемгә карый.

**Сорау:** Минем, гайбәт сөйләү уразаны боза, дип ишеткәнем бар. Дөресме ул?

**Җавап:** Гайбәт уразаны бозмый, әмма Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм хәдисләрендә гайбәт ураза вакытында да, ураза булмаганда да сөйләнмәскә тиеш дип әйтелә. Моның зур гөнаһ икәнен Коръән аятьләре дә исбатлый.

# Рамазан, ураза зикерләре

## Сәхәр һәм ифтар

**Сорау:** Сәхәр ашагач, кайсы вакытта ният кылырга кирәк?

**Җавап:** Сәхәр ашаганнан соң ураза өчен таң атканчы ният кылу – мөстәхәб.

Ураза тоту өчен күңел белән ният кылу да җитә. Тел белән һичбер сүз әйтмичә, күңелдән «иртәгә ураза тотачакмын» дип уйлау да дөрес.

**Сорау:** Иртән йоклап калып, ният кылынмаган булса, аны кайчанга кадәр кылып була?

**Җавап:** Өйләгә кадәр бер сәгать чамасы вакыт калганчы ният кылынса да ярый. Өйлә вакытына бер сәгать чамасы гына вакыт калгач, ният кылу хәерле түгел.

**Сорау:** Уразага керер алдыннан ниятне ничек әйтергә?

**Җавап:** Ураза тотар алдыннан түбәндәге сүзләрне (гарәпчә) укып, тел белән ният кылу мөстәхәб санала:

نَوَيْتُ أَنْ أَصُومَ صَوْمَ شَهْرِ رَمَضَانَ مِنَ الْفَجْرِ إِلَى الْمَغْرِبِ خَالِصًا لِلَّهِ تَعَالَى

«Нәүәйтүән әсуумә саумә шәһри рамәдаанә минәл-фәҗри иләлмәгъриби хаалисан лилләәһи тәгааләә».

Мәгънәсе: «Аллаһы Тәгалә өчен, ихласлык белән таң вакытыннан башлап, кояш батканчыга кадәр Рамазан уразасын тотарга ният кылдым».

Сәхәрне кичтән түгел, ә нәкъ менә таң атуның беренче билгеләре күренә башлар алдыннан ашасаң яхшы була, чөнки бу очракта аның савабы күбрәк.

**Сорау:** Авыз ачар өчен сөннәт булган берәр төрле ризык бармы?

**Җавап:** Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Хөрмәләре булган кеше шулар белән (хөрмәләре белән), хөрмәсе булмаган кеше су белән авыз ачсын, чөнки су пакьләндерә», – дип әйткән.

Ифтардан соң (авыз ачканнан соң) түбәндәге дога укыла:

اَللَّهُمَّ لَكَ صُمْتُ وَبِكَ آمَنْتُ وَعَلَيْكَ تَوَكَّلْتُ وَعَلَى رِزْقِكَ أَفْطَرْتُ فَاغْفِرْ لِي يَا غَفَّارُ مَا قَدَّمْتُ وَمَا أَخَّرْتُ

«Аллааһуммә ләкә сумтү вә бикә әәмәнтү вә галәйкә тәүәккәлтү вә галәә ризкыйкә әфтартү фәгъфирлии йәә гаффәәрү мә каддәмтү вә мәә әххартү».

Мәгънәсе: «Аллаһым, шушы уразамны Синең өчен тоттым, Сиңа гына иман китердем һәм Сиңа тәвәккәл иттем. Синең ризыгың белән авыз

ачам. Әй, гөнаһларны гафу итүче Аллаһым, минем әүвәлге гөнаһларымны да, соңгы гөнаһларымны да ярлыка».

## Тәравих

**Сорау:** Тәравих намазы кайсы вакытта һәм ничә рәкәгать итеп укыла?

**Җавап:** Рамазан аенда уразадан кала икенче зур гамәл – ул тәравих намазы. Тәравих намазы Рамазан аенда укыла. Ул 20 рәкәгатьтән тора.

Тәравих намазы ирләр һәм хатыннар өчен, ураза тотучылар өчен дә, берәр төрле авыру яки сәфәрдә булу сәбәпле, ураза тотмаучылар өчен дә сөннәт мөәккәдә булып санала. Тәравих намазын мәчеттә уку – сөннәт, аны үтәгән өчен зур савап вәгъдә ителгән. Әмма әлеге намазны өйдә берүзең укырга туры килсә, өйдә дә укырга рөхсәт ителә.

**Сорау:** Тәравих намазын укыганда, ял вакытында көйләп укыла торган зикерләр бар. Аларның мәгънәләре ничек?

**Җавап:** Рамазанның 1-20 нче көннәрендә, гадәттә, түбәндәге зикерне укыйлар.

سُبْحَانَ ذِي الْمُلْكِ وَالْمَلَكُوتِ سُبْحَانَ ذِي العِزَّةِ وَالعَظَمَةِ وَالْقُدْرَةِ وَالْكِبْرِيَاءِ وَالجَبَرُوتِ سُبْحَانَ الْمَلِكِ الْحَيِّ الَّذِي لَا يَمُوتُ سُبُّوحٌ قُدُّوسٌ رَبُّنَا وَ رَبُّ الْمَلَائِكَةِ وَ الرُّوحِ لاَ إِلَهَ إِلاَّ اللّٰه نَسْتَغْفِرُاللّٰه نَسْأَلُكَ الْجَنَّةَ وَ نَعُوذُبِكَ مِنَ النَّارِ

«Сүбхәәнә ẓил-мүлки вәл-мәләкүүт. Сүбхәәнә ẓил-гыйззәти вәл-гаẓамәти вәл-кудрати вәл-кибрияя-и вәл-җәбәруут. Сүбхәәнәл-мәликил-хәййил-ләẓии ләә йәмүүт. Сүббүүхүн куддүүсүн раббүнәә вә раббүл-

мәләәикәти вәрруух. Ләә иләәһә илләллааһу нәстәгъфируллааһ. Нәс’әлүкәл җәннәтә вә нәгуузү бикә минән нәәр».

Мәгънәсе: «Яшерен вә ачык булган һәрнәрсәнең Иясе чиста Пакь. Көч-Куәт, Бөеклек, Күркәмлелек Иясе Пакь. Ул Мәңге исән һәм беркайчан да үлмәс. Камиллек Иясе, Кимчелексез, Ул – безнең Раббыбыз, фәрештәләрнең һәм җаннарның Раббысы. Аллаһыдан башка илаһ юк һәм без Аннан гөнаһларыбызның ярлыкавын сорыйбыз. Йә, Раббым, без Синнән җәннәт сорыйбыз һәм ут газабыннан сыенабыз».

Соңгы ун көнендә түбәндәге зикер әйтелә:

سُبْحَانَ الْمَلِكِ الْحَنَّانِ الْمَنَّانِ، سُبْحَانَ الْمَلِكِ الدَّيَّانِ، اَلْمَعْرُوفِ بِالْغُفْرَانِ وَالْمَوْصُوفِ بِالْإِحْسَانِ. اَلْوَدَاعُ اَلْوَدَاعُ اَلْفِرَاقُ اَلْفِرَاقُ يَا شَهْرَ رَمَضَانِ. اَللّٰهُمَّ يَا قَدِيمُ يَا حَكِيمُ يَا عَلِيمُ اِغْفِرْلَنَا يَا كَرِيمُ يَا رَحِيمُ يَا حَلِيمُ يَا أَرْحَمَ الرَّاحِمِينَ.

«Сүбхәәнәл мәликиль хәннәәнил мәннәән. Сүбхәәнәл мәликид дәййәән. Әлмәгъруууфү билгуфраан. Әлмәүсууфү биль ихсәән. Әлвәдәәгъ. Әлвәдәәгъ. Әльфирaак. Әльфирaак, йәә шәһра рамәдаан. Аллааһуммә йәә кадиим, йәә хәкиим, йәә галиим игъфир ләнәә йәә кәриим йәә рахиим йәә хәлиим йәә әрхәмәр-раахимиин».

Мәгънәсе: «Юмарт һәм Рәхимле булган Хаким Пакьтер. Ярлыкаучы буларак билгеле, игелеге белән аерылып торган хөкем Итүче Хаким Пакьтер. Ий Рамазан ае, синең белән саубуллашабыз, саубуллашабыз, аерылабыз, аерылабыз. Мәңге, Хәким, Галим булган Аллаһы, безнең гөнаһларны ярлыка, Син юмартлык Иясе, гөнаһларны Ярлыкаучы, ий, Рәхимнәрнең Рәхимлесе».

**Сорау:** Тәравих намазын укып, 5нче тәсбихтән соң нинди дога укыла?

**Җавап:** Тәравих укылгач, түбәндәге дога укылыр:

اَللَّهُمَّ صَلِّ عَلَى مُحَمَّدٍ وَعَلَى آلِ مُحَمَّدٍ وَسَلِّمْ اَللَّهُمَّ زَيِّنَّا بِزِينَةِ الْإِيمَانِ وَشَرِّفْنَا بِشَرَافَةِ الْهِدَايَةِ وَالْعِرْفَانِ وَأَكْرِمْنَا بِصِيَامِ شَهْرِ رَمَضَانَ وَارْزُقْنَا الْجَنَّةَ وَالْغُفْرَانَ وَتَقَبَّلْ مِنَّا تَرَاوِيحَنَا يَا سُبْحَان وَاسْتَجِبْ دُعَائَنَا يَا حَنَّان . بِفَضْلِكَ وَجُودِكَ يَا مَنَّانُ بِرَحْمَتِكَ يَا أَرْحَمَ الرَّاحِمِينَ

«Аллааһуммә салли галәә Мүхәммәдин вә галәә әәли Мүхәммәдин вә сәллим. Аллааһуммә зәййиннәә бизиинәтил-иимәән. Вә шәррифнәә бишәраафәтил-һидәәйәти вәл-гирфәән. Вә әкримнәә бисыйәәми шәһри рамадаан. Вәрзукънәл-җәннәтә вәл-гуфраан. Вә тәкаббәл миннәә тәраауиихәнәә йәә сүбехән. Вәстәҗиб дүгәә'әнәә йәә хәннәән. Бифәдъликә вә җүүдикә йәә мәннәән. Бирахмәтикә йәә әрхәмәр-раахимиин».

**Мәгънәсе:** «Йә, Аллаһым, Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм һәм аның әһле-бәйтен мөбарәк кыл һәм аларны сәламлә. Йә, Аллаһым, безне иман зиннәте белән бүләклә, хак юлга үгет-нәсыйхәт, гыйлем биреп, Рамазан аенда ураза тоттыр, ярлыкавыңны бир һәм җәннәт насыйп әйлә! Ий, Пакь булган Аллаһы Тәгалә, бездән тәравих намазын кабул ит. Ий, Мәрхәмәтле булган Аллаһы Тәгалә, мәрхәмәтеңнән, юмартлыгыңнан үтенечләребезгә җавап бир. Син мәрхәмәтлеләрнең иң Мәрхәмәтлесе! Барысы да Синең рәхмәтеңнән була».

# Рамазан ае белән бәйле матди чыгымнар

## Фидия

Рамазан аенда ураза тота алмаган кешеләр уразаларын башка айларда тота ала, уразаны бөтенләй тота алмаганнар исә фидия садакасы түләргә тиеш була. Фидия – ураза тотмаган көннәр өчен бирелә торган садака. Фидия акчалата түләнергә мөмкин. 2021 елда аның күләме 200 сум дип билгеләнде.

## Фитыр

Фитыр садакасы бирү һәр мөселманга да вәҗиб гамәлләрдән санала. Фитыр садакасы мохтаҗларга бирелә. Аны мөселман булмаганнардан һәм фәкыйрьләрдән тыш, бар кеше дә бирергә тиеш. Фитырны гаилә башлыгы барлык гаилә әгъзалары һәм аның тәрбиясендә булган кешеләр өчен үзенең кеременнән түли. Ир бала балигъ булуга, фитырны үзе өчен үз кеременнән түләргә омтылырга тиеш. Андый мөмкинлеге булмаган очракта, бу бурыч гаиләдәге башка ир-атлар өстенә төшә.

2021 елда фитыр садакасы түләү өчен нисаб күләме — 36 000 сум (көмеш буенча), фитыр садакасының минималь күләме – 100 сум, ә зәкят чыгару мөмкинлеге булганнарга 700 сум итеп түләргә тәкъдим ителә.

*«Рамазан. Ураза: еш бирелә торган сораулар»* китабыннан

# Хәдис

# УРАЗА КИТАБЫ

## كِتابُ الصَّوْمِ

٥٢٨

عَنْ أَبِي هُرَيْرَةَ: الصِّيَامُ جُنَّةٌ فَلَا يَرْفُثْ وَلَا يَجْهَلْ وَإِنْ امْرُؤٌ قَاتَلَهُ أَوْ شَاتَمَهُ فَلْيَقُلْ إِنِّي صَائِمٌ مَرَّتَيْنِ وَالَّذِي نَفْسِي بِيَدِهِ لَخُلُوفُ فَمِ الصَّائِمِ أَطْيَبُ عِنْدَ اللَّهِ تَعَالَى مِنْ رِيحِ الْمِسْكِ يَتْرُكُ طَعَامَهُ وَشَرَابَهُ وَشَهْوَتَهُ مِنْ أَجْلِي الصِّيَامُ لِي وَأَنَا أَجْزِي بِهِ وَالْحَسَنَةُ بِعَشْرِ أَمْثَالِهَا

Әбү Һөрайрадан тапшырыла: «Ураза – ул (җәһәннәм утыннан) пәрдә, ураза тоткан кеше ярамаган гамәлләр кылмасын һәм үз-үзен наданнар кебек тотмасын. Кем дә булса аның белән талашырга теләсә яки аны ачулана башласа, ул ике тапкыр: «Мин ураза тотам!» – дип әйтсен. Мин җаным Аның кулында булган Зат белән ант итәм, ураза тотучының авызыннан килгән ис Аллаһы Тәгалә өчен мускусның хуш исеннән дә тәмлерәк. Аллаһы болай дип әйтә: «Ул Минем өчен ашау-эчүдән һәм үзенең нәфесенә иярүдән баш тарта. Бу уразаны ул Минем өчен тота, һәм Мин аңа моның өчен әҗерен бирәчәкмен. Ә яхшы эшнең әҗере ун тапкыр артыграк булачак!»

٥٢٩

عَنْ سَهْلٍ: إِنَّ فِي الْجَنَّةِ بَابًا يُقَالُ لَهُ الرَّيَّانُ يَدْخُلُ مِنْهُ الصَّائِمُونَ يَوْمَ الْقِيَامَةِ لَا يَدْخُلُ مِنْهُ أَحَدٌ غَيْرُهُمْ يُقَالُ أَيْنَ الصَّائِمُونَ فَيَقُومُونَ لَا يَدْخُلُ مِنْهُ أَحَدٌ غَيْرُهُمْ فَإِذَا دَخَلُوا أُغْلِقَ فَلَمْ يَدْخُلْ مِنْهُ أَحَدٌ

Сәһлдән тапшырыла: «Хакыйкатьтә, җәннәттә Әр-Раййән дигән капкалар бар һәм Кыямәт көнендә аның аша бары тик ураза тоткан кешеләр генә керәчәк. «Ураза тоткан кешеләр кая?» – дип соралгач, алар уяначаклар һәм бу капкага алардан башка беркем дә кермәячәк. Алар җәннәткә кергәч, капкалар ябылыр, һәм алар аша бүтән беркем дә кермәс».

٥٣٠

عَنْ أَبِي هُرَيْرَةَ: مَنْ أَنْفَقَ زَوْجَيْنِ فِي سَبِيلِ اللَّهِ نُودِيَ مِنْ أَبْوَابِ الْجَنَّةِ يَا عَبْدَ اللَّهِ هَذَا خَيْرٌ فَمَنْ كَانَ مِنْ أَهْلِ الصَّلَاةِ دُعِيَ مِنْ بَابِ الصَّلَاةِ وَمَنْ كَانَ مِنْ أَهْلِ الْجِهَادِ دُعِيَ مِنْ بَابِ الْجِهَادِ وَمَنْ كَانَ مِنْ أَهْلِ الصِّيَامِ دُعِيَ مِنْ بَابِ الرَّيَّانِ وَمَنْ كَانَ مِنْ أَهْلِ الصَّدَقَةِ دُعِيَ مِنْ بَابِ الصَّدَقَةِ فَقَالَ أَبُو بَكْرٍ رَضِيَ اللَّهُ عَنْهُ بِأَبِي أَنْتَ وَأُمِّي يَا رَسُولَ اللَّهِ مَا عَلَى مَنْ دُعِيَ مِنْ تِلْكَ الأَبْوَابِ مِنْ ضَرُورَةٍ فَهَلْ يُدْعَى أَحَدٌ مِنْ تِلْكَ الأَبْوَابِ كُلِّهَا قَالَ نَعَمْ وَأَرْجُو أَنْ تَكُونَ مِنْهُمْ

Әбү Һөрайрадан тапшырыла: «Аллаһы ризалыгы өчен үз малының ике тигез өлешен корбан иткән кешене җәннәт ишекләреннән: «Йә, Аллаһының колы, бу – изгелек», – дип чакырып алачаклар. Намаз укыган кешене намаз капкаларыннан, Аллаһы юлында тырышлык куйган кешене Аллаһы юлында булучылар капкасыннан, ураза тоткан кешене Әр-Раййән капкасыннан, ә садака биргән кешене садака капкаларыннан керергә чакырачаклар». Моны ишеткәч, Әбү Бәкер радыяллаһу ганһе: «Әти-әнием синең өчен фида булсын, йә Аллаһының Расүле! Шул капкалардан чакырылган кешеләр башка бернәрсәгә дә мохтаҗ булмаслар, ләкин шулар арасында һәр капкадан да чакырылган кешеләр табылыр микән соң?» – дип сорады. Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Әйе, һәм мин синең дә алар арасында булуыңа өметләнәм!» – диде».

٥٣١

عَنْ أَبِي هُرَيْرَةَ: إِذَا جَاءَ رَمَضَانُ فُتِحَتْ أَبْوَابُ الْجَنَّةِ

Әбү Һөрайрадан тапшырыла: «Рамазан җиткәч, җәннәт капкалары ачыла!»

٥٣٢

عَنْ أَبِي هُرَيْرَةَ: إِذَا دَخَلَ شَهْرُ رَمَضَانَ فُتِّحَتْ أَبْوَابُ السَّمَاءِ وَغُلِّقَتْ أَبْوَابُ جَهَنَّمَ وَسُلْسِلَتْ الشَّيَاطِينُ

Әбү Һөрайрадан тапшырыла: «Рамазан ае җиткәч, күк капкалары ачыла, җәһәннәм капкалары biкләнә һәм шәйтаннар богаулап куела».

٥٣٣

عَنْ ابْنِ عُمَرَ: إِذَا رَأَيْتُمُوهُ فَصُومُوا وَإِذَا رَأَيْتُمُوهُ فَأَفْطِرُوا فَإِنْ غُمَّ عَلَيْكُمْ فَاقْدُرُوا لَهُ — لِهِلَالِ رَمَضَانَ

Ибне Гомәрдән тапшырыла: «Айны күрсәгез (Рамазан башындагы яңа туган ай), ураза тота башлагыз, ә аны тагын күргәч (ягъни шәүвәл ай тугач), уразагызны туктатыгыз. Әгәр көн болытлы булып, ай сездән яшеренгән булса, Рамазан ае буенча хисаплагыз».

٥٣٤

عَنْ أَبِي هُرَيْرَةَ: مَنْ قَامَ لَيْلَةَ الْقَدْرِ إِيمَانًا وَاحْتِسَابًا غُفِرَ لَهُ مَا تَقَدَّمَ مِنْ ذَنْبِهِ وَمَنْ صَامَ رَمَضَانَ إِيمَانًا وَاحْتِسَابًا غُفِرَ لَهُ مَا تَقَدَّمَ مِنْ ذَنْبِهِ

Әбү Һөрайрадан тапшырыла: «Иман белән Аллаһыдан әҗер өмет итеп Кадер кичәсен намазда үткәргән кешенең элек кылган гөнаһлары

ярлыканыр. Иман белән Аллаһыдан әҗер өмет итеп Рамазан аен ураза тотып үткәргән кешенең элек кылган гөнаһлары ярлыканыр».

٥٣٥

عَنْ أَبِي هُرَيْرَةَ: مَنْ صَامَ رَمَضَانَ إِيمَانًا وَاحْتِسَابًا غُفِرَ لَهُ مَا تَقَدَّمَ مِنْ ذَنْبِهِ

Әбү Һөрайрадан тапшырыла: «Иман белән Аллаһыдан әҗер өмет итеп Рамазан аен ураза тотып үткәргән кешенең элек кылган гөнаһлары ярлыканыр».

٥٣٦

عَنْ أَبِي هُرَيْرَةَ: مَنْ لَمْ يَدَعْ قَوْلَ الزُّورِ وَالْعَمَلَ بِهِ فَلَيْسَ لِلَّهِ حَاجَةٌ فِي أَنْ يَدَعَ طَعَامَهُ وَشَرَابَهُ

Әбү Һөрайрадан тапшырыла: «Әгәр кеше ялганлаудан һәм алдау белән эш итүдән тыелмаса, Аллаһыга аның ашау-эчүдән тыелып торуы кирәк түгел» .

٥٣٧

عَنْ أَبِي هُرَيْرَةَ: قَالَ اللَّهُ كُلُّ عَمَلِ ابْنِ آدَمَ لَهُ إِلَّا الصِّيَامَ فَإِنَّهُ لِي وَأَنَا أَجْزِي بِهِ وَالصِّيَامُ جُنَّةٌ وَإِذَا كَانَ يَوْمُ صَوْمِ أَحَدِكُمْ فَلَا يَرْفُثْ وَلَا يَصْخَبْ فَإِنْ سَابَّهُ أَحَدٌ أَوْ قَاتَلَهُ فَلْيَقُلْ إِنِّي امْرُؤٌ صَائِمٌ وَالَّذِي نَفْسُ مُحَمَّدٍ بِيَدِهِ لَخُلُوفُ فَمِ الصَّائِمِ أَطْيَبُ عِنْدَ اللَّهِ مِنْ رِيحِ الْمِسْكِ لِلصَّائِمِ فَرْحَتَانِ يَفْرَحُهُمَا إِذَا أَفْطَرَ فَرِحَ وَإِذَا لَقِيَ رَبَّهُ فَرِحَ بِصَوْمِهِ

Әбү Һөрайрадан тапшырыла: «Аллаһы Тәгалә: «Адәм баласы ни генә кылмасын, ул аның үзе өчен, уразадан кала, чөнки ураза ул Миңа тиешле әйбер һәм Мин аның өчен әҗерен бирәчәкмен!» – дип әйтте.

Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм шулай ук болай дип әйткән: «Ураза – ул (җәһәннәм утыннан) пәрдә, ураза тоткан кеше ярамаган гамәлләр кылмасын һәм тавышын күтәрмәсен. Кем дә булса аның белән талашырга теләсә яки аны ачулана башласа: «Мин ураза тотам!» – дип әйтсен. Мөхәммәднең җаны Аның кулында булган Зат белән ант итәм! Ураза тотучының авызыннан килгән ис Аллаһы өчен мускус исеннән тәмлерәк. Ураза тоткан кеше икеләтә шатлык хисе кичерәчәк: беренче тапкыр – авыз ачканда, икенче тапкыр – үзенең Раббысы белән очрашкач, ураза тотканына шатланачак».

٥٣٨

عَنْ عَبْدِ اللَّهِ: مَنْ اسْتَطَاعَ الْبَاءَةَ فَلْيَتَزَوَّجْ فَإِنَّهُ أَغَضُّ لِلْبَصَرِ وَأَحْصَنُ لِلْفَرْجِ وَمَنْ لَمْ يَسْتَطِعْ فَعَلَيْهِ بِالصَّوْمِ فَإِنَّهُ لَهُ وِجَاءٌ

Габдулладан тапшырыла: «Бервакыт мин Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм белән булганда ул: «Көченнән килгән кеше өйләнсен, чөнки никах карашны түбән төшерергә һәм гыйффәтне сакларга ярдәм итә. Өйләнә алмаган кеше ураза тотсын, чөнки ураза аны шәһвәтенә иярүдән тотып калыр», – диде».

٥٣٩

عَنْ عَبْدِ اللَّهِ بْنِ عُمَرَ: الشَّهْرُ تِسْعٌ وَعِشْرُونَ لَيْلَةً فَلَا تَصُومُوا حَتَّى تَرَوْهُ فَإِنْ غُمَّ عَلَيْكُمْ فَأَكْمِلُوا الْعِدَّةَ ثَلَاثِينَ

Габдулла бине Гомәрдән тапшырыла: «Ай егерме тугыз көннән дә килергә мөмкин, шуңар күрә, аны (яңа туган айны) күрми торып, ураза тота башламагыз. Көн болытлы булып, ай күренмәсә, утыз көннән хисаплагыз».

٥٤٠

عَنْ أُمِّ سَلَمَةَ: أَنَّ النَّبِيَّ صَلَّى اللَّهُ عَلَيْهِ وَسَلَّمَ آلَى مِنْ نِسَائِهِ شَهْرًا فَلَمَّا مَضَى تِسْعَةٌ وَعِشْرُونَ يَوْمًا غَدَا أَوْ رَاحَ فَقِيلَ لَهُ إِنَّكَ حَلَفْتَ أَنْ لَا تَدْخُلَ شَهْرًا فَقَالَ إِنَّ الشَّهْرَ يَكُونُ تِسْعَةً وَعِشْرِينَ يَوْمًا

Өмме Сәләмәдән тапшырыла: «Бервакыт Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм бер ай буе хатыннарым янына кермим дип ант иткән. Ә егерме тугыз көн үткәч, алар янына иртә белән (яки: «өйләдән соң») кергән. Аңа: «Син бит алар янына бер ай кермим дип ант иттең!» – дигәннәр. Ул: «Ай егерме тугыз көннән дә килә ала!» – дип әйткән».

٥٤١

عَنْ أَبِي بَكْرَةَ: شَهْرَانِ لَا يَنْقُصَانِ شَهْرَا عِيدٍ رَمَضَانُ وَذُو الْحَجَّةِ

Әбү Бәкраттан тапшырыла: «Ике ай кыскармый . Алар бәйрәм айлары – Рамазан һәм зөлхиҗҗә».

٥٤٢

عَنْ ابْنَ عُمَرَ: إِنَّا أُمَّةٌ أُمِّيَّةٌ لَا نَكْتُبُ وَلَا نَحْسُبُ الشَّهْرُ هَكَذَا وَهَكَذَا يَعْنِي مَرَّةً تِسْعَةً وَعِشْرِينَ وَمَرَّةً ثَلَاثِينَ

Ибне Гомәрдән тапшырыла: «Айның егерме тугыз көннән дә, утыз көннән дә килә алуын исәптә тотып, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Хакыйкатьтә, без надан халык, яза һәм хисаплый белмибез. Ә ай андый да, мондый да була ала», – дип әйткән».

٥٤٣

عَنْ أَبِي هُرَيْرَةَ: لَا يَتَقَدَّمَنَّ أَحَدُكُمْ رَمَضَانَ بِصَوْمِ يَوْمٍ أَوْ يَوْمَيْنِ إِلَّا أَنْ يَكُونَ رَجُلٌ

كَانَ يَصُومُ صَوْمَهُ فَلْيَصُمْ ذَلِكَ الْيَوْمَ

Әбү Һөрайрадан тапшырыла: «Сезнең берегез дә, әгәр ул аның гадәткә кергән гамәле булмаса, Рамазанга бер яки ике көн кала ураза тота башламасын. Әгәр ул аның гадәткә кергән гамәле икән, бу көнне дә ураза тотсын».

٥٤٤

عَنْ عَدِيِّ بْنِ حَاتِمٍ: لَمَّا نَزَلَتْ {حَتَّى يَتَبَيَّنَ لَكُمْ الْخَيْطُ الابْيَضُ مِنْ الْخَيْطِ الاسْوَدِ} عَمَدْتُ إِلَى عِقَالٍ أَسْوَدَ وَإِلَى عِقَالٍ أَبْيَضَ فَجَعَلْتُهُمَا تَحْتَ وِسَادَتِي فَجَعَلْتُ أَنْظُرُ فِي اللَّيْلِ فَلَا يَسْتَبِينُ لِي فَغَدَوْتُ عَلَى رَسُولِ اللَّهِ صَلَّى اللَّهُ عَلَيْهِ وَسَلَّمَ فَذَكَرْتُ لَهُ ذَلِكَ فَقَالَ إِنَّمَا ذَلِكَ سَوَادُ اللَّيْلِ وَبَيَاضُ النَّهَارِ

Гади бине Хәтимнән тапшырыла: «...Таңның ак җебе (төннең) кара җебеннән аерылганчыга кадәр ашагыз, эчегез, моннан соң кичкә кадәр ураза тотыгыз», – аяте иңгәч, мин (дөянең аякларын бәйли торган) ак һәм кара бауны мендәр астыма куйдым. Төнлә аларга карадым, ләкин берсен дә аера алмадым. Иртә белән Пәйгамбәр саллаллаһу галәйһи вә сәлләм янына килеп бу хакта сөйләдем, һәм ул: «Хакыйкатьтә, бу төннең караңгылыгы һәм көннең яктылыгына ишарә!» – диде».

٥٤٥

عَنْ أَنَس بْن مَالِكٍ: تَسَحَّرُوا فَإِنَّ فِي السَّحُورِ بَرَكَةً

Әнәс бине Мәликтән тапшырыла: «Таң алдыннан ашагыз, хакыйкатьтә, сәхәр ашауда бәрәкәт бар».

٥٤٦

عَنْ سَلَمَةَ بْنِ الأَكْوَعِ: أَنَّ النَّبِيَّ صَلَّى اللَّهُ عَلَيْهِ وَسَلَّمَ بَعَثَ رَجُلًا يُنَادِي فِي النَّاسِ يَوْمَ عَاشُورَاءَ أَنَّ مَنْ أَكَلَ فَلْيُتِمَّ أَوْ فَلْيَصُمْ وَمَنْ لَمْ يَأْكُلْ فَلَا يَأْكُلْ

Сәләмә бине Әл-Әквәгътән тапшырыла: «Гашурә көне җитүен халыкка хәбәр итәр өчен Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм бер кешене җибәргән һәм: «Ашап өлгергән кеше ризыктан тыелсын (ягъни, ураза тотсын), ә ашамаганнар кичкә кадәр бернәрсә дә ашамасын», – дип әйткән.

٥٤٧

عَنْ أَبِي هُرَيْرَةَ: إِذَا نَسِيَ فَأَكَلَ وَشَرِبَ فَلْيُتِمَّ صَوْمَهُ فَإِنَّمَا أَطْعَمَهُ اللَّهُ وَسَقَاهُ

Әбү Һөрайрадан тапшырыла: «Әгәр дә кеше ураза вакытында онытылып ашаса яки эчсә, ул кеше ураза тотуын дәвам итсен, чөнки, хакыйкатьтә, аны ашатучы һәм эчертүче – Аллаһы».

٥٤٨

عَنْ أَبِي هُرَيْرَةَ: بَيْنَمَا نَحْنُ جُلُوسٌ عِنْدَ النَّبِيِّ صَلَّى اللَّهُ عَلَيْهِ وَسَلَّمَ إِذْ جَاءَهُ رَجُلٌ فَقَالَ يَا رَسُولَ اللَّهِ هَلَكْتُ قَالَ مَا لَكَ قَالَ وَقَعْتُ عَلَى امْرَأَتِي وَأَنَا صَائِمٌ فَقَالَ رَسُولُ اللَّهِ صَلَّى اللَّهُ عَلَيْهِ وَسَلَّمَ هَلْ تَجِدُ رَقَبَةً تُعْتِقُهَا قَالَ لَا قَالَ فَهَلْ تَسْتَطِيعُ أَنْ تَصُومَ شَهْرَيْنِ مُتَتَابِعَيْنِ قَالَ لَا فَقَالَ فَهَلْ تَجِدُ إِطْعَامَ سِتِّينَ مِسْكِينًا قَالَ لَا قَالَ فَمَكَثَ النَّبِيُّ صَلَّى اللَّهُ عَلَيْهِ وَسَلَّمَ فَبَيْنَا نَحْنُ عَلَى ذَلِكَ أُتِيَ النَّبِيُّ صَلَّى اللَّهُ عَلَيْهِ وَسَلَّمَ بِعَرَقٍ فِيهَا تَمْرٌ وَالْعَرَقُ الْمِكْتَلُ قَالَ أَيْنَ السَّائِلُ فَقَالَ أَنَا قَالَ خُذْهَا فَتَصَدَّقْ بِهِ فَقَالَ الرَّجُلُ أَعَلَى أَفْقَرَ مِنِّي يَا رَسُولَ اللَّهِ فَوَاللَّهِ مَا بَيْنَ لَابَتَيْهَا يُرِيدُ الْحَرَّتَيْنِ أَهْلُ بَيْتٍ أَفْقَرُ مِنْ أَهْلِ بَيْتِي فَضَحِكَ النَّبِيُّ صَلَّى اللَّهُ عَلَيْهِ وَسَلَّمَ حَتَّى بَدَتْ أَنْيَابُهُ ثُمَّ

قَالَ أَطْعِمْهُ أَهْلَكَ

Әбү Һөрайрадан тапшырыла: «Без Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм янында утырганда аның янына бер кеше килеп: «Йә Аллаһының Расүле! Мин һәлак булдым!» – диде. Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм аннан: «Нәрсә булды?» – дип сорады. Ул: «Ураза вакытында мин хатыным белән якынлык кылдым», – диде. Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм аннан: «Синең азат итәрлек колларың бармы?» – дип сорады. Ул: «Юк», – дип җавап бирде. Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Син ике ай рәттән ураза тота аласыңмы?» – дип сорады. Ул: «Юк», – диде. Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Син алтмыш мохтаҗ кешене ашата аласыңмы?» – дип сорады. Ул: «Юк», – диде. Шуннан соң Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм күпмедер вакытка тынып калды, без исә көтеп тордык. Шуннан соң аңа хөрмәләр белән тулы хөрмә агачы яфракларыннан ясалган кәрзин китерделәр. Ул: «Сорау биргән кеше кайда?» – дип сорады. «Мин монда», – дигән җавап килде. Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Моны ал да, садака итеп тарат», – диде. Ул кеше: «Йә Расүлүллаһ, миннән дә мохтаҗ булган кешеләргәме?» – дип сорады. – Аллаһы белән ант итәм, Мәдинәдә минем гаиләмнән дә мохтаҗрак гаилә юк!» – диде. Моны ишеткәч, Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм тешләре күренерлек итеп көлеп җибәрде һәм: «Аларны үз гаиләңә ашат!» – дип әйтте».

٥٤٩

عَنْ ابْن أَبِي أَوْفَى: كُنَّا مَعَ رَسُولِ اللَّهِ صَلَّى اللَّهُ عَلَيْهِ وَسَلَّمَ فِي سَفَرٍ فَقَالَ لِرَجُلٍ انْزِلْ فَاجْدَحْ لِي قَالَ يَا رَسُولَ اللَّهِ الشَّمْسُ قَالَ انْزِلْ فَاجْدَحْ لِي قَالَ يَا رَسُولَ اللَّهِ الشَّمْسُ قَالَ انْزِلْ فَاجْدَحْ لِي فَنَزَلَ فَجَدَحَ لَهُ فَشَرِبَ ثُمَّ رَمَى بِيَدِهِ هَا هُنَا ثُمَّ قَالَ إِذَا رَأَيْتُمْ اللَّيْلَ أَقْبَلَ مِنْ هَا هُنَا فَقَدْ أَفْطَرَ

Ибне Әбү Гауфтан тапшырыла: «Көннәрдән бер көнне без Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм белән юлда булганда, ул бер кешегә: «(Атланган хайваныңнан) Җиргә төш тә, миңа ашарга болгатып бир», – диде. Теге кеше: «Йә Аллаһының Расүле! Кояш бит әле?» – диде. Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм янә: «Төш тә, миңа ашарга болгатып бир», – диде. Теге кеше янә: «Йә Аллаһының Расүле! Кояш бит әле?» – диде, һәм Пәйгамбәр өченче тапкыр: «Төш тә, миңа ашарга болгатып бир!» – дип боерды. Ниһаять, теге кеше төште, аңа ашарга болгатты, һәм Пәйгамбәр, эчеп алгач, кулы белән көнчыгышка күрсәтте һәм: «Моннан төн килүен күрсәгез, ураза тотучы кеше авыз ачсын!» – диде».

٥٥٠

عَنْ عَائِشَةَ: أَنَّ حَمْزَةَ بْنَ عَمْرٍو الأَسْلَمِيَّ قَالَ لِلنَّبِيِّ صَلَّى اللَّهُ عَلَيْهِ وَسَلَّمَ أَأَصُومُ فِي السَّفَرِ وَكَانَ كَثِيرَ الصِّيَامِ فَقَالَ إِنْ شِئْتَ فَصُمْ وَإِنْ شِئْتَ فَأَفْطِرْ

Гайшәдән тапшырыла: «Бик күп ураза тотуы белән аерылып торган Хәмзә бине Гамр Әл-Әсләми Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләмнән: «Миңа юлда ураза тотарга кирәкме?» – дип сорады. Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Теләсәң – тот, теләмәсәң – тотмасаң да була», – дип җавап бирде.

٥٥١

عَنْ جَابِرِ بْنِ عَبْدِ اللَّهِ: كَانَ رَسُولُ اللَّهِ صَلَّى اللَّهُ عَلَيْهِ وَسَلَّمَ فِي سَفَرٍ فَرَأَى زِحَامًا وَرَجُلًا قَدْ ظُلِّلَ عَلَيْهِ فَقَالَ مَا هَذَا فَقَالُوا صَائِمٌ فَقَالَ لَيْسَ مِنْ الْبِرِّ الصَّوْمُ فِي السَّفَرِ

Җәбир бине Габдулладан тапшырыла: «Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм юлда вакытта кешеләрнең бер бәндәне кояштан каплап торганнарын күреп: «Нәрсә булды?» – дип сорады. Аңа: «Ул ураза

тота», – дип җавап бирделәр. Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Сәфәрдә вакытта ураза тоту тәкъвалыктан түгел», – дип әйтте».

٥٥٢

عَنْ عَائِشَةَ: مَنْ مَاتَ وَعَلَيْهِ صِيَامٌ صَامَ عَنْهُ وَلِيُّهُ

Гайшәдән тапшырыла: «Кем дә булса уразасын тотып бетермичә вафат булса, аның өчен варислары тотып бетерсен».

٥٥٣

عَنْ ابْنِ عَبَّاسٍ: جَاءَ رَجُلٌ إِلَى النَّبِيِّ صَلَّى اللَّهُ عَلَيْهِ وَسَلَّمَ فَقَالَ يَا رَسُولَ اللَّهِ إِنَّ أُمِّي مَاتَتْ وَعَلَيْهَا صَوْمُ شَهْرٍ أَفَأَقْضِيهِ عَنْهَا قَالَ نَعَمْ فَدَيْنُ اللَّهِ أَحَقُّ أَنْ يُقْضَى

Ибне Габбастан тапшырыла: «Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм янына бер кеше килеп: «Йә Аллаһының Расүле! Минем әнием ай буе ураза тотып бетермичә вафат булды, бәлки миңа аның өчен моны үтәргәдер?» – дип сорады. Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм аңа: «Әйе, чөнки Аллаһы каршындагы бурычны кайтару өстенрәк!» – диде».

٥٥٤

عَنْ سَهْلِ بْنِ سَعْدٍ: لَا يَزَالُ النَّاسُ بِخَيْرٍ مَا عَجَّلُوا الْفِطْرَ

Сәһел бине Сәгъдтән тапшырыла: «Бу кешеләр ифтарны ашыктырудан туктаганчы бәрәкәттән мәхрүм ителмәсләр».

٥٥٥

عَنْ ابْنِ أَبِي أَوْفَى: كُنْتُ مَعَ النَّبِيِّ صَلَّى اللَّهُ عَلَيْهِ وَسَلَّمَ فِي سَفَرٍ فَصَامَ حَتَّى أَمْسَى قَالَ لِرَجُلٍ انْزِلْ فَاجْدَحْ لِي قَالَ لَوْ انْتَظَرْتَ حَتَّى تُمْسِيَ قَالَ انْزِلْ فَاجْدَحْ لِي إِذَا رَأَيْتَ اللَّيْلَ قَدْ أَقْبَلَ مِنْ هَا هُنَا فَقَدْ أَفْطَرَ الصَّائِمُ

Ибне Әбү Гауфтан тапшырыла: «Без Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм белән сәфәрдә идек. Ул кич җиткәнче ураза тотты һәм бер кешегә: «(Атланган хайваныңнан) Җиргә төш тә, миңа ашарга болгатып бир», – дип әйтте. Шул кеше: «Ахшам җиткәнен көтмисеңме?» – диде. Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «(Атланган хайваныңнан) Җиргә төш тә, миңа ашарга болгатып бир, – дип кабатлады. – Ураза тотучыга кояш баегач та ашарга (ифтар кылырга) ярый».

٥٥٦

عَنْ الرُّبَيِّعِ بِنْتِ مُعَوِّذٍ: أَرْسَلَ النَّبِيُّ صَلَّى اللَّهُ عَلَيْهِ وَسَلَّمَ غَدَاةَ عَاشُورَاءَ إِلَى قُرَى الانْصَارِ مَنْ أَصْبَحَ مُفْطِرًا فَلْيُتِمَّ بَقِيَّةَ يَوْمِهِ وَمَنْ أَصْبَحَ صَائِمًا فَلَيَصُمْ

Рубаййигъ бинте Мөгаввиз тапшырыла: «Гашура көненең иртәсендә Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм әнсарларны кисәтергә кеше җибәрде: «Бүген иртә белән ашаган кеше кичкә кадәр ашамасын, ә иртәдән бирле ураза тотучы көне буе ураза тотсын!» – дип әйтергә кушты».

٥٥٧

عَنْ أَبِي سَعِيدٍ: لَا تُوَاصِلُوا فَأَيُّكُمْ إِذَا أَرَادَ أَنْ يُوَاصِلَ فَلْيُوَاصِلْ حَتَّى السَّحَرِ قَالُوا فَإِنَّكَ تُوَاصِلُ يَا رَسُولَ اللَّهِ قَالَ إِنِّي لَسْتُ كَهَيْئَتِكُمْ إِنِّي أَبِيتُ لِي مُطْعِمٌ يُطْعِمُنِي وَسَاقٍ يَسْقِينِ

Әбү Сәгыйдтән тапшырыла: «Берөзлексез (көндез дә, төнлә дә) ураза тотмагыз! Әгәр дә берәрегез (икенче көнне дә) уразасын дәвам иттерергә теләсә, аның уразасы сәхәр вакытыннан да артык дәвам итмәсен (ягъни кич белән ифтар кылмыйча, сәхәрне көтсен)». Сәхабәләр: «Йә Аллаһының Расүле! Син бит берөзлексез ураза тотасың!» – диделәр. Пәйгамбәр

салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Мин сезнең кебек түгел. Йоклаган вакытта мине ашатучы һәм эчертүче (Аллаһы) бар», – дип җавап бирде».

٥٥٨

عَنْ أَبِي هُرَيْرَةَ: نَهَى رَسُولُ اللَّهِ صَلَّى اللَّهُ عَلَيْهِ وَسَلَّمَ عَنْ الْوِصَالِ فِي الصَّوْمِ فَقَالَ لَهُ رَجُلٌ مِنْ الْمُسْلِمِينَ إِنَّكَ تُوَاصِلُ يَا رَسُولَ اللَّهِ قَالَ وَأَيُّكُمْ مِثْلِي إِنِّي أَبِيتُ يُطْعِمُنِي رَبِّي وَيَسْقِينِ فَلَمَّا أَبَوْا أَنْ يَنْتَهُوا عَنْ الْوِصَالِ وَاصَلَ بِهِمْ يَوْمًا ثُمَّ يَوْمًا ثُمَّ رَأَوْا الْهِلَالَ فَقَالَ لَوْ تَأَخَّرَ لَزِدْتُكُمْ كَالتَّنْكِيلِ لَهُمْ حِينَ أَبَوْا أَنْ يَنْتَهُوا

Әбү Һөрайрадан тапшырыла: «Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм берөзлексез ураза тотуны тыйды, шуннан соң мөселманнарның берсе: «Йә Аллаһының Расүле! Син шулай эшлисең бит», – диде. Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Сезнең кайсыгзы миңа тиң? Хакыйкатьтә, Раббым мине төнлә ашата һәм эчертә», – диде. Кайберәүләр берөзлексез ураза тотуны туктатмагач, Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм дә алар белән бергә ач торды – башта бер көн, аннан икенче көн, шуннан соң яңа ай туганы күренде. Моннан соң Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм аларның буйсынмауларына җәза бирер өчен: «Әгәр ул (ай) соңрак чыккан булса, мин сезгә тагын өстәгән булыр идем», – дип әйтте».

٥٥٩

عَنْ أَبِي جُحَيْفَةَ: آخَى النَّبِيُّ صَلَّى اللَّهُ عَلَيْهِ وَسَلَّمَ بَيْنَ سَلْمَانَ وَأَبِي الدَّرْدَاءِ فَزَارَ سَلْمَانُ أَبَا الدَّرْدَاءِ فَرَأَى أُمَّ الدَّرْدَاءِ مُتَبَذِّلَةً فَقَالَ لَهَا مَا شَأْنُكِ قَالَتْ أَخُوكَ أَبُو الدَّرْدَاءِ لَيْسَ لَهُ حَاجَةٌ فِي الدُّنْيَا فَجَاءَ أَبُو الدَّرْدَاءِ فَصَنَعَ لَهُ طَعَامًا فَقَالَ كُلْ قَالَ فَإِنِّي صَائِمٌ قَالَ مَا أَنَا بِآكِلٍ حَتَّى تَأْكُلَ قَالَ فَأَكَلَ فَلَمَّا كَانَ اللَّيْلُ ذَهَبَ أَبُو الدَّرْدَاءِ يَقُومُ قَالَ نَمْ فَنَامَ ثُمَّ ذَهَبَ يَقُومُ فَقَالَ نَمْ فَلَمَّا كَانَ مِنْ آخِرِ اللَّيْلِ قَالَ سَلْمَانُ قُمْ

الْآنَ فَصَلَّيَا فَقَالَ لَهُ سَلْمَانُ إِنَّ لِرَبِّكَ عَلَيْكَ حَقًّا وَلِنَفْسِكَ عَلَيْكَ حَقًّا وَلِأَهْلِكَ عَلَيْكَ حَقًّا فَأَعْطِ كُلَّ ذِي حَقٍّ حَقَّهُ فَأَتَى النَّبِيَّ صَلَّى اللَّهُ عَلَيْهِ وَسَلَّمَ فَذَكَرَ ذَلِكَ لَهُ فَقَالَ النَّبِيُّ صَلَّى اللَّهُ عَلَيْهِ وَسَلَّمَ صَدَقَ سَلْمَانُ

Әбү Җөхәйфәдән тапшырыла: «Сәлман белән Әбү Әд-Дәрдә Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм тырышлыгы белән туганлаштылар. Әбү Әд-Дәрдәның хәлен белешергә килгәч, Сәлман аның хатыны Өмме Әд-Дәрдәны бик иске киемнәрдән күреп: «Сиңа ни булды?» – дип сорады. Ул: «Синең туганың Әбү Әд-Дәрдә бу дөнья малларына мохтаҗ түгел», – дип җавап бирде. Шуннан соң Әбү Әд-Дәрдә үзе кайтып керде һәм, Сәлмангә сыйлар әзерләп: «Ашап ал», – диде. Әбү Әд-Дәрдә: «Дөреслектә, мин ураза тотам», – диде. Сәлман: «Син ашамый торып, мин дә ашамыйм!» – диде. Шунда ул да ашады. Төн җиткәч, Әбү Әд-Дәрдә намазга торды. Сәлман аңа: «Йокла», – диде һәм ул йоклады, соңыннан янә намазга торды. Сәлман аңа янә: «Йокла», – диде. Төн азагында Сәлман аңа: «Ә хәзер тор», – диде. Һәм алар бергә намаз укыдылар. Сәлман аңа: «Хакыйкатьтә, синең Раббыңның сиңа хакы бар, җаныңның да сиңа хакы бар, хатыныңның да сиңа хакы бар, хакы булганнарның һәрберсенә үз өлешләрен бир!» – диде. Шуннан соң Әбү Әд-Дәрдә, Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм янына килеп, боларны сөйләде. Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Сәлман дөресен әйткән!» – диде».

٥٦٠

عَنْ عَائِشَةَ: لَمْ يَكُنْ النَّبِيُّ صَلَّى اللَّهُ عَلَيْهِ وَسَلَّمَ يَصُومُ شَهْرًا أَكْثَرَ مِنْ شَعْبَانَ فَإِنَّهُ كَانَ يَصُومُ شَعْبَانَ كُلَّهُ وَكَانَ يَقُولُ خُذُوا مِنْ الْعَمَلِ مَا تُطِيقُونَ فَإِنَّ اللَّهَ لَا يَمَلُّ حَتَّى تَمَلُّوا وَأَحَبُّ الصَّلَاةِ إِلَى النَّبِيِّ صَلَّى اللَّهُ عَلَيْهِ وَسَلَّمَ مَا دُووِمَ عَلَيْهِ وَإِنْ قَلَّتْ وَكَانَ إِذَا صَلَّى صَلَاةً دَاوَمَ عَلَيْهَا

Гайшәдән тапшырыла: «Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм шәгъбанга караганда бер айда да күбрәк ураза тотмый иде, кайбер вакытта ул бу айны тоташ ураза тота иде һәм еш кына: «Үзегезнең хәлегездән килә торган эшләргә генә алыныгыз. Хакыйкатьтә, сез (изге гамәл кылудан) армый торып, Аллаһы (сезгә әҗер-савап бирүдән) арымас», – дип әйтә иде. Пәйгамбәрнең яраткан намазларына килгәндә, алар – кыска булса да даими укыла торган намазлар иде. Шуңар күрә, ул намазны бер укыса, аны, гадәттә, киләчәктә һаман укый торган булды».

٥٦١

عَنْ عَبْدِ اللَّهِ بْن عَمْرِو بْنِ الْعَاصِ: يَا عَبْدَ اللَّهِ أَلَمْ أُخْبَرْ أَنَّكَ تَصُومُ النَّهَارَ وَتَقُومُ اللَّيْلَ فَقُلْتُ بَلَى يَا رَسُولَ اللَّهِ قَالَ فَلَا تَفْعَلْ صُمْ وَأَفْطِرْ وَقُمْ وَنَمْ فَإِنَّ لِجَسَدِكَ عَلَيْكَ حَقًّا وَإِنَّ لِعَيْنِكَ عَلَيْكَ حَقًّا وَإِنَّ لِزَوْجِكَ عَلَيْكَ حَقًّا وَإِنَّ لِزَوْرِكَ عَلَيْكَ حَقًّا وَإِنَّ بِحَسْبِكَ أَنْ تَصُومَ كُلَّ شَهْرٍ ثَلَاثَةَ أَيَّامٍ فَإِنَّ لَكَ بِكُلِّ حَسَنَةٍ عَشْرَ أَمْثَالِهَا فَإِنَّ ذَلِكَ صِيَامُ الدَّهْرِ كُلِّهِ قُلْتُ يَا رَسُولَ اللَّهِ إِنِّي أَجِدُ قُوَّةً قَالَ فَصُمْ صِيَامَ نَبِيِّ اللَّهِ دَاوُدَ عَلَيْهِ السَّلَام وَلَا تَزِدْ عَلَيْهِ قُلْتُ وَمَا كَانَ صِيَامُ نَبِيِّ اللَّهِ دَاوُدَ عَلَيْهِ السَّلَام قَالَ نِصْفَ الدَّهْرِ

Габдулла бине Гамр бине Әл-Гастан тапшырыла: «Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм миңа: «Йә Габдулла! Сине көндез ураза тота, ә төнлә намаз укый диләр», – диде. Мин: «Әйе, йә Расүлуллаһ», – дидем. Ул миңа: «Алай эшләмә! Аша да, ураза да тот, төнге намазларыңны да укы, йокла да; чөнки синең тәнеңнең сиңа хакы бар, күзләреңнең дә сиңа хакы бар, хатыныңның да сиңа хакы бар, кунагыңның да сиңа хакы бар. Шуңа сиңа айга өч көн ураза тоту да җитә, һәрбер эш өчен ун әҗер бирелә бит. Шул рәвешле, син даими ураза тоткан кебек буласың», – диде. Мин: «Йә Расүлуллаһ! Минем бит көчемнән килә», – дидем. Ул миңа: «Алай-

са, Давыд галәйһиссәлам тоткан кебек ураза тот, ләкин шуннан артыгын түгел!» – диде. Мин: «Давыд галәйһиссәлам ничек ураза тоткан?» – дип сорадым. Ул: «Көнаралаш», – дип җавап бирде».

٥٦٢

عَنْ أَنَسٍ: دَخَلَ النَّبِيُّ صَلَّى اللَّهُ عَلَيْهِ وَسَلَّمَ عَلَى أُمِّ سُلَيْمٍ فَأَتَتْهُ بِتَمْرٍ وَسَمْنٍ قَالَ أَعِيدُوا سَمْنَكُمْ فِي سِقَائِهِ وَتَمْرَكُمْ فِي وِعَائِهِ فَإِنِّي صَائِمٌ ثُمَّ قَامَ إِلَى نَاحِيَةٍ مِنْ الْبَيْتِ فَصَلَّى غَيْرَ الْمَكْتُوبَةِ فَدَعَا لِأُمِّ سُلَيْمٍ وَأَهْلِ بَيْتِهَا فَقَالَتْ أُمُّ سُلَيْمٍ يَا رَسُولَ اللَّهِ إِنَّ لِي خُوَيْصَّةً قَالَ مَا هِيَ قَالَتْ خَادِمُكَ أَنَسٌ فَمَا تَرَكَ خَيْرَ آخِرَةٍ وَلَا دُنْيَا إِلَّا دَعَا لِي بِهِ قَالَ اللَّهُمَّ ارْزُقْهُ مَالًا وَوَلَدًا وَبَارِكْ لَهُ فَإِنِّي لَمِنْ أَكْثَرِ الأنْصَارِ مَالًا وَحَدَّثَتْنِي ابْنَتِي أُمَيْنَةُ أَنَّهُ دُفِنَ لِصُلْبِي مَقْدَمَ حَجَّاجٍ الْبَصْرَةَ بِضْعٌ وَعِشْرُونَ وَمِائَةٌ

Әнәстән тапшырыла: «Көннәрдән бер көнне Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм Өмме Сүләем (Әнәснең әнисе) янына керде. Өмме Сүләйм аңа хөрмә һәм май китерде. Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм аңа: «Маегызны кире савытына бушатыгыз, а хөрмәне кире кәрзингә салыгыз, чөнки мин ураза тотам», – диде. Шуннан соң ул, урын табып, Өмме Сүләйм һәм аның гаиләсенә бәрәкәт сорап өстәмә намаз укыды. Аннары Өмме Сүләйм аннан: «Йә Аллаһының Расүле! Минем сиңа бер үтенечем бар», – диде. Ул: «Нинди?» – дип сорады. Өмме Сүләйм: «Бу синең хезмәтчең Әнәскә кагыла», – диде. Шул вакытта Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм Аллаһыдан минем өчен бер нәрсәне дә калдырмыйча бу дөньяда да, Ахирәттә дә бәхетләр теләп дога кылды. «Йә Аллаһы! Аңа байлык һәм балалар бүләк ит, аңа бәрәкәт бир!» – диде. (Аллаһуммәр-зукһу мәәлән вә вәләдән вә бәрик ләһу!) Һәм, дөреслектә,

мин хәзер иң бай әнсарларның берсе, ә минем кызым Үмәйнә әйтүенчә, Хәҗҗәҗ пәйдә булганчы, Басрада минем йөз егермедән артык нәселем күмелгән иде».

٥٦٣

عَنْ عِمْرَانَ بْنِ حُصَيْنٍ: يَا أَبَا فُلَانٍ أَمَا صُمْتَ سَرَرَ هَذَا الشَّهْرِ قَالَ أَظُنُّهُ قَالَ يَعْنِي رَمَضَانَ قَالَ الرَّجُلُ لَا يَا رَسُولَ اللَّهِ قَالَ فَإِذَا أَفْطَرْتَ فَصُمْ يَوْمَيْنِ

Гыймран бине Хөсайнидан тапшырыла: «Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм бер кешедән: «Йә фәлән кешенең әтисе, син бу айның (шәгъбанның) ахырында ураза тоттыңмы?» – дип сорады. Ул кеше: «Юк, йә Расүлуллаһ!» – диде. Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Рамазан аеның фарыз уразасын тотып бетергәч, шәүвәл аенда тагын ике көн ураза тот», – диде. Башка бер риваятьтә Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Шәгъбан аенда тагын ике көн ураза тот», – дип килә.

٥٦٤

عَنْ جُوَيْرِيَةَ بِنْتِ الْحَارِثِ: أَنَّ النَّبِيَّ صَلَّى اللَّهُ عَلَيْهِ وَسَلَّمَ دَخَلَ عَلَيْهَا يَوْمَ الْجُمُعَةِ وَهِيَ صَائِمَةٌ فَقَالَ أَصُمْتِ أَمْسِ قَالَتْ لَا قَالَ تُرِيدِينَ أَنْ تَصُومِي غَدًا قَالَتْ لَا قَالَ فَأَفْطِرِي

Җөвәйрия бинте Әл-Хәристән тапшырыла: «Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм аның янына җомга көнне, ул ураза тоткан вакытта килде һәм: «Син кичә дә ураза тоттыңмы?» – дип сорады. Ул: «Юк», – диде. Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Иртәгә дә ураза тотарга ниятлисеңме?» Җөвәйрия: «Юк», – диде. Шуннан соң Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Алайса, авыз ач (уразаңны туктат)», – дип әмер итте.

٥٦٥

عَنْ ابْنِ عَبَّاسٍ: قَدِمَ النَّبِيُّ صَلَّى اللَّهُ عَلَيْهِ وَسَلَّمَ الْمَدِينَةَ فَرَأَى الْيَهُودَ تَصُومُ يَوْمَ عَاشُورَاءَ فَقَالَ مَا هَذَا قَالُوا هَذَا يَوْمٌ صَالِحٌ هَذَا يَوْمٌ نَجَّى اللَّهُ بَنِي إِسْرَائِيلَ مِنْ عَدُوِّهِمْ فَصَامَهُ مُوسَى قَالَ فَأَنَا أَحَقُّ بِمُوسَى مِنْكُمْ فَصَامَهُ وَأَمَرَ بِصِيَامِهِ

Ибне Габбастан тапшырыла: «Мәдинәгә килгәч, Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм яһүдиләрнең Гашурә көнне ураза тотканнарын күрде. Ул алардан: «Нигә шулай?» – дип сорады. Алар: «Бу – изге көн, Аллаһы ул көнне Исраил уллары кавемен дошманнан коткарган һәм Муса галәйһиссәлам ул көнне ураза тота торган булган», – дип җавап бирделәр. Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм шуннан соң: «Минем Муса галәйһиссәламгә сезгә караганда хакым күбрәк!» – диде һәм бу көнне ул үзе дә ураза тота башлады, башкаларга да боерды».

# КАДЕР КИЧӘСЕ ФАЗЫЙЛӘТЛӘРЕ КИТАБЫ

## كِتَابُ فَضْلِ لَيْلَةِ الْقَدْرِ

٥٦٦

عَنْ ابْنِ عُمَرَ: أَنَّ رِجَالًا مِنْ أَصْحَابِ النَّبِيِّ صَلَّى اللَّهُ عَلَيْهِ وَسَلَّمَ أُرُوا لَيْلَةَ الْقَدْرِ فِي الْمَنَامِ فِي السَّبْعِ الأَوَاخِرِ فَقَالَ رَسُولُ اللَّهِ صَلَّى اللَّهُ عَلَيْهِ وَسَلَّمَ أَرَى رُؤْيَاكُمْ قَدْ تَوَاطَأَتْ فِي السَّبْعِ الأَوَاخِرِ فَمَنْ كَانَ مُتَحَرِّيهَا فَلْيَتَحَرَّهَا فِي السَّبْعِ الأَوَاخِرِ

Ибне Гомәрдән тапшырыла: «Пәйгамбәрнең кайбер сәхабәләренә төшләрендә Кадер кичәсе айның соңгы җиде көненең берсенә туры килүе хакында хәбәр ителде. Моны ишеткәч, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи

вә сәлләм: «Күрәм, Кадер кичәсе айның соңгы җиде көненә туры килүе хакында төшләрегез уртак, шулай булгач, бу төннең бәрәкәтенә ирешергә теләгән кеше аны соңгы җиде көндә эзләсен!» – диде».

٥٦٧

عَنْ أَبِي سَعِيدٍ الْخُدْرِيِّ: كُنْتُ أُجَاوِرُ هَذِهِ الْعَشْرَ ثُمَّ قَدْ بَدَا لِي أَنْ أُجَاوِرَ هَذِهِ الْعَشْرَ الاوَاخِرَ فَمَنْ كَانَ اعْتَكَفَ مَعِي فَلْيَثْبُتْ فِي مُعْتَكَفِهِ وَقَدْ أُرِيتُ هَذِهِ اللَّيْلَةَ ثُمَّ أُنْسِيتُهَا فَابْتَغُوهَا فِي الْعَشْرِ الاوَاخِرِ وَابْتَغُوهَا فِي كُلِّ وِتْرٍ وَقَدْ رَأَيْتُنِي أَسْجُدُ فِي مَاءٍ وَطِينٍ

Әбү Сәгыйд Әл-Хөдридән тапшырыла: «Рамазан аеның уртадагы ун көнендә Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм игътикяф кыла иде. Егерменче көн тәмамлангач, егерме беренче көннең иртәсендә ул өенә кайта иде. Көнәрдән бер көнне Рамазан аенда егерме беренче көнне ул өенә кайтмады, игътикяфен дәвам итте. Ул кешеләргә кайбер әмерләр хакында хәбәр итеп вәгазь белән мөрәҗәгать итте. Соңыннан ул: «Элек мин игътикяфне шушы ун көнне кыла идем, бүгеннән башлап мин игътикяфне Рамазан аеның соңгы ун көнендә кылачакмын. Минем белән бергә игътикяф кылган булган кешеләр үз урыннарында калсын. Дөреслектә, миңа Кадер кичәсенең кайсы көнгә туры килүе хакында хәбәр ителгән иде, ләкин мин аның кайсы көнне икәнен оныттым. Шуңа күрә аны Рамазанның соңгы ун көнендә эзләгез. Шулай ук мин үземнең былчырак һәм су эчендә сәҗдә кылуымны күргән идем», – диде. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм боларны сөйләгән көнне бик каты яңгыр яуды. Рамазан аеның егерме беренче көнендә Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм ястү намазын җитәкләгәндә мәчет түбәсеннән бик каты су акты. Иртәнге намаздан соң мин Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең маңгае былчырак һәм судан юешләнгәнен күрдем».

٥٦٨

عَنْ ابْنِ عَبَّاسٍ: الْتَمِسُوهَا فِي الْعَشْرِ الاوَاخِرِ مِنْ رَمَضَانَ لَيْلَةَ الْقَدْرِ فِي تَاسِعَةٍ تبْقَى فِي سَابِعَةٍ تبْقَى فِي خَامِسَةٍ تبْقَى

Ибне Габбастан тапшырыла: «Кадер кичәсен Рамазан аеның, ай тәмамланырга тугыз, җиде, биш көн кала, соңгы ун төнендә эзләгез».

٥٦٩

عَنْ ابْنِ عَبَّاسٍ: هِيَ فِي الْعَشْرِ هِيَ فِي تِسْعٍ يَمْضِينَ أَوْ فِي سَبْعٍ يبْقَيْنَ يَعْنِي لَيْلَةَ

Ибне Габбастан тапшырыла: «Ул (Кадер кичәсе) – Рамазан аеның (соңгы) ун төненең берсе; һәм ул йә беренче тугыз төннең берсенә, йә соңгы җиде төннең берсенә туры килә».

# ИГЪТИКЯФ КИТАБЫ

## كِتَابُ الْاِعْتِكَافِ

٥٧٠

عَنْ ابْنِ عُمَرَ: قَالَ كُنْتُ نَذَرْتُ فِي الْجَاهِلِيَّةِ أَنْ أَعْتَكِفَ لَيْلَةً فِي الْمَسْجِدِ الْحَرَامِ قَالَ فَأَوْفِ بِنَذْرِكَ

Ибне Гомәрдән тапшырыла: «Көннәрдән бер көнне Гомәр: «Җәһилият вакытында мин Әл-Харам мәчетендә төнне игътикяфтә уздырырмын дип ант иткән идем», – дигән. Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм аңа: «Үзеңнең антыңны үтә!» – дип җавап бирде».

٥٧١

عَنْ عَائِشَةَ: مَا هَذَا آلْبِرَّ تُرْوْنَ بِهِنَّ

Гайшәдән тапшырыла: «Рамазан аеның соңгы ун көнендә Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм игътикяф кыла иде. Мин аның өчен йон чатыр кордырган идем. Иртәнге намазны уздырганнан соң ул чатырына кереп китә иде. Көннәрдән бер көнне Хафса Гайшәдән үзенең чатырын кордырырга рөхсәт сорый, Гайшә рөхсәт итә. Моны күреп, Зәйнәб бинте Җәһеш тә үзенең чатырын кордыра. Бу чатырларны күреп, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Нәрсә бу? (Нинди чатырлар бу?)», – дип сорый. Аңа бу Хафса һәм Зәйнәбнең чатырлары булуын хәбәр итәләр. Шуннан ул әйтте: «Алар моны тәкъвалык күрсәткече дип уйлыйлармы?» – диде. Бу вакыйгадан соң Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм шул елның Рамазанында мәчеттә игътикяф кылудан баш тарта һәм шәүвәл аеның ун көнендә игътикяф кыла».

٥٧٢

عَنْ عَائِشَةَ: أَنَّ النَّبِيَّ صَلَّى اللَّهُ عَلَيْهِ وَسَلَّمَ أَرَادَ أَنْ يَعْتَكِفَ فَلَمَّا انْصَرَفَ إِلَى الْمَكَانِ الَّذِي أَرَادَ أَنْ يَعْتَكِفَ إِذَا أَخْبِيَةٌ خِبَاءُ عَائِشَةَ وَخِبَاءُ حَفْصَةَ وَخِبَاءُ زَيْنَبَ فَقَالَ آلْبِرَّ تَقُولُونَ بِهِنَّ ثُمَّ انْصَرَفَ فَلَمْ يَعْتَكِفْ حَتَّى اعْتَكَفَ عَشْرًا مِنْ شَوَّالٍ

Гайшәдән тапшырыла: «Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм игътикяф кылырга теләп, мәчеткә юнәлә, ләкин игътикяф кыла торган урынга килеп җиткәч, анда чатырлар корылганын күрә: Гайшә, Хафса һәм Зәйнәбнең чатырлары. Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Сез моны тәкъвалык күрсәткече дип уйлыйсызмы?» – дип сорый. Шуннан соң ул Рамазан аенда игътикяф кылып тормыйча, шәүвәл аеның соңгы ун көнен игътикяфтә уздыра».

٥٧٣

عَنْ صَفِيَّةَ: أَنَّهَا جَاءَتْ إِلَى رَسُولِ اللَّهِ صَلَّى اللَّهُ عَلَيْهِ وَسَلَّمَ تَزُورُهُ فِي اعْتِكَافِهِ فِي الْمَسْجِدِ فِي الْعَشْرِ الأَوَاخِرِ مِنْ رَمَضَانَ فَتَحَدَّثَتْ عِنْدَهُ سَاعَةً ثُمَّ قَامَتْ تَنْقَلِبُ فَقَامَ النَّبِيُّ صَلَّى اللَّهُ عَلَيْهِ وَسَلَّمَ مَعَهَا يَقْلِبُهَا حَتَّى إِذَا بَلَغَتْ بَابَ الْمَسْجِدِ عِنْدَ بَابِ أُمِّ سَلَمَةَ مَرَّ رَجُلَانِ مِنَ الأَنْصَارِ فَسَلَّمَا عَلَى رَسُولِ اللَّهِ صَلَّى اللَّهُ عَلَيْهِ وَسَلَّمَ فَقَالَ لَهُمَا النَّبِيُّ صَلَّى اللَّهُ عَلَيْهِ وَسَلَّمَ عَلَى رِسْلِكُمَا إِنَّمَا هِيَ صَفِيَّةُ بِنْتُ حُيَيٍّ. فَقَالا: سُبْحَانَ اللَّهِ يَا رَسُولَ اللَّهِ، وَكَبُرَ عَلَيْهِمَا. فَقَالَ النَّبِيُّ صَلَّى اللَّهُ عَلَيْهِ وَسَلَّمَ: إِنَّ الشَّيْطَانَ يَبْلُغُ مِنَ الإِنْسَانِ مَبْلَغَ الدَّمِ وَإِنِّي خَشِيتُ أَنْ يَقْذِفَ فِي قُلُوبِكُمَا شَيْئًا

Сафийййәдән тапшырыла: «Көннәрдән бер көнне Расулүллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм Рамазан аеның соңгы ун көнендә мәчеттә игътикяф кылганда, ул аның хәлен белергә килде. Күпмедер вакыт сөйләшкәч, ул кайтып китәргә теләп урыныннан кузгалды, Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм исә аны озатырга чыкты. Өмме Сәләмәнең ишеге янында булган мәчет капкасына килеп җиткәч, әнсарлардан булган ике ир узып барышлый Пәйгамбәргә сәлам бирде. Пәйгамбәр аларга: «Ашыкмагыз, бу – Сафия бинте Хөйәй», – дип әйтте. Алар: «Сөбехәналлаһ, йә Аллаһының Расүле!» – диделәр. Бу алар өчен авыр булды. Шунда Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Дөреслектә, шәйтан кешенең тәненә үтеп кереп, аның кан тамырлары аша хәрәкәт итә. Мин ул сезнең күңелләрегезгә берәр начар уй салыр дип курыктым!» – дип әйтте».

*«Зубдатуль-Бухари» хәдисләр җыентыгыннан*

# Тәфсир

# Юныс галәйһиссәлам кыйссасы

Юныс галәйһиссәлам Нәйнәвәдә – Ассирия дәүләтенең башкаласында Тигр елгасы яр буенда, хәзерге Мосул шәһәрендә туып үсә. Кавемдәшләре арасында ул ышанычлы, намуслы, әхлаклы һәм ярдәмчел булганга, олы хөрмәт казана. Әмма балык тарафыннан йотылуы белән, «Зәннүн» һәм «Сәхибел-Хүт» дигән исемнәр белән таныла.

30 яшендә Юныс галәйһиссәлам үзенең потларга табынучы халкына пәйгамбәр итеп җибәрелә. 33 ел дәвамында ул бертуктаусыз кавемдәшләренә дәгъват кыла, иманга килергә өнди, әмма нәйнәвәлеләр аның сүзләренә колак салмый, көлә генә. Юныс галәйһиссәлам артыннан ике генә кеше иярә.

– Өч көн эчендә Раббым сезнең өскә җәза җибәрәчәк, – дип, ул үз халкын Аллаһыдан алган хәбәр белән кисәтеп куя. – Бит-йөзләрегез саргаячак, соңыннан Яратучыдан җәза да киләчәк.

Шулай дип әйтеп, Юныс галәйһиссәлам җәзадан үзе дә куркып, туган шәһәрен ташлап, качарга ашыга. Әмма Аллаһыдан моңа рөхсәт алмый.

Нәйнәвә халкын тиздән, Юныс галәйһиссәлам әйткәнчә, коточкыч дәһшәт камап ала: күк йөзен кара төтен каплый, ә кешеләрнең йөзләре саргая башлый. Алар пәйгамбәр әйткән сүзләрнең һәм якынлашып килә торган җәзаның хакыйкать булганына инана. Өсләренә һәлакәт килүен аңлап, нәйнәвәлеләр Юныс галәйһиссәламне эзләргә тотына. Әмма юкка – ул шәһәрдә булмый инде.

## Нәйнәвәлеләрнең бергәләп тәүбә кылулары

Аллаһы Тәгалә олы куркуда һәм өметсезлектә калган Нәйнәвә кешеләренең йөрәкләренә тәүбә сала. Аның кисәтеп куелган җәзасы килеп җитүгә тагын ике көн бар иде, шуңа халык бергә җыелып Аллаһыдан котылу чарасын сорап, ялгышлыкта яшәүләре өчен гафу үтенеп тәүбә кы-

лыргa булалар. Шулай итәләр дә. Кавем тауга менеп Яратучының Барлыгына һәм Берлегенә, Аның расүле Юныс галәйһиссәламгә иман китерә һәм бер-берсенең дә үпкә-ачуларын гафу итәләр. Ирләр һәм хатын-кызлар, балалар һәм яшьләр – барысы бергә Аллаһыга ялваралар һәм күз яшьләренә йотылып, ихластан Аннан гафу сорыйлар.

Аллаһы – Рәхимле һәм Гафү итүче. Ул башлыксыз калган кавемне дә кичерә – пәйгамбәр үз халкын ташлап китә, ә Раббыбыз аның тәүбәләрен кабул итә. Кешелек тарихында, Юныс галәйһиссәлам кавеме тәүбә иткән һәм һәлакәттән сакланып калган бердәнбер халык булып кала. Аллаһы Коръәндә болай дип әйтә:

فَلَوْلَا كَانَتْ قَرْيَةٌ آمَنَتْ فَنَفَعَهَا إِيمَانُهَا إِلَّا قَوْمَ يُونُسَ لَمَّا آمَنُوا كَشَفْنَا عَنْهُمْ عَذَابَ الْخِزْيِ فِي الْحَيَاةِ الدُّنْيَا وَمَتَّعْنَاهُمْ إِلَىٰ حِينٍ ﴿٩٨﴾

> **«[Һәлакәткә дучар ителгән өммәтләр арасында] Юныс галәйһиссәламнең кавеменнән тыш, [газапны күргәннәреннән соң] иман китереп тә, иманнары аңа файда биргән бер [генә булса да] сала [халкы] булдымы соң? Алар [газап галәмәтләрен күргәннән соң] иман китергәч, Без алардан дөнья тормышында хурлык газабын алдык һәм аларны [Безгә мәгълүм] бервакытка кадәр [дөнья нигъмәтләреннән файдаландырдык».**

«Юныс», 10:98

Гөнаһлар афәткә, бәла-казаларга илтә, тәүбә исә коткарып кала. Мисал өчен, Аллаһы Расүле салләллаһу галәйһи вә сәлләм бер хәдисендә болай дип әйткән: «Раббысына истигъфар кылган бәндә җәзага тартылмаячагына ышана ала». Йөрәктән чыккан дога һәм ихлас күңелдән кылынган тәүбә теләсә нинди бәла-казадан коткарырга сәләтле. Әгәр дә афәт тулы бер кавемгә һөҗүм итсә, гафу сорауны бөтен халык, җәмәгать белән ялварырга кирәк.

## Җирәбә Юныс галәйһиссәламгә чыга

Юныс галәйһиссәлам, үз халкын калдырып киткәч, диңгез ярына кадәр барып җитә дә, бер корабка утырып, диңгезгә чыга. Беркадәр ара барганнан соң, кораб кинәт туктый, көчле җил күтәрелә, давыл башлана. Кораб менә-менә батар кебек була. Аны хәрәкәткә китерә алмаган диңгезчеләр, моны начар билге дип кабул итәләр һәм араларында җинаятьче бардыр дип уйлыйлар.

Диңгезчеләр корабта булган барлык кешене җыеп: «Сезнең арагызда хуҗасыннан качкан кол бар. Ул алга чыксын», – дип әйтәләр. Әмма берсе дә үз-үзен танытмый, шуңа күрә җирәбә салу турында карар кабул ителә. Ул вакытта диңгезчеләрнең шундый йоласы була: кораб үз юлын дәвам итә алсын өчен, җирәбә төшкән кешене диңгезгә ташлыйлар.

Җирәбә уйнатыла. Һәм ул Юныс галәйһиссәламгә чыга.

«Мондый хөрмәтле кеше кол була алмый», – дип карар чыгарып, диңгезчеләр гафу үтенеп, янә җирәбә уйнаталар. Бу юлы да, өченче тапкырда да җирәбә барыбер Юныс галәйһиссәламгә чыга. Бу хакта Коръәндә болай дип әйтелә:

فَسَاهَمَ فَكَانَ مِنَ الْمُدْحَضِينَ ﴿١٤١﴾

**«[Диңгезгә ыргытыласы кешене билгеләргә] Шобага тартты һәм оттырганнардан булды».**

«Саффәт / Сафта торучылар», 37:141

Өченче тапкыр уйнатылган җирәбәнең аңа төшүен күреп, Юныс галәйһиссәлам бу сынауның Аллаһыдан булуын аңлый һәм: «Мин – үз Хуҗамнан качкан колмын», – дип диңгезгә ташлана.

## Юныс галәйһиссәлам балык карынында

Юныс галәйһиссәлам тәвәкәлләп диңгезгә ташлана һәм Аллаһының рәхмәте белән аны шунда ук зур балык йота. Әлеге мизгелдә Аллаһы Тәгалә балыкка шундый мөмкинлек бирә ки, йоткан вакытта Юныс галәйһиссәламгә бернинди зыян килми, хәтта сөякләре дә сынмый. Балык, Юныс галәйһиссәламне йотып, диңгез төбенә төшеп югала.

فَالْتَقَمَهُ الْحُوتُ وَهُوَ مُلِيمٌ ﴿١٤٢﴾

**«[Диңгезгә ыргытылгач] Аны балык йотты. Ул [үзен] әрләгән бер кеше иде».**

«Саффәт / Сафта торучылар», 37:142

Шулай итеп, Юныс галәйһиссәлам бернинди зыян күрмичә һәм үз аңында булып балык карынында кала. Аның өчен барысы да көн кебек ачык була: үз халкын рөхсәтсез калдырганга күрә бу вакыйгалар аңа илаһи кисәтү буларак җибәрелә.

Юныс галәйһиссәлам үз хатасын аңлап, дөм караңгыда – балык карынында утырып Аллаһыны зикер итә:

وَذَا النُّونِ إِذ ذَّهَبَ مُغَاضِبًا فَظَنَّ أَن لَّن نَّقْدِرَ عَلَيْهِ فَنَادَىٰ فِي الظُّلُمَاتِ أَن لَّا إِلَٰهَ إِلَّا أَنتَ سُبْحَانَكَ إِنِّي كُنتُ مِنَ الظَّالِمِينَ ﴿٨٧﴾

**«[Расүлем!] Балык иясен дә [искә ал]! Менә ул [Юныс галәйһиссәлам] ярсыган хәлдә [кавемен ташлап] киткән иде дә, Без, аңа каршы хөкем бирмәячәкбез дип, санаган иде. [Утырган бер көймәдә, шобага нәтиҗәсендә, диңгезгә ыргытылуыннан соң аны йоткан балык эчендәге] Караңгылыклар эчендә: «Синнән башка һичбер илаһ юк! Син пакь! Һичшиксез, мин залимнәрдән булдым!» – дип дәште».**

«Әл-Әнбия / Пәйгамбәрләр», 21:87

Коръәндә шулай ук Юныс галәйһиссәламнең әлеге догасы кабул булуы һәм Аллаһының аны гафу итүе әйтелә:

فَاسْتَجَبْنَا لَهُ وَنَجَّيْنَاهُ مِنَ الْغَمِّ ۚ وَكَذَٰلِكَ نُنجِي الْمُؤْمِنِينَ ﴿٨٨﴾

**«Без аңа җавап бирдек һәм аны [йоткан балыкка: «Бераздан аны диңгез ярына илтеп чыгар!» – дип әмер итеп] хәсрәтеннән коткардык. Мөэминнәрне дә шулай коткарырбыз».**

«Әл-Әнбия / Пәйгамбәрләр», 21:88

Шушы тәсбих, Юныс галәйһиссәламнең алдагы тормышында әйтелгән бик күп башка зикерләре кебек үк, күкләргә аша. Үз гомерендә ул Аллаһы Тәгаләне бихисап зикер кылганга күрә, фәрештәләр хәтта аның тавышын да белгәннәр. Бу юлы да алар Юныс галәйһиссәламне тавышыннан танып, болай диләр: «Ий Раббыбыз! Бу Юныс галәйһиссәламнең тавышы түгелме? Син һәрвакыт аңа рәхмәтле булдың, бу юлы аны бәладән коткармассыңмы?»

Нинди гаҗәп! Җирдә яшәүчеләрнең берсе дә Юныс галәйһиссәламгә ярдәм итә алмый, чөнки аның кайда булуын да белмиләр, ләкин аңа ярдәмгә күк ияләре үзләре үк ашыга! Һәм Аллаһы балыкка, Юныс галәйһиссәламне ярга чыгарырга әмер биреп, аны коткара.

Бу күренештә Яратучыбызның бөек хикмәте ята: пәйгамбәрне үзенең имин көннәрендә күп тапкырлар әйткән зикерләре коткара. Даими рәвештә Аллаһыга рәхмәтеңне, яратуыңны һәм Аңа бар яктан бирелгәнлегеңне белдереп ихластан зикер әйтү кешене киләчәктә күпләгән авырлыклардан һәм бәлаләрдән коткара ала.

Аллаһы Тәгалә Коръәндә болай дип әйтә:

فَلَوْلَا أَنَّهُ كَانَ مِنَ الْمُسَبِّحِينَ ﴿١٤٣﴾ لَلَبِثَ فِي بَطْنِهِ إِلَىٰ يَوْمِ يُبْعَثُونَ ﴿١٤٤﴾

**«Әгәр дә ул [тыныч чорда Аллаһыны күп зикер итеп] тәсбих итүчеләрдән булмаса. Алар терелтеләчәк көнгә кадәр аның карынында көтәчәк [һәм бөтен кеше кабереннән чыккан вакытта, ул балыкның карыныннан терелтеләчәк] иде».**

«Саффәт / Сафта торучылар», 37:143-144

Әлеге аять ачыктан-ачык рәвештә бәхетле-имин вакытта Аллаһыны зикер кылучыга авыр мәлдә, һичшиксез, ярдәм булачагын күрсәтә.

Төрле риваятьләр буенча, Юныс галәйһиссәлам балык карынында өч, җиде яки кырык көн булган, дип әйтелә. Ул балык карыныннан мөхәррам аеның унынчы көнендә (Гашурә көнендә) чыккан.

Балык Юныс галәйһиссәламне яр буена чыгаргач, ул Аллаһы Тәгаләгә үзенең котылуы өчен чиксез рәхмәтләрен әйтергә тотына. Кәлам Шәрифтә Юныс галәйһиссәламнең котылуы турында түбәндәгеләр әйтелә:

فَنَبَذْنَاهُ بِالْعَرَاءِ وَهُوَ سَقِيمٌ ﴿١٤٥﴾ وَأَنبَتْنَا عَلَيْهِ شَجَرَةً مِّن يَقْطِينٍ ﴿١٤٦﴾

**«Ул авыру хәлдә булганда, Без аны буш бер җиргә ташладык. Һәм [ябырылган черкиләрдән, кояш кызулыгыннан саклау өчен] аның өстенә [киң яфраклы] кабак агачы үстердек».**

«Саффәт / Сафта торучылар», 37:145-146

Юныс галәйһиссәлам балык карыныннан чыгып котылганда бик ябыккан, бетәшкән, хәлсез һәм ярдәмгә мохтаҗ булган. Аллаһы Тәгалә аның янәшәсенә зур һәм киң яфраклы үсемлек үстерә, әнә шулай итеп аны кояш эссесеннән һәм чебен-черкиләрдән саклый.

Бер риваятьтә әлеге үсемлек сөт бүлеп чыгарган, аның белән Юныс галәйһиссәлам тукланган дип әйтелә. Башка бер риваятьтә Аллаһы Тәгалә Юныс галәйһиссәламгә тау кәҗәсен буйсындыруы, аның иртән һәм кич килеп, пәйгамбәргә үзенең сөтен биргәнлеге хакында искә алына.

Хәлсезлектән котылгач һәм көч җыйгач, Юныс галәйһиссәлам гыйбадәт кылырга керешә. Ул Аллаһы Тәгаләгә түбәндәге дога белән мөрәҗәгать итә: «Ий Раббым! Барлык әмерләр һәм карарлар Синнән генә. Әмма мин бик тә Нәйнәвәгә кайтырга һәм үземнең иман китергән халкымны күрергә өметләнәм. Моның белән беррәттән, мин Синең һәрбер карарларың белән риза булачакмын».

Һәм Аллаһы аңа үз халкын хакыйкатькә чакыру бурычын янә йөкли.

Габдулла бине Габбас радыяллаһу ганһедән килгән риваятьтә хәбәр ителгәнчә, Юныс галәйһиссәлам йөз егерме мең кешене тәшкил иткән халыкка пәйгамбәр сыйфатында җибәрелгән. Әлеге халыкның саны турында Коръәндә болай дип әйтелә:

وَأَرْسَلْنَاهُ إِلَىٰ مِائَةِ أَلْفٍ أَوْ يَزِيدُونَ ﴿١٤٧﴾ فَآمَنُوا فَمَتَّعْنَاهُمْ إِلَىٰ حِينٍ ﴿١٤٨﴾

**«Без аны [сәламәтләндереп, рөхсәтсез ташлап киткән] йөз меңгә [кабат] җибәрдек, яки алар [күрер күзгә] күбрәкләр иде. [Газапның билгеләрен күргәннән соң] Алар иман китерделәр, Без исә аларны [әҗәлләре хакында әзәлдә билгеләнгән] бервакытка кадәр яшәттек».**

«Саффәт / Сафта順 торучылар», 37:147-148

Юныс галәйһиссәлам үз кавемен гөнаһлардан ярлыкау сораган, Аллаһыга иман китергән һәм аның кайтуын көткән хәлдә таба. Ул халык белән бергә-бер калып, аларны Раббыбызның әмерләрен һәм тыюларын үтәргә өйрәтә һәм аларны үз артыннан хакыйкый юлдан алып бара. Кавемдәшләре бернинди тайпылусыз аның артыннан иярәләр һәм иң яхшы рәвештә барлык дини кануннарны үтиләр.

Юныс галәйһиссәламнән соң да Аллаһы Тәгалә Нәйнәвә халкына туры юлдан барган вакытта күпләгән бәрәкәтләр бирә. Озак еллар алар сәгадәттә һәм иминлектә яшиләр.

Әлеге нәсыйхәтнең хикмәте шунда ки, хакыйкатькә чакыручылар, төрле нахак бәлаләр тагуларына да карамастан, сабыр булырга тиешләр, чөнки кешеләр үзләренең адашуларында нык торырга һәм авырлыклар китерергә мөмкиннәр. Һәрбер кеше моның белән очрашкан. Бары сабыр итеп һәм ныклык күрсәтеп кенә башка кешеләрнең күңелләренә илтә торган юл ачыла, чөнки тырышлык бездән, ә уңыш – Аллаһыдан. Иманга чакыру һәм начарлыкны кире кагу гамәлен ташлап өметен югалтканнарны Аллаһы ничек җәзага тартасын кем дә булса беләме? Аллаһы мондый җәзалардан Үзе сакласын!

*Камил хәзрәт Сәмигуллин,*

*Татарстан Республикасы мөфтие*

# Коръән сүрәләре

### 68. Әл-Каләм (Каләм) сүрәсе

Мәккә чоры, 52 аять

Рәхимле һәм шәфкатьле Аллаһы исеме белән!

1. **Нун.** [Ләүхүл-Мәхфүзнең һәм фәрештәләрнең] **Каләм белән һәм алар язган нәрсәләр белән ант итәмен!**
2. [Расүлем!] **Раббыңның** [сиңа насыйп иткән көчле акыл, пәйгамбәрлек, камиллек, кебек] **рәхмәте сәбәпле, син тиле түгелсең.**
3. **Һичшиксез,** [мөшрикләрдән күргән авырлыкларга җавап итеп] **сиңа төкәнмәс әҗер бар.**
4. **Һәм син, һичшиксез, югары әхлак иясе.** [Олуг пәйгамбәрләр кебек, син дә чыдый алмаслык михнәтләрне кичерәсең].
5. **Тиздән син дә күрәчәксең, алар да.**
6. **Кайсыгыз** [синме, алармы] **шашканлыкны.**
7. **Һичшиксез, синең Раббың Аның юлыннан язган** [һәм чын мәгънәсендә акылын югалткан] **кешеләрне яхшырак белә. Янә Ул һидаять тапкан** [акыллы] **кешеләрне дә яхшырак белә.**
8. [Расүлем!] **Шуңа күрә ялганда гаепләүчеләргә** [бераз – Аллаһы Тәгаләгә, бераз потларга гыйбадәт кылуны тәкъдим итүчегә] **буйсынма.**
9. **Алар синең күндәм булуыңны теләрләр, алар да күндәм булырлар иде.**
10. [Расүлем!] **Һичбер күпләп ант итүчегә, түбән булганга буйсынма.**[1]
11. [Һәркемне] **Хурлаучыга,** [бозык уйлар белән] **сүз йөртүчегә** [дә буйсынма].
12. [Һәм, шулай ук] **Игелеккә киртә салучыга, дошманга, гөнаһлыга.**
13. **Дорфага, җитмәсә, зинадан туганга.**
14. **Ул кеше мал һәм ир балаларга ия булса да** [аңа иярмә].

---

1 Галимнәрнең уртак фикерләренчә, 10 нчы-17 нче аяте кәримәләрдә тасвирланган кеше – Вәлид бине Могыйра. Ул ун улына да: «Арагыздан Ислам динен кабул итүчегә ярдәмемне туктатам», – дип янаган дорфа, залим, кансыз һәм холыксыз кеше булган. Ул үзе дә монда әйтелгән ун сыйфатның тугызын кабул иткән. Ләкин зинадан туган икәнен бу аятьләр килгәнче белмәгән булган. Бу хәбәрне ишеткәннән соң, әнисенә барып: «Мөхәммәд мине тасвирлаганда зинадан туганлыгымны әйтте. Мин моны белми идем. Йә син миңа дөресен әйтәсең, йә башыңны чабып өзәрмен!» – дигәч, әнисе: «Син атаң дип белгән кеше бай һәм кысыр иде. Мин, ул үлеп китсә, малы чит кешегә калмасын өчен, бер көтүче белән зина кылдым, менә син шул көтүчедән тудың», – дигән (Нәсәфи, Бәйдави).

15. **Аңа Безнең аятьләребез укылган чакта, ул: «Әүвәлгеләрнең** [уйлап чыгарып] **язган хикәяләре генә», – дип әйтә.**
16. **Без аның** [фил] **борынын** [бер билге белән] **тамгалаячакбыз** [һәм йөзенең каралыгы һәркемгә күренеп торачак]**.**
17. **Һичшиксез, Без бакча ияләрен сынаганыбыз кебек, аларны да** [синең бәддогаң сәбәпле, кытлык белән] **сынадык. Менә алар** [бакча хуҗалары] **иртә җитүгә тулысынча аны** [җимешләрне] **җыеп алачакларына ант иттеләр.**
18. **Алар** [«ИншәАллаһ», – дип] **өстәп әйтмәделәр.**[1]
19. **Алар йоклаган вакытта Раббыңнан уратып ала торган бер бәла аны йөреп чыкты.**
20. **Иртән кисеп ташланган кебек булды.**
21. **Алар иртән бер-берсенә дәштеләр.**
22. **«Бакчагызга барыгыз, әгәр уңыш җыярга җыенган кешеләр булсагыз** [ашыгыгыз, эшегез тизрәк бетсен]**».**
23. **Алар, әкрен генә сөйләшә-сөйләшә, анда кузгалдылар.**
24. **«Бүген бер генә фәкыйрь дә сезгә кермәсен».**
25. **Көчле икәнлекләрен санап, иртән юлга чыктылар.**
26. **Әмма аны** [янган-һәлак булган хәлдә] **күргәч, әйттеләр: «**[Безнең бакчабыз түгел!] **Без** [килгәндә] **юлдан язганбыз.**
27. **Юк!** [Бу безнең бакчабыз!] **Без мәхрүм ителдек!»**
28. **Араларындагы иң уртачалары: «Мин сезгә тәсбих итәргә кирәк», – димәгән идемме?» – диде.**
29. **Алар: «Аллаһы пакь!** [Ул безгә золым эшләмәде]**. Һичшиксез, без** [үз-үзләребезгә] **золым эшләдек», – диделәр.**
30. **Алар бер-берсен шелтәли башладылар.**
31. **Әйттеләр: «Ни үкенеч безгә! Без** [Аллаһының хөкемнәренә карата] **чиктән ашкан кешеләр булдык.**
32. **Бәлки, Раббыбыз безгә моның урынына моннан да яхшырагын бирер. Һичшиксез, без Раббыбызга кайтабыз».**
33. [Безнең Мәккә халкына җибәргән] **Газап шундый. Ахирәт газабы**

---

1 Риваятьтән күренгәнчә, Сангага ике фәрсәхлек арада яшәгән изге бер кеше, бакчасындагы уңышны җыяр вакыт җиткәч, киселми калган яки җил очырган, яки агач астына җәелгән япмадан читкә төшкән хөрмәләрнең барысын да ярлыларга бирә торан булган, шулай итеп ярлыларның бик күп ихтыяҗы канәгатьләндерелә торган булган. Ул зат үлеп киткәч, уллары: «Бала-чагабыз бик күп, әгәр дә атабыз кебек эшли башласак, безгә авырга киләчәк. Шуңа күрә фәкыйрьләр уянып килеп җиткәнче, иртән иртәрәк торып, хөрмәне җыеп алыйк», – дип ант иткәннәр. Шуннан соң алдагы аяте кәримәләрдә аңлатылган вакыйгалар булган (Алуси).

**исә моннан да зуррак. Әгәр белсәләр иде.**

34. **Һичшиксез, тәкъва иясе коллар өчен Раббылары хозурында нигъмәтләр белән тулы җәннәтләр бар.**
35. **Без мөселманнарны гөнаһлылар кебек итәрбезмени?**
36. **Ни булды сезгә? Ничек** [болай ялгыш] **хөкем бирәсез?**
37. **Әллә сезнең** [күктән иңгән] **китабыгыз бармы һәм шуннан укыйсызмы?**
38. **Һичшиксез, сез сайлаган нәрсәләр анда сезнең өчен дип** [укыйсызмы?]
39. **Әллә сездә Безнең Кыямәт көненә кадәр дәвам итәчәк** [һәм ул көнне] **үзегез карар биргән нәрсәләр сезнеке булачак дигән антларыбыз бармы?**
40. **Кайсысы бу мәсьәләдә кәфил булганын син алардан сора.**
41. **Әллә аларның фикердәшләре бармы? Алайса фикердәшләрен китерсеннәр, әгәр дә тугры кешеләр булсалар.**
42. [Эшнең читенлеге сәбәпле] **Авырлык киләчәк һәм сәҗдәгә чакырылачаклар, ләкин** [моңа башкарырга] **көч таба алмаячаклары көнне** [беркайчан исеңнән чыгарма]**.**
43. [Күргән дәһшәтләре сәбәпле] **Күтәрелеп карый алмаячаклар, аларны хурлык каплап алачак. Югыйсә алар сәламәт чакта сәҗдәгә чакырылганнар иде инде.**
44. **Мине бу сүзне ялган дип санаганнар белән бергә** [ялгыз] **калдыр. Һичшиксез, Без аларны сизмәгән якларыннан акрынлап һәлакәткә якынайтырбыз.**
45. **Мин аларга кичектерү бирәмен. Минем тотып алуым бик каты бит.**
46. [Расүлем!] **Әллә син алардан бер түләү сорыйсыңмы да, алар, шул сәбәпле, өсләренә бурычлар алалармы?**
47. **Әллә гаибкә ияләр дә** [кешеләргә мәшруг иткән уйдырма тәртипләрен аңардан күчереп] **язалармы?**
48. **Раббыңның хөкеменә сабыр ит һәм балыкның юлдашы** [Юныс [галәйһиссәлам] **кебек булма. Менә ул** [балыкның карынына эләккәч, иман китермәгән кавеменә карата] **борчулы бер хәлдә** [Раббысына] **мөрәҗәгать итте.**
49. **Әгәр дә аңа Раббыңнан бер нигъмәт ирешмәгән булса, ул хур ителгән буларак** [агачлар да, үләннәр дә үсмәгән] **буш бер җиргә**

**чыгарып атылган булыр иде.**[1]

50. **Раббысы аны сайлады һәм аны** [күркәм сыйфатларга ия булган] **изге кешеләрдән итте.**
51. **Һичшиксез, кяферләр зикерне ишеткән вакытларында күзләре белән сине** [урыныңнан] **тайдырырга әзерләр, һәм алар** [Коръәндә булган гыйлемнәрне аңламаганнары өчен, синең хакта бер карарга килә алмыйча]**: «Һичшиксез, ул бит – тиле кеше!» – дип әйтәләр.**
52. **Хәлбуки, ул** [Коръән] **– бөтен галәмнәр өчен** [Аллаһы Тәгаләдән] **бер үгет.**[2]

## 69. Әл-Хәкка (Котылгысыз) сүрәсе

Мәккә чоры, 52 аять

Рәхимле һәм шәфкатьле Аллаһы исеме белән!

1. [Җитәчәге] **Хак булган Вакыт!**
2. **Нәрсә ул хак булган Вакыт?**
3. **Хак булган вакытның ни икәнен син каян белә аласың?**
4. **Сәмуд һәм гад кавемнәре** [галәмнәрне һәм кешеләрне] **һәлак иткән вакыйганы** [Кыямәтне] **ялган дип санадылар.**
5. **Сәмудка килгәндә, алар чиктән ашкан бер вакыйга белән һәлак ителделәр.**
6. **Гад** [кавеме] **исә каты искән бик салкын давыл белән һәлак ителде.**
7. **Ул** [Раббылары] **бер-бер артлы җиде төн, сигез көн буена котырырга ирек бирде. Син анда** [булсаң] **ул кавемнең эче буш хөрмә агачы кәүсәләре кебек җиргә түшәлгәннәрен күрер** [идең].
8. **Алардан калган берәр кешене күрәсеңме?**
9. **Фиргавен дә, аңардан алда булганнар да,** [Лутның [галәйһиссәлам]

1 Бу турыда тулырак «Юныс» сүрәсендә карагыз.

2 Бу аяте кәримәләр күз тиюнең хак булганына һәм Аллаһының рөхсәте белән тәэсир иткәненә дәлил булып торалар. Күз тию дөяне – казанга, кешене кабергә кертерлек тәэсирле булганын белдергән сахих хәдис-шәрифләр дә бар. Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм заманында Әсәд уллары дип беленгән бер кабиләнең күзе бик каты булган. Алардан берәрсе өч көн ач калып, шуннан соң берәр нәрсәгә күз тидерсә һәм: «Шундый бернәрсә күрмәдем!» – дип әйтсә, ул әйбер тулысынча һәлак була торган булган. Мөшрикләр аларның берсен Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә алып килеп бу сүзне әйттерсәләр дә, Аллаһы Тәгалә сөекле Пәйгамбәрен күз тиюдән саклаган (Бәйдави, Нәсәфи, Хазин).

**асты өскә әйләндерелгәннәре дә** [шәһәрләре бөтенесе] **гөнаһ кылдылар.**

10. **Алар Раббыларының расүленә баш күтәрделәр, һәм Ул аларны каты бер тотып алу белән тотып алды.**
11. [Нух [галәйһиссәлам] **Су ташыгач** [һәм иң биек тауның түбәсеннән дә унбиш терсәк кадәр күтәрелгәч], **Без сезне су өстендә йөргән көймәдә йөрттек.**
12. **Аны сезгә** [бар итүченең югары көчен күрсәтеп торган] **бер гыйбрәт итик, һәм истә калдыра алган колаклар аны исендә калдырсын дип** [болай иттек].
13. **Сурга бер мәртәбә өрү белән** [тәүге кат] **өрелгәч.**
14. **Җир һәм таулар** [илаһи бер кодрәт белән] **күтәрелгәч, аннары икесе дә берьюлы** [бер-берсенә] **бәрелеп төп-төз ителгәч.**
15. **Шул көнне барлыкка киләчәк Вакыйга җитәчәк.**
16. **Күк тә ярылачак,** [бүген төзек күренүенә карамастан] **ул көнне зәгыйфь** [һәм менә-менә төшеп китәрдәй бер хәлдә] **булачак.**
17. **Фәрештәләр аның читләре буйлап булачаклар. Раббыңның Гарешен алар өстеннән сигез** [фәрештә] **күтәреп барачак.**
18. **Ул көнне** [хисап бирер өчен, Аллаһы Тәгаләнең хозурына] **чыгачаксыз, сездә бер генә сер дә яшерен калмаячак.**
19. **Китабы уң кулына бирелгән кеше** [куанычыннан иптәшләренә борылып] **әйтер: «Алыгыз китабымны, укыгыз** [эчендәге изге гамәлләрне күрегез].
20. **Һичшиксез, мин хисабым белән очрашуымны белә идем».**
21. **Һәм ул рәхәт тормыш эчендә.**
22. **Биек бер җәннәттә.**
23. **Җимешләре исә** [хәтта ятып торучыга да үрелеп кенә өзеп алырлык] **якын.**
24. [Ул көнне аларга] **«Элекке** [дөнья] **көннәрдә кылган** [яхшы] **нәрсәләрегез өчен, тынычлык белән ашагыз һәм эчегез!»** [дип әйтеләчәк].
25. **Кемгә исә китабы сул кулына бирелә, ул** [дәфтәрендәге начар гамәлләрне күреп] **әйтер: «Аһ, миңа китабым бирелмәсә иде!**
26. **Хисабымның нәрсәлеген белмәсәм иде!**
27. **Аһ, бу** [дөньяда татыган үлемем] **соңгы нәрсә булса иде** [дә кабат терелтелмәсә идем].
28. **Малым мине коткармады.**

29. **Хакимлегем** [кешеләргә тәэсир итәрлек кодрәтем] **миннән югалды** [һәм мин түбән бер хәлдә калдым]**».**
30. [Аллаһы Тәгалә җәһәннәм сакчыларына әйтер] **«Тотыгыз да шуны богаулагыз!**
31. **Шуннан соң аны Утка ташлагыз!**
32. **Шуннан соң аны җитмеш терсәклек чылбыр белән урагыз».**
33. **Чөнки ул бөек булган Аллаһыга ышанмый иде.**
34. [Ахирәткә ышанмаганы өчен, савап өмет итмәгәнлегеннән] **Мескенне ашатырга** [үзе дә бармаганы кебек, теләге булган кешене] **дә** [игелеккә] **өндәмәде.**
35. **Аңа бүген монда дус юк.**
36. **Эрен һәм каннан башка ашамлык та юк.**
37. **Аны гөнаһлылардан башка, беркем дә ашамаячак.**
38. **Әйе!** [Җир, күк кебек] **Сез күрә алган нәрсәләр белән ант итәмен.**
39. **Һәм** [фәрештәләр, рухлар кебек] **сез күрә алмаган нәрсәләр белән дә** [ант итәмен]**.**
40. **Һичшиксез, ул** [Коръәни Кәрим Расүлем һәм Җәбраил [галәйһиссәлам] кебек Аллаһы өчен] **бик хөрмәтле-шәрәфле бер илченең** [ирештергән] **сүзе.**
41. **Шагыйрь сүзе түгел бу** [Коръән]**.** [Чамасыз үҗәтлегегез сәбәпле күбесен инкяр итсәгез дә] **Сез аз иман китерәсез!**
42. **Һәм** [ул кайчакларда сез уйлаган кебек] **күрәзәче сүзе дә түгел. Аз уйлыйсыз шул!**
43. [Ул] **Галәмнәрнең Раббысыннан иңдерелгән.**
44. **Әгәр ул** [Расүлем Безнең тарафтан аңа вәхи килмичә] **Безгә карата нинди дә булса сүзләр уйлап чыгарган булса иде.**
45. **Без аның уң кулын тотар идек.**
46. **Шуннан соң шаһ тамырын ярыр идек.**
47. **Шулвакыт сезнең арагыздан аны берәү дә коткара алмас иде.**
48. **Һичшиксез, ул** [Коръән] **– тәкъвалык ияләре өчен бер үгет.**
49. **Арагызда аны ялган дип санаучылар барлыгын, әлбәттә, Без беләбез.**
50. **Һичшиксез, ул** [Коръән] **– кяферләр өчен бер хәсрәт.**
51. **Һичшиксез, ул** [Коръән] **– шиге булмаган хак.**
52. **Шулай булгач, Бөек Раббыңны** [бөек булган] **исеме белән** [зикер кыл] **тәсбих ит.**

# Фəн

# Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм исламияттә беренче педагог

هَلْ يَسْتَوِي الَّذِينَ يَعْلَمُونَ وَالَّذِينَ لَا يَعْلَمُونَ

**«[Исламны] Белгән [һәм белгәне белән яшәгән] кешеләр белән [хакны] белмәгән [шул сәбәпле, наданнарча эш йөрткән һәм адашу эчендә югалып калган] кешеләр тиң була аламы?»**

«Әз-Зүмәр / Төркемнәр», 39:9

Дөньяда һәр нәрсә тәкәмәл[1] вә тәрракый итеп даимән үзгәреп торадыр. Дөньяда бер хәлдә торган һич бер нәрсә юк, үзгәрми тору гайре табигый бер эш. Һөнәр вә санагатьнең тәрракый итеп торуы, ихтирагат фәнниянең[2] көннән-көн яңара баруы хәят бәшриядә[3] ни кадәр зур үзгәрешләр китерсә, тарыз мәгыйшәттә[4] ни кадәр күп алмашынулар ясаса, тәрбия вә тәгълим эшләре дә халыкларның әхлак вә әдәбенә, гореф вә гадәтенә шул дәрәҗәдә уң тәэсире бар.

Халык арасыннан чыккан бер мөрабби[5] вә мөгаллимнең иҗтиһады вә гайрәте аркасында шул халыкның әхлак вә гадәте белән бергә рухы да үзгәрәдер. Моннан ике мең ярым ел борын үтеп киткән Сократ хәким үзенең тәрбия вә тәгалиме аркасында бөтен милләтенә яңа рух биреп, Юнан фәлсәфәсен иске эзеннән чөергән иде. Шуның өчен аңа халык «беренче мөгаллим» ләкабен биргән иде.

---

1 Тәкәмәл – камилләшү.

2 Ихтирагат фәния – уйлап табып чыгарылган әйберләр, фәнни-техник ачышлар.

3 Хәят бәшрия – кеше хәяты, яшәеше.

4 Тарыз мәгыйшәт – яшәү рәвеше, тәртибе.

5 Мөрабб – тәрбияче, остаз.

Моннан биш гасыр элек Амос Коменский[1] дигән кеше тәрбия вә тәгълим кагыйдәләрен яңа бер әсаскә[2] корып, хәзерге педагогика фәненә нигез салып, Аурупа мәдәниятендә ул да «беренче мөгаллим» ләкабенә истихкак[3] казанды. Шулай булгач, тәгълим вә тәрбия эше бик иске мәсьәлә булып чыкты. Ләкин никадәр иске булса да, һичбер искерми торган, мәйданнан китми торган, хәят бәшрияда иң мөһим урын тоткан бер мәсьәләдер. Бу мәсьәлә ничә мең еллардан бире тикшерелеп, камилләшеп торадыр. Фәкать бездә, мөселманнарда гына, бу мәсьәлә гүя яңа гына чыккан «бидгать сәийә»[4] булып күренәдер.

Гүя, безгә тәрбия вә тәгълимнең һичбер әһәмияте юк. Оҗмаһка тәрбиясез дә керергә була. Бездә бит әле булса: без дөньяга Ахирәт өчен килгән, безгә яңа мәктәпләр, яңа тәртипләр нигә кирәк? – дигән тавышларны бик еш ишетергә мөмкин. Бездә әле булса: баланы хәлфәгә биргәндә «ите синңа, сөяге беләң тиресе миңа» дип тапшырылыр; хәлфә балаларга такталарыннан артык йөкләтмәсә, яткызып камчыламаса, ул хәлфәне йомшаклыкта гаепләүләр; «кайда ул борынгы хәлфәләр, кайда борынгы мәктәпләр», дип аһ орулар бик күп очрыйдыр.

Бездә тәгълим вә тәрбия (педагогика) мәсьәләсе бик яңа кебек күренсә дә, аның урыны аурупалылардан борынрак мөселманнарда булган. Аурупалыларда беренче мөгаллим саналган Амос Коменскийның педагогикада төзегән әсас безнең мөрабби вә мөгаллимебез Мөхәммәд галәйһиссәлам тарафыннан аннан 7-8 гасыр элек корылмыштыр. Затән[5] исламиятнең үзе дә наданлык, бозыклык вә азгынлык эчендә калган

---

[1] Ян Амос Коменский (1592-1670) – күренекле педагог-гуманист, «педагогиканың әтисе» буларак билгеле, «Бөек дидактика» хезмәтенең авторы. – ред.

[2] Әсас – нигез, төп.

[3] Истихкак – лаеклы булу.

[4] Бидгать сәийә – начар, тискәре яңалык

[5] Затән – нигездә.

халыкны агартуга, тәрбия вә тәһзиб[1] кылуга җибәрелгән юлдыр. Бу хакыйкатьне исламиятка дошман, мөтәгассыйб[2] ауропалылар да икърар кыладыр. Миллер дигән бер моваррих[3]: «Диннәр арасында тәмәддүн[4] вә тәрракыйга өнди торган бер дин бар исә ул да Ислам дине», – диде. Кариев: «Ислам дине Азия вә Африкага мәдәният алып килде, шул мәдәният Ауропа мәдәниятенең нигезенә беренче кирпеч булып керде», – дип кайд[5] итәдер.

Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм педагог иде, заманасының мөҗәддиде[6], өммәтенең «мөгаллим әүвәле» иде. Ул зате пакь өммәтенең начар гадәтләрен, бозык әхлагын ... ташлап, карендәшлек, йомшаклык, мәрхәмәтчелек, ярдәмчелек кеби җәмгыять бәшриянең сәгадәте өчен иң лязем булган фазыйләтләр белән тәрбия кылды. Җәмгыять бәшриянең сәгадәтен тәкәммил кылу иң бөек максуды иде. «Мин күркәм әхлакны тәмам урнаштыру өчен килдем» (хәдис).

Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм педагог иде: үзенең тәгълиматын урынына карап, мөнәсәбәт көтеп, «тәдриҗ»[7] белән сөйләр иде. Шәригать хөкемнәрен өйрәткәндә якыннан еракка, җиңелдән авырга, мәгълүмнан мәҗһүлгә[8] күчү кагыйдәсен ригая[9] кылыр иде. Аңа вәхи булып килгән тәгълимат илаһия бик мәҗһүл һәм мөраккәб[10] булыр иде. Шуны өммәтләренә ирештерү өчен әлбәттә аның ригая кыла торган

1 Тәһзиб – төзәтү, тәрбияләү.

2 Мөтәгассыйб – фанатик, кире.

3 Моваррих – тарихчы.

4 Тәмәддүн – цивилизация.

5 Кайд – теркәү, язып кую.

6 Мөҗәддид – яңартучы.

7 Тәдриҗ – акрын-акрын алга бару.

8 Мәҗһүл – билгесез.

9 Ригая – кайгырту, игътибар итү.

10 Мөраккәб – катлаулы.

кагыйдәләре бар иде. Пәйгамбәрләрнең күбе диннәрен өммәтләренә юлы белән аңлата алмый, лязем дәрәҗәдә нәшер итә алмадыклары хәлдә әфәндебез хәзрәтләре бик аз заманда ничә меңнәрчә өммәт җыйды. Бәдәви, таркау, фетнәче гарәп кабиләләренең башын кушып, дәһшәтле Ислам дәүләте корырга муафикъ булды. Хәзрәт расүлнең бу моафикыяты, аз заманда шул кадәр өммәт җыя алуы куә кодсиядән, халыкларга Аллаһы Тәгаләнең һидаять бирүеннән идеме? Шөбһә юк, хәзрәт Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм тәрбия вә тәгълимдә оста бер мөрабби вә мөгаллим иде. Дингә дәгъвәттә маһир[1] бер психолог иде. Моны игътираф[2] итмәү хәзрәт расүлнең кәмаләт шәхсиясенә хыянәт дип беләмен.

Хәзрәт расүл җәнапләре психолог иде: ул өммәтенең әхвәл рухиясына (психологиясенә) мөтталигъ[3] булган соң гына шуңа мөнасиб[4] сүз сөйләр иде.

وَبَشِّرُوا وَلاَ تُنَفِّرُوا

Халыкка авыр тоелачак нәрсәләр йөкләтеп өркетмәде. Халыкның аңлавына, төшенә алуына бик диккать итәр иде.

Тәгълимдә әхвәл рухияне, истигъдад[5] фикрияне игътибарга алу тиешлеге Ауропада Гасыр сәгадәттән 7 гасыр соң гына аңлашылып, педагогиканың әсасы кануннары сурәтендә кабул ителде. Монда үкенечле нәрсә монау: хәзрәт расүл җәнапләре вазгы[6] кылган шу тәрбия вә тәгълим кануннарыннан һич бере үзенең өммәте булган мөселманнар арасына таралмый, тәмамы белән Ауропага күчкән. Ислам голамасы гафләт итеп, хәзрәт Мөхәммәднең шул хәрәкәтләренә ияреп, аны киңәйтә белмәгән.

1 Мөраккәб – катлаулы.

2 Игътираф – тану.

3 Мөталлигъ – ирешкән, белгән.

4 Мөнасиб – яраклы, туры килгән.

5 Истигъдад – сәләтлелек; зирәклек.

6 Вазгы – кую, оештыру.

Фараби, Ибне Тофайл, Ибне Рөшд кеби бик аз голама тәрия вә тәгълим эшенә диккать итеп, шул юлда кагыйдәләр төзесәләр дә, аларның әфкаре белән күбрәк Аурупа голамасы файдаланып, үзебезнекеләр аларны кяфер ясауга тырышудан бушамаганнар.

Хөласә[1]: безнең мәктәп вә мәдрәсәләребездәге тәгълим вә тәрбия аңа татбикъ[2] кылынмаган, мөдәррис вә мөгаллимнәребезнең аннан хәбәре булмаган, дәрес-китапларыбыз аңа муафикъ язылмаган, аның нигезе җәнаб расүл Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм хәзрәтләре тарафыннан вазгы кылынып, Ауропага күчеп, төзәтелгән, киңәйтелгән. Педагогия белән психология тәгълим вә тәрбия эше өчен җан бәрабәрендә кирәкле фәннәрдер. Хосусан мәктәп вә мәдрәсәләрдә дин-гыйбадәт дәресләре бу фәннәргә татбикъ кылынып укытылса, Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең сөннәтенә ияртелгән булачак.

يَسِّرُوا وَلاَ تُعَسِّرُوا

*Мәхдүм Нури*

*«Мөгаллим» журналы, 1913 ел, 1 нче сан, 3-5 битләр.*

1 Хөласа – нәтиҗә, йомгак.

2 Татбикъ – яраштыру, яраклаштыру.

# Нәсыйхәт

# Кабер газабы һәм газапның катылыгы бәяны

«Без Аллаһының Расүле белән ансардан булган бер кешенең җеназасына чыктык һәм кабергә туктадык. Моннан соң ләхет кылынмады, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм утырды һәм без дә аның тирәсенә утырдык, гүя безнең баш өстендә бер кош һәм аның кулында гуд агачы. Ул гуд агачы белән җирне казыды. Аллаһының Расүле салләллаһу галәйһи вә сәлләм башын күтәрде һәм: «Кабер газабыннан Аллаһыга сыгынамын», – дип, ике яки өч мәртәбә әйтте. Моннан соң Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай диде: «Дөреслектә, мөэмин кол Ахирәтне каршылауда һәм дөньядан киселүдә булса, аңа йөзләре кояш кебек ак булучы фәрештәләр иңәр. Ул фәрештәләр белән оҗмахтан җәннәт исле, хуш исле нәрсәләр, ягъни хушбуй һәм кәфен булыр. Алар күз күрми торган җиргә кадәр утырырлар, моннан соң үлем фәрештәсе килер, ул кешенең башы турысында утырыр. Үлем фәрештәсе: «Әй тынычланган нәфес, Аллаһының мәгъфирәтенә һәм Аллаһы Тәгаләнең ризалыгына чык», – дип әйтер. Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип дәвам итте: «Ул җан чыгар, сәкадан тамчы аккан кебек агар. Фәрештәләр ул җанны алырлар һәм аны керфек йомганга кадәр үлем фәрештәсе кулында калдырмаслар, оҗмахтан килгән кәфенгә һәм хушбуйга алырлар һәм ул хушбуйдан җир йөзендә булучы яфәр исенең иң хуш исе кебек ис чыгар. Фәрештәләр ул җан белән ашырлар һәм фәрештәләрдән бер төркем хозурына үтмәсләр. Үткән очракта ул төркем әйтер: «Әй, бу нинди күркәм рух? Фәрештәләр: «Фәлән улы фәләннең рухы», – дип әйтеп, ул кешене иң күркәм исемнәр белән атарлар. Моннан соң бу рух белән дөнья күгенә туктарлар, ул җанга ишек ачуны сорарлар. Ул ишек фәрештәләргә ачылыр, җанны каршы алырлар һәм аны һәр күктән ул күкнең якын фәрештәләре үзләренә билгеләнгән күккә, җиденче күктә

туктаганга кадәр күтәрерләр. Аллаһы Тәгалә әйтер: «Аның дәфтәрен мөэминнәрнең гамәле языла торган дәфтәргә языгыз һәм аны җиргә кайтарыгыз. Аларны ул җирдән яраттым һәм ул җирдән аларны икенче мәртәбәләп чыгарырмын». Җан ул мөэминнең тәненә кайтарылыр, аның янына ике фәрештә килеп әйтерләр: «Раббың кем?» Ул әйтер: «Раббым – Аллаһы». Әйтерләр: «Динең нәрсә?» Ул мөэмин әйтер: «Динем – Ислам». Әйтерләр: «Сезгә җибәрелгән кеше хакында нәрсә әйтерсең?» Мөэмин әйтер: «Аллаһының Расүледер». Әйтерләр: «Гыйлемең нәрсә?» Ул әйтер: «Аллаһының китабын укыдым, ул Аллаһыга ышандым, Аны дөрес дип санадым». Бер тавыш килер: «Минем колым дөресен әйтте. Аңа җәннәттәге түшәкне түшәгез, җәннәт киемен кидерегез. Аңа җәннәт исе һәм хушбуе килсен өчен, җәннәткә ишек ачыгыз». Шуннан соң аның өчен кабере күз күреме кадәр киң кылыныр, янә аңа йөзе күркәм һәм исе хуш булучы ир килер. Ул ир мөэмингә әйтер: «Сине шатландырган Зат белән сөенеч бирәмен». Бу аның белән вәгъдәләнгән көндер. Мөэмингә ул кеше әйтер: «Мин синең изге гамәлең». Ул мөэмин әйтер: «Әй минем Раббым, Кыямәт көнен торгыз, хәтта мин балаларым, хезмәтчеләрем янына кайтыр идем».

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйтте: «Дөреслектә, кяфер булган кол Ахирәтне каршы алуда һәм дөньядан киселүдә булса, аңа күктән йөзләре кара фәрештәләр иңәр һәм алар белән паласлар булыр. Аннан күз күреме кадәр җирдә утырырлар. Моннан соң үлем фәрештәсе килеп, баш турысында утырыр һәм болай дип әйтер: «Әй начар нәфес, Аллаһының каһәренә һәм Аның ачуына чык». Ул кешенең җаны бөтен тәненә таралыр, фәрештә аның җанын алыр. Тамырлары һәм беркетелгән нәрсәләре белән киселер. Күз йомганчыга кадәр дә ул җанны үлем фәрештәсе кулында калдырмаслар. Фәрештәләр җанны паласка куярлар, җаннан үләксә исе кебек чирканыч ис чыгар. Фәрештәләр җан белән ашырлар һәм фәрештәләрдән булган төркем хозурына үтмәсләр, мәгәр үтсәләр исә, бу нинди бозык рух, дип сорарлар. Алар аны исемнәрнең иң

кабахәтләре белән атарлар, хәтта ул җан белән дөнья күгенә туктаганга кадәр ашырлар. Ишек ачуны сорарлар, ул җан өчен ишек ачылмас. Моннан соң Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм бу аятьне укыды:

إِنَّ الَّذِينَ كَذَّبُوا بِآيَاتِنَا وَاسْتَكْبَرُوا عَنْهَا لَا تُفَتَّحُ لَهُمْ أَبْوَابُ السَّمَاءِ وَلَا يَدْخُلُونَ الْجَنَّةَ حَتَّىٰ يَلِجَ الْجَمَلُ فِي سَمِّ الْخِيَاطِ ۚ وَكَذَٰلِكَ نَجْزِي الْمُجْرِمِينَ ﴿٤٠﴾

**«Безнең аятьләребезне ялганга санаган кешеләр һәм алардан ерагаеп, тәкәбберләнүчеләр өчен күк капкалары [аз гына булса да] ачылмаячак, һәм дөя энә күзеннән чыкканчы, алар җәннәткә [мәңге] керә алмаячаклар».**

«Әгъраф / Пәрдә», 7:40

Аллаһы Тәгалә: «Аның дәфтәрен җәһәннәм ташына языгыз», – дип әйтер һәм ул колның рухы камил ташлану белән ташланыр. Моннан соң Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип укыды: «Берәү Аллаһыга ширек кылса, гүя күктән төште, аны кош алыр, яисә аны җил ерак урынга очырыр, ягъни рухы аның тәненә кире кайтарылуда вәгъдә кылыныр. Аңа ике фәрештә килер, аның белән бергә утырырлар һәм аңа әйтерләр: «Раббың кем?» Ул: «Аһ, белмим», – дип әйтер. Алар: «Динең ни?» – дип сорарлар. Ул әйтер: «Аһ, белмим». Аннан: «Сезгә җибәрелгән ир хакында ни әйтерсең?» – дип сорарлар. Ул: «Аһ, белмим», – дип әйтер. Күктән бер тавыш килер: «Колым ялганлады, ут түшәкләреннән аңа түшәк түшәгез һәм аңа уттан кием кидертегез, аның өчен утка ишек ачыгыз». Аңа тәмугның эссесе, утның җилләре керер, аның хозурына кабере тар кылыныр. Ул кешенең кабыргалары кабердә бер-берсенә керер. Аңа йөзе һәм киемнәре начар, исе сасы булучы ир килеп: «Сиңа явыз булган нәрсә белән (сине сөендерәмен. Бу көн сиңа вәгъдә кылынган көндер», – дип әйтер. Ул кеше: «Син кем?» – дип сорар. Ул начар кеше: «Мин синең

гамәлең», – дип әйтер. Ул кол: «Әй Аллаһым, Кыямәтне торгызма», – дип ялварыр!

Факиһ радыяллаһу ганһе болай дип әйтте: «Әбү Җәгъфәр үзенең иснәде белән Әбү Һөрайра радыяллаһу ганһедән болай дип китерә: «Аллаһының Расүле салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Һәркайчан мөэмингә үлем вакыты җитсә, фәрештәләр бер ефәк кисәге белән килерләр. Ул ефәктә яфәр һәм күп төрле исләр булыр. Ул колның җаны йон камырдан сөрелгән кебек сөрелер. Дәхи әйтелер: «Әй тынычланган нәфес, разый булган хәлдә, үзеңнән разый кылынган хәлдә Аллаһы Тәгаләнең рәхмәтенә һәм Аның ризалыгына кайт. Әгәр аның рухы чыгарылса, моның хозурына яфәр һәм хушбуйлар куелыр, ефәккә төрелер. Ул рух күктәге гыйллиингә (дәфтәрләргә) җибәрелер», – дип әйтте.

Факиһ радыяллаһу ганһе болай диде: «Әбү Җәгъфәр үзенең иснәде белән Габдулла бине Гомәр радыяллаһу ганһедән риваять итә: «Дөреслектә, мөэмин кеше кабергә куелса, җитмеш аршын озынлыгында кабер киңәер, аның хозурына хушбуйлар таратылыр һәм ул ефәк белән төрелер. Әгәр аның белән Коръәннән бер нәрсә булса, ул кешегә Коръәннең нуры җитәр. Әгәр Коръәннән бер нәрсә дә булмаса, аның өчен кабердә кояш кебек нур кылыныр һәм аның охшашы йоклый торган яшь кияү кебек булыр. Аны беркем уятмас, мәгәр аның сөекле әһеле генә уятыр. Ул кияү йокысыннан йокыдан туймаган кебек торыр».

Факиһ радыяллаһу ганһе болай дип әйтте: «Бер кеше кабер газабыннан котылырга теләсә, аның хозурына дүрт төрле нәрсә лязем булыр, дүрт нәрсәдән сакланыр. Тиешле булган дүрт нәрсә: намазларны һәм садаканы үтәү, Коръән уку, тәсбихләрне күп кылу, чөнки бу нәрсәләр каберне яктырта һәм киң кыла. Әмма аннан саклана торган дүрт нәрсә: ялганчылык, хыянәт, сүз йөртү һәм бәвелдер».

Тәхкыйк, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнән риваять ителде. Дөреслектә, ул болай дип әйтте:

«Бәвелдән сакланыгыз, чөнки кабер газабының күбесе бәвелдән сакланмаганнандыр».

Дәхи Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнән риваять ителә: «Дөреслектә, Аллаһы Тәгалә сезгә дүрт нәрсәне мәкруһ кылды: намазда буш эш, кыйраәттә уйнау, уразада җимагъ, кабер янында көлү».

Мөхәммәд бине Сәмәктән риваять ителде: «Дөреслектә, ул Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм каберстанга карап, болай дип әйтте: «Бу кабернең тик торуы сезне алдамасын. Ни гаҗәеп, ул каберләрдә кайгылылар күп булды. Янә сезне каберләрнең тигезлеге алдамасын, ни гаҗәп, ул кабердәге кешеләрнең бер-берсеннән аерылуы каты булды. Акыллы кешегә кабергә кермәстән әүвәл каберне күп зикер итү тиешле буладыр». Суфьян Әс-Сәүри радыяллаһу ганһе болай дип әйтте: «Берәү каберне күп зикер итсә, ул каберне оҗмах бакчаларыннан булган бер бакча итеп табар. Бер кеше аннан гафил булса, ул каберне ут чокырларыннан булган бер чокыр итеп табар».

Гали радыяллаһу ганһедән риваять ителә. Дөреслектә, ул үзенең хотбәсендә болай дип әйтте: «Әй Аллаһының бәндәләре! Үлемнән сакланыгыз, аннан кичегү булмас. Әгәр аның өчен торсагыз, ул сезне алыр. Әгәр аннан качсагыз, насыяләрегездән (йөзләрегездән) тоткан хәлдә сезгә үлем ирешер. Тиз арада котылуны табарга тырышыгыз, чөнки сезнең артыгызда кабахәтлекне теләүче булучыдыр, ул – теләүче – кабердер. Аң булыгыз, дөреслектә, кабер җәннәт бакчаларыннан булган бер бакча яисә ут чокырларыннан булган бер чокырдыр. Белегез, дөреслектә, кабер һәр көнне өч мәртәбә сөйләшәдер. Ул әйтер: «Мин золымәт, ягъни караңгылык йорты. Мин вәхшилек йорты. Мин кортлар йорты». Белегез, дөреслектә, бу көннән башка тагын да катырак көн булучыдыр. Ул көнне кечкенәләр картаерлар, зур кеше исерер, һәр бала имезүче – имезә торган нәрсәдән зәһүл кылыр, һәр йөкле үзенең баласын ташлар. Кешеләрне исерек күрерсең, әмма алар исерекләр түгел, ләкин Аллаһы Тәгаләнең

газабы катыдыр. Бу көннән соң ут булыр, ул утның эссесе каты, чокыры ерак һәм зиннәте тимер, суы сары судыр. Ул утта рәхәт булмас. Һәм болай дип әйтте: «Мөселманнар каты елау белән еладылар». Гали радыяллаһу ганһе: «Бу көннән соң башка көн булучыдыр. Оҗмах җирләр һәм күкләр киңлегендә булыр, ул гыйлем, харам шөбһәдән сакланган кешеләргә хәзерләнде», – дип әйтте. Аллаһы Тәгалә безне каты газаптан котылдырса иде. Безгә һәм сезгә дә нигъмәтләр йортын хәләл кылса иде».

Үсәйд бине Габдрахманнан риваять ителә. Ул болай дип әйтте: «Миңа иреште, дөреслектә, әгәр мөэмин бәндә үлсә һәм аны күтәрсәләр, ул: «Мине ашыктырыгыз», – дип әйтер, һәркайчан аны ләхеткә куйсалар, аңа җир: «Дөреслектә, мин сине сөя идем һәм син минең аркам өстендә идең, хәзер син миңа бигрәк тә сөеклерәксең», – дип әйтер».

Госман бине Гаффан радыяллаһу ганһедән риваять ителә. Дөреслектә, ул радыяллаһу ганһе бер кабергә туктап елады. Аннан: «Дөреслектә, син оҗмах белән җәһәннәмне искә төшерә идең, әмма еламадың, ни өчен монда елыйсың?» – дип сорадылар. Госман радыяллаһу ганһе болай дип әйтте: «Дөреслектә, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Кабер – Ахирәт йортыннан булган бер йорттыр. Әгәр аннан һәм аннан соңгысыннан котылса, ул кабердән җиңелрәк. Әгәр аннан һәм аннан соңгысыннан котылмаса, аннан катырак».

Габделхәмид бине Мәхмүттән риваять ителә. Ул болай дип әйткән: «Мин ибне Габбас радыяллаһу ганһе каршында утыра идем. Аның янына бер кавем килеп болай дип әйтте: «Без хаҗилар булып чыктык, таш иясе булган кабиләгә туктаганчы безнең бер иптәшебез бар иде. Ул иптәшебез үлде, без аны хәзерләдек, моннан соң китеп, аның өчен кабер һәм ләхет казыдык. Тәхкыйк, ләхетне кара еланнар белән тулы итеп таптык һәм ул каберне ташладык, аның өчен икенче урында казыдык. Шул вакытта янә ләхетне тутырган кара еланнар таптык. Ул каберне дә ташладык һәм аңа өченчене казыдык. Янә ләхетне кара еланнар белән тулы итеп таптык, янә

бу каберне дә ташлап сиңа килдек». Ибне Габбас радыяллаһу ганһе болай дип әйтте: «Бу эш кешенең кылган эшедер, барыгыз һәм аны ул казыган каберләрегезнең берсенә күмегез. Валлаһи, җирне кайдан гына казысагыз да, әлбәттә, җирнең теләсә кайсы урынында ул еланны табарсыз. Аның кавеменә хәбәр бирегез». Габделхәмид бине Мәхмүт дәвам итеп болай дип әйтте: «Без китеп, ул казыган җирләрнең берсенә аны күмдек. Кайткканда бездә булган аның нәрсәләре белән туганнарына килдек. Аның хатынына: «Аның гамәлләреннән нәрсәсе бар иде?» – дип сорадык. Хатыны: «Ашамлык, ягъни бодай сата торган булды. Һәркөнне үзенең азыгы кадәр ала торган булды, моннан соң ул ашамлыкка охшашлы үлән катнаштыра иде. Янә арпаның сапларын һәм эченнән чыккан ярамас нәрсәләрен, ягъни ашамлыкның ярамас нәрсәләрен ашамлыкка сала иде», – дип әйтте. Факиһ радыяллаһу ганһе болай дип әйтте: «Дөреслектә, бу хәбәрдә, хыянәт, кабер газабына сәбәп булуга дәлил бар. Гүя алар күргән нәрсәләр терекләргә хыянәттән тыелсыннар өчен гыйбрәттер». Болай дип әйтелә: «Дөреслектә, җир һәр көнне биш мәртәбә кычкырыр. Беренче кычкыруда: «Әй адәм улы, минем аркамда йөрисең һәм синең бара торган урының минем эчемдер», – дип әйтү булыр. Икенчесендә: «Әй адәм улы, минем өстемдә төрле ниләр ашыйсың. Минем эчемдә сине кортлар ашар», – дип әйтер. Өченче тапкырында мондый сүзләр әйтер: «Әй адәм улы, минем аркамда көләсең, тиздән минем эчемдә еларсың». Дүртенчесендә: «Әй адәм улы, минем аркамда шатланасың, тиздән минем эчемдә кайгырырсың», бишенчесендә: «Әй адәм улы, минем аркамда гөнаһ кыласың, тиздән минем эчемдә газапланырсың», – дип мөрәҗәгать итәр.

Гамру бине Динар радыяллаһу ганһедән риваять ителә. Ул әйтте: «Мәдинә әһеленнән бер ир булды. Мәдинәнең чатында аның кыз кардәше бар иде. Шикләнеп, барып-кайтып йөри торган булды. Моннан соң ул кыз кардәше үлде. Һәм кардәше аны әзерләп, каберенә илтеп күмгәннән соң, үзенең әһеленә кайтканда, үзе белән булган янчыкны онытканын исенә

төшерде. Үзенең иптәшләреннән булган бер ирдән ярдәм сорады, алар кабергә килделәр. Ул каберне казыды, янчыкны тапты. Иптәшенә әйтте: «Күч, минем кыз туганым нинди хәлдә икәнен карыйм». Ләхет хозурына ябылган нәрсәне күтәрде, шул вакытта каберне ут йөзеннән ялкынланган итеп күрде, күтәргән нәрсәне төшерде, каберне тигезләде һәм үзенең әнисенә кайтып әйтте: «Әй анам, минем апам булган нәрсәдән хәбәр бир». Анам әйтте: «Апаң турында ни өчен сорыйсың? Ул һәлак булды». Ул ир әйтте: «Син хәбәр бир». Анам әйтте: «Синең апаң намазны кичектерә торган иде, тәһарәтне тулысынча алмыйча намаз укый иде. Күршеләр йокларга яткач, ишекләренә килеп, аларның сүзләрен тыңлап, кешеләргә җиткерә иде. Ягъни, ул сүз йөртүчелек белән йөрү өчен күршеләрнең сүзләрен тыңлый торган булды». Бу сүз йөртүчелек кабер газабының сәбәбедер. Бер кеше кабер газабыннан котылуны теләсә, Мөнкир һәм Нәкирнең сораулары җиңел булсын өчен, аның өчен сүз йөртүдән һәм башка гөнаһлардан, саклану лязем булыр. Аллаһы Тәгалә болай дип әйтте:

يُثَبِّتُ اللَّهُ الَّذِينَ آمَنُوا بِالْقَوْلِ الثَّابِتِ فِي الْحَيَاةِ الدُّنْيَا وَفِي الْآخِرَةِ ۖ وَيُضِلُّ اللَّهُ الظَّالِمِينَ ۚ وَيَفْعَلُ اللَّهُ مَا يَشَاءُ ﴿٢٧﴾

> **«Аллаһы иман китергән кешеләрне дөнья тормышында да, Ахирәттә дә көчле [тәүхид кәлимәсе булган] сүз белән [Ислам динендә] ныгыта. Әмма Аллаһы залимнәрне юлдан яздыра. Аллаһы теләгәнен кыла».**

«Ибраһим», 14:27

Бәрра бине Газиб радыяллаһу ганһе Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнән риваять итте. Дөреслектә, Пәйгамбәребез болай дип әйткән: «Әгәр мөселман кеше каберендә соралса һәм ул: «Дөреслектә, Аллаһыдан башка һич мәгъбүд (гыйбадәт кылынучы зат) юк, дәхи Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм Аллаһының колы һәм Расүле»,

дип шаһитлык бирсә, аның бу шәһадәте Аллаһы Тәгаләнең югарыда килгән аятен раслаудыр. (Югарыда «Тәфсир җәләләйн»гә муафыйк итеп тәрҗемә ителде). Аллаһы Тәгаләгә итагать кылучы ихласлы мөэмингә сәбит кылу өч хәлдә булыр. Беренчесе, үлем фәрештәсе күренгән вакытта. Икенчесе, Мөнкир һәм Нәкирнең сорау алган хәлендә. Өченчесе, Кыямәт көнендә хисап вакытында аннан сораган вакытта.

Үлем фәрештәсе күренгән вакытта сәбит кылу өч нәрсә хозурынадыр. Ул өчнең беренчесе, көфердән саклану һәм тәүхид хозурына рухы чыкканчы истикамәттә муафыйк булу һәм ул Исламдадыр. Икенчесе, аны фәрештәләр Аллаһының рәхмәте белән сөендерүдер. Өченчесе, җәннәттән булган урынны күрүдер.

Кабердә сәбит кылу өч нәрсә хозурынадыр. Ул өч нәрсәнең беренчесе, хәтта Мөнкир һәм Нәкиргә җавап биргәнчегә кадәр аңа Аллаһы Тәгалә аннан разый була торган нәрсәне әйтеп торыр. Икенчесе, аннан куркыныч һәм катылыкның китүе. Өченчесе, җәннәттәге урынын күрү. Кабер җәннәт бакчаларыннан булган бакча булып әверелер.

Әмма хисап вакытында сәбитле булу өч нәрсә хозурынадыр. Ул өчнең беренчесе, аннан сорала торган нәрсәдән дәлилне әйтеп тору. Икенчесе, аңа хисап җиңел булуы. Өченчесе, аннан белеп һәм хата белән кылынган гөнаһларының кичүе.

Әйтелде: сәбит кылу дүрт хәлдәдер. Беренчесе, үлем вакытында. Икенчесе, кабердә, хәтта куркынычсыз җавап биргәнчегә кадәр. Өченчесе, хисап вакытында. Дүртенчесе, Сират күпере янында, хәтта ялтыраган яшен кебек үткәнчегә кадәр.

Әгәр кабер сорауларының хәленнән, ул ничек, дип соралса, аңа әйтелер: «Тәхкыйк, ул кабердә сорау хакында галимнәр сөйләште. Анда риваятьләр төрле-төрле булды». Ул галимнәрнең кайберсе болай дип әйтер: «Сорау тәннән башка җанга гына булыр. Бу сорау вакытында җан тәннең күкрәгенә кадәр керер. Кайберәүләре әйттеләр: «Ул кешенең

рухы тәне белән кәфене арасында булыр». Боларның һәркайсы хакында әсәрләр килде.

Гыйлем әһеле каршында дөрес булганы шулдыр: кеше кабердәге сорауны укый һәм кабер соравының рәвеше белән шөгыльләнмәс, ничек булуын Аллаһы Белүче, дип әйтер. Без ул кабергә үрелсәк, ул сорауны күрербез. Әгәр берәү Мөнкир һәм Нәкирнең сорауларын инкяр итсә, дөреслектә, аның инкяр итүе ике нәрсәнең берсеннән азат итми. Әгәр: «Дөреслектә, бу сорау акыл юлыннан карасаң дөрес түгел», – дип әйтсә, ул сорау табигатькә капма-каршы, ягъни бер җан чыккач, җан керүне күз алдына китерү мөмкин түгел. Яисә әйтер: «Моның булуы дөрес, ләкин катгый дәлил белән сәбит түгел». Акыл ягыннан дөрес түгел дисә, аның сүзе пәйгамбәрлекне – тәгътылгә, могҗизаны ялганга саный, чөнки пәйгамбәрләр адәмнәрдән булдылар һәм аларның табигатьләре үзләреннән башкаларның табигате кебектер. Фәрештәләрне дә күрделәр һәм алар хозурына вәхи индерелде. Муса галәйһиссәламгә диңгез ачылды һәм аның таягы елан булып әверелде. Боларның барысы табигатькә каршыдыр, Исламга кергәннән соң моны инкяр итүче Исламнан чыгар. Әгәр, ул кабер соравы дөрес, ләкин катгый дәлилләнмәде, дисә, тәхкыйк, без хәбәрләрдән риваять кылдык шундый хәбәрне ишеткән кешегә ул хәбәрләр канәгать кыла торган урындыр. Янә Аллаһы Тәгаләнең китабында да моның хозурына дәлил булучыдыр. Аллаһы Тәгалә болай дип әйтте:

وَمَنْ أَعْرَضَ عَن ذِكْرِي فَإِنَّ لَهُ مَعِيشَةً ضَنكًا ...﴿١٢٤﴾

**«Кем дә кем Минем зикеремнән йөз чөерсә, аны [дөньяда да, кабердә дә] авыр тормыш көтә».**

«Та һа», 20:124

Коръән хәдискә таянып тәфсир кылынган. Янә аны Кыямәт көнендә сукыр итеп кубарырбыз. Тәфсир әһелләре «Мәгыйшәтән даңкә» сүзен «кабер соравы» дип тәфсир кылдылар. Аллаһы Тәгалә болай дип әйтте:

يُثَبِّتُ اللَّهُ الَّذِينَ آمَنُوا بِالْقَوْلِ الثَّابِتِ فِي الْحَيَاةِ الدُّنْيَا وَفِي الْآخِرَةِ... ﴿٢٧﴾

**«Аллаһы иман китергән кешеләрне дөнья тормышында да, Ахирәттә дә көчле [тәүхид кәлимәсе булган] сүз белән [Ислам динендә] ныгыта».**

«Ибраһим», 14:27

Факиһ радыяллаһу ганһе үзенең иснәде белән Сәгыйд бине Мөсәййәбтән, ул Гомәр радыяллаһу ганһедән, ә ул Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнән риваять итә. Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән: «Әгәр мөэмин кеше үзенең каберенә керсә, аңа кабернең ике егете килер. Алар ул мөэминнең каберенә утырып аннан сорарлар! Дөреслектә, ул кеше һәркайчан аны калдырып китсәләр, башмакларының тавышын ишетер Аннан: «Раббың кем? Динең нәрсә? Пәйгамбәрең кем?» – дип сорарлар. Ул мөэмин әйтер: «Аллаһы Тәгалә – минем Раббым. Динем – Ислам. Пәйгамбәрем – Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм». Аңа әйтерләр: «Аллаһы Тәгалә сине раслаган иде, күзең рәхәтләнгән хәлдә йокла. Ул Аллаһы Тәгаләнең сүзедер: «Иман китергән мөэминнәргә Аллаһы Тәгалә дөнья тереклегендә һәм Ахирәттә тәүхид, ягъни хак сүз хозурына аларны сәбит кылыр, үзләренә җәбер кылучыларны Аллаһы Тәгалә station аздырыр».

Әбү Хәзим бине Гомәр радыяллаһу ганһедән риваять ителде. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән: «Әй Гомәр! Әгәр сиңа кабернең ике егете Мөнкир һәм Нәкир килсә, сиңа ничек булыр? Ике кара фәрештә, күзләре зәңгәр, үзләренең тешләре

белән җирне тишәләр, йоннарына басарлар. Боларның тавышлары каты тавышлы күк күкрәү кебек, күзләре атылган яшен кебектер». Гомәр радыяллаһу ганһе болай дип әйткән: «Минем акылым үзем беләнме? һәм мин бу көн булган хәлдә булырмынмы?» Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Әйе», – дип әйтте. Гомәр радыяллаһу ганһе: «Шул вакытта боларны Аллаһы Тәгаләнең рөхсәте белән сиңа җибәрермен», – диде. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйтте: «Дөреслектә, Гомәр радыяллаһу ганһе моңа ирешүчедер».

Факиһ Әбү Касыйм бине Габдрахманнан, ул үзенең иснәде белән Әбү Һөрайра радыяллаһу ганһедән, ул Пәйгамбәребездән риваять итә. Дөреслектә, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән: «Һич үлә торган мәет булмас, мәгәр булды исә, ул мәет өчен тавыш булыр, аның янында булган кешедән башка һәр хайван ул тавышны ишетер. Әгәр кеше ул тавышны ишетсә, әлбәттә, аңсыздан кычкырып егылыр иде. Әгәр ул үзенең каберенә киткәндә изге булса, әйтер: «Мине ашыктырыгыз, әгәр минем алдымда хәердән булган нәрсәне белсәгез, миннән алдан барыр идегез». Әгәр изге булмаса әйтер: «Мине ашыктырмагыз, әгәр алдымда булган начарлыктан ни барын белсәгез, мине ашыктырмас идегез». Ул каберенә куелса, аңа ике кара фәрештә килер, күзләре зәңгәр булыр. Аңа баш ягыннан килерләр, ул кешенең намазы әйтер: «Минем яныма килмә, бу ята торган урын өчен байтак кичләрне йокысыз һәм сакланган хәлдә үткәрде». Аның ике аягы тарафыннан килерләр. Ата-ана изгелеге килер һәм әйтер: «Безнең тарафтан килмә, тәхкыйк, бу урыннан сакланган өчен безнең хозурыбызга торыр булды». Аның уң ягыннан килер һәм ул кешенең садакасы әйтер: «Минем тарафтан килмә, бу ята торган урыннан саклану өчен ул минем белән садака бирә торган булды». Аның сул ягыннан килер һәм аның уразасы әйтер: «Минем тарафтан килмә, бу урыннан саклану өчен, дөреслектә, сусыз һәм ач тора торган булды». Аны йоклаган кешене уяткан сыман уятырлар

һәм әйтерләр: «Аллаһы Тәгалә сүзен, җиткерә торган ирне күрдеңме?» Ул бала, Аллаһының нигъмәте яшерен булды. Ул кеше: «Кем ул?» – дип әйтер. Әйтелер: «Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм», – дип. Ул кеше әйтер: «Шәһадәт бирәмен, дөреслектә, ул Мөхәммәд Аллаһы Тәгаләнең Расүледер». Аңа фәрештәләр әйтерләр: «Мөэмин булып яшәдең, мөэмин булып үлдең». Аның кабере киң кылыныр, аның өчен Аллаһы Тәгаләнең кәраматеннән Аллаһы теләгәннәре чәчелер. Аллаһыдан муафыйк булуны, һәм безне адаша торган урынга аздыручы нәфес теләкләреннән саклануны, дәхи, гафләткә адаштыра торган нәфес теләкләреннән, кабер газабыннан безне саклауны сорыйбыз». Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм кабер газабыннан Аллаһыга сыгына торган иде.

Гайшә радыяллаһу ганһедән зикер ителә. Дөреслектә, ул әйтте: «Миңа бер яһүди хатын кергәнчегә кадәр кабер газабын белми идем. Ул яһүди бер нәрсә сорады, аңа бирдем. Ул әйтте: «Сине Аллаһы Тәгалә кабер газабыннан сакласын». Мин ул яһүдинең сүзен яһүдиләрнең юк нәрсәләреннән, дип уйладым. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм керде. Мин моны Расүлулла салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә зикер иттем. Пәйгамбәребез миңа: «Дөреслектә, кабер газабы хак», – дип хәбәр бирде, һәр мөселманга кабер газабыннан Аллаһы Тәгаләгә сыгыну, һәм ул кабергә кермәстән әүвәл изге гамәлләр белән хәзерләнү вәҗибтер. Тәхкыйк, дөньяда булган вакытта аңа эш җиңел булды. Әгәр кабергә керсә, дөреслектә, ул аның өчен бер генә изгелек кылуга рөхсәт бирүне теләр һәм аңа рөхсәт бирелмәс һәм ул кайгыда һәм үкенечтә калыр. Акыллы кешегә үлгән кешеләр хакында уйларга тиешле була. Дөреслектә, үлгән кешеләр алар өчен ике рәкәгать намаз укырга, бер мәртәбә шәһадәт кәлимәсен әйтергә, яисә бер тәсбих әйтергә рөхсәт бирелүен телиләр. Алар өчен рөхсәт бирелмәс, алар терекләрдән гаҗәпләнерләр. Дөреслектә, алар көннәрен гафләттә һәм ялкаулыкта бушка үткәрәләр.

Әй, кардәш, көннәреңне бушка үткәрмә, ул көннәр малыңның башыдыр. Дөреслектә, син малның башына кодрәтле булган вакытта көчең табышка җитәр, чөнки Ахирәт файдасы бу көндә арзандыр. Ахирәт файдасын арзан вакытта җыйганчыга кадәр тырыш, чөнки шул көн килер, ул көндә бу файда кыйммәт булып әверелер. Бу арзан көндә Ахирәт файдасын кыйммәт көне өчен күп кыл, чөнки, дөреслектә, ул файданы Ахирәт көнендә теләүгә көчең җитмәс.

Без Аллаһы Тәгаләдән безне фәкыйрьлек һәм хаҗәт көненә хәзерләнү өчен муафыйк кылуны, һәм безне кайтуны теләгән үкенүчеләр җөмләсеннән кылмауны, барча мөселман ирләр һәм хатыннар хозурына үлем исереклеген һәм кабер катылыгын җиңел кылуны сорыйбыз. Әй барча галәмне тәрбия кылучы, догабызны кабул кыл. Дөреслектә, Аллаһы Тәгалә – рәхмәт кылучыларның иң рәхмәт кылучысыдыр. Ул Аллаһы безнең җитәкчебез һәм ул вәкаләт йөзеннән ни хуш булды. Хәүл һәм куәт юк, мәгәр олуг һәм бөек Аллаһы белән генә.

*«Тәнбиһүл-гафилин» китабыннан*

# Олы гөнаһлар

## Хатын-кызларның – ирләргә, ирләрнең хатын-кызларга охшарга тырышуы

Аллаһы Раббыбыз Коръәндә болай дип әйтә:

وَالَّذِينَ يَجْتَنِبُونَ كَبَائِرَ الْإِثْمِ وَالْفَوَاحِشَ ...﴿٣٧﴾

**«Һәм шул кешеләр өчен ки, алар [ширек кебек] гөнаһның зурларыннан һәм [зина кебек] кабахәт нәрсәләрдән сакланалар».**

«Әш-Шура / Киңәш», 42:37

Ибне Габбас радыяллаһу ганһе: «Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм хатын-кызларга охшарга тырышучы ир-атларны һәм ирләргә охшарга тырышучы хатын-кызларны ләгънәт кылган», – дип әйткән.

Икенче бер хәдистә болай дип әйтелгән: «Ирләргә охшарга тырышучы хатын-кызны Аллаһы ләгънәт кылсын».

Әбү Һөрайра радыяллаһу ганһе болай дип әйткән: «Аллаһының Расүле салләллаһу галәйһи вә сәлләм хатын-кызлар киемен кигән ир-атларны, ир-атлар киемен кигән хатын-кызларны ләгънәт кылды».

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән: «Җәһәннәм әһелләре арасында мин әле күрмәгән ике төркем кеше бар. Алар белән башка кешеләрне кыйнаячаклар. Икенче төркем – хатын-кызлар. Алар киенгән, әмма шул ук вакытта киемсез кебек. Аларның башлары дөя өркәченә охшаган. Бу хатын-кызлар җәннәткә кермәс, хәтта аның исен дә сизмәс. Ә шул вакытта җәннәт исе билгеле бер ераклыктан сизеләчәк».

Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Ир-ат хатын-кызга итагать итә башласа – һәлак булыр», – дип әйткән.

Менә хатын-кызларның ләгънәт кылынган кайбер гамәлләре: кием артына яшеренгән алтыннарны, кайбер бизәнү әйберләрен күрсәтү, чит ирләр янында булганда ислемайлар сибү, башкаларның игътибарын җәлеп итә торган киемнәр кию.

*Имам Әз-Зәһәбинең «Әл-Кәбаир» китабыннан*

# Әдәби сәхифә

# Кайнар диңгез юлы

(Дәвамы. Башы алдагы санда)

Рәйсә ире белән көн саен төнге тәхәдҗуд намазы укып, Аллаһтан мөселманнарны җыеп намаз укырлык урын сорап ялвардылар. Таһир хәзрәт иртүк тора да Сургут шәһәре баш идарәсе җитәкчесе янына бара. Җитәкчеләр яныннан нинди кәеф белән кайтуын, аның йөзенә карауга белә. Таһир авыр сулап, өстәл янына килеп утырды.

– Указлы мулла да булдым, Устав та бар. Тик бернинди үзгәреш юк, бу торгынлык кайчанга кадәр дәвам итәчәк? Мәчет төзер өчен, иң начар урыннарны тәкъдим итәләр. Вакытлыча гына гыйбадәт кыла торган бер бүлмә генә бирсәләр дә ярар иде.

– Хәмит Ясәвиев дигән җитәкче чакырды диде ич әткәй, барып кара әле аның янына, ул бит татар кешесе, сине аңламый калмас, – диде Рәйсә.

– Кем янына бара дип уйлыйсың соң син, Хәмит абый янына барам. Кабул итү бүлмәсендә басып торам, күтәрелеп тә карамыйча кабинетына кереп китә. Иртәгә соңгы тапкыр барып карыйм да, әгәр дә шушындый битарафлык дәвам итсә, кайтып китәбез Казанга, – диде төшенке тавыш белән. Казаннан килгән запас акчалар бетеп, күп көнне нәфел уразалары тотып көн уздырсалар да, булганына шөкер иттеләр.

...Рәйсә иренең йокламыйча таң аттырганын күрде. Таһир әле бер якка, әле икенче якка әйләнеп ятты. Җиде тулганчы өйдән чыгып киткән иде, сәгать тугызлар тирәсендә ярсыган хәлдә әйләнеп тә кайтты.

– Китәбез! Монда без кирәк түгел! – дип, урынга барып капланды.

Рәйсә ире янына барып утырды, кулы белән аркасыннан сыйпап алды.

– Нәрсә дип әйтте соң ул? Кайтып китәр дәрәҗәгә җиткерерлек, нинди сүз ул?

– Минем яныма көн саен килеп, аптыратып йөрмә, диде. Бу – син монда кирәк түгел, дигән җавапны аңлата түгелме соң? Китәбез, җаныем, балаларны юлга әзерлә!

Рәйсә урыныннан кузгалып китмәде, җайлап кына үз сүзен әйтте.

– Минем дә Казанда яшисем килә, җаныем. Тик икенче ягы бар: сине булдыра алмады, шуның өчен кайтты, диячәкләр. Әткәй өчен бигрәк тә бик авыр булачак. Кайтмыйбыз, Таһир. Сургутта җитәкчеләр күп, башкаларына мөрәҗәгать итеп кара.

Таһир әкрен генә тынычланырга тырышты. Шулчак аларга заводта эшләүче Мөхтәр Сәгыйтов килеп керде. Дингә битараф булмаган бу кешене аларга, әйтерсең лә, Аллаһ Үзе җибәрде. Исәнлек-саулык сорашып, йортка дога кылгач, Мөхтәр ярдәмен тәкъдим итте.

– «Москвич» машинам бар, кая кирәк, шунда алып барам, хәзрәт. Сургут шәһәрендә җәмәгать белән намаз укырлык бер йорт булса да табыйк. Су кудыру каналы җитәкчесе Әнвәр Зәйнуллин белән сөйләшеп карыйк әле, үзебезнең мөселман кешесе, – диде.

Шушы сүзне генә көтеп утырган Таһир, җанланып китте. Ярты сәгатьтән алар Әнвәрнең кабинетында утыралар иде инде. Таһир, мәчет салырга җир бирмиләр дип, проблемасын әйтте. Хуҗа аны илтифат күрсәтеп тыңлады.

– Безнең оешманың элекке урынында «Кызыл почмак» бинасы калды. Барып карыйк әле, мәчет итеп файдаланып торырлык әле ул, – диде.

Өчесе бергә «Кызыл почмак» бинасын карарга бардылар. Кыйблага юнәлгән. Каршысында – урман. Табигать кочагында бит бу! Ишеген ачып керсәләр, электр үткәрелгән, газ белән җылытыла. Таһирнең куанычыннан, сулышы киңәеп китте.

– Рәхмәт сезгә, Әнвәр дус! Вакытлыча файдалану өчен менә дигән бина бу! – диде.

...Икенче көнне Таһир «Кызыл почмак»ка Рәйсәне алып килде. Башта йортны юып чыгарырга, аннары обойларга кирәк, дигән ният белән икесе эш башладылар. Аларга булышырга иң беренче башкорт хатыны Хәдичә апа килде һәм җиңен сызганып, эшкә кереште. Әхәт Илялов исем-фамилияле җитәкче урындыклар, аның сәркатибе Галия Мәүлиева төргәге белән тукыма китерде. Нефтьчеләр паркындагы «Кызыл почмакта» гыйбадәтханә булачак дигән хәбәр, мөселманнар арасында тиз таралды. Булышырга килүчеләр саны көн саен арта торды. Рәйсә күрше йортта яшәүче Бәхия апаларга кереп, Галия китергән тукымадан пәрдәләр текте. Обойлап, яңа пәрдәләр дә элеп куйгач, «Кызыл почмак» бинасы, чын гыйбадәтханә йортына әйләнде. Таһир хәзрәт гарәп графикасы һәм намаз тәртипләре укыта башлады. Дәрескә йөрүчеләр ун кешедән башланды.

...Сургут җирендә Таһир хәзрәтнең беренче ярдәмчесе Наиф абый:

– Себер җирендә динне син торгызырга тиеш, энем! Монда кеше үлгәндә, җеназа да укылмады. Син дини тәртипләрне беләсең, барысын да җайга салырсың дип ышанам, – диде.

Гыйбадәтханәгә халык төрле сораулар белән килә башлады. Рәйсә көне буе иренең сәркатибе вазифасын башкарды, һәркемнең соравын игътибар белән тыңлап, иренә җиткереп торды.

– Руслар белән татарларның бер зиратта күмелгәнен беләсезме сез? Катнаш була алмый, моны аерырга кирәк, – диде урта яшьләрдәге ир кеше.

Таһир хәзрәт мөселманнар өчен аерым зират булдыру кирәклеген хакимият җитәкчеләренә шул көнне үк җиткерде. Мөселманнар белән христианнар өчен, аерым зират булдырылды. Элекке тәртип буенча кабер казучылар хәзрәттән аракы сорый башладылар.

– Болай ярамый, кардәшләр, ислам динебез буенча мәетне хәрәм эчеп озатмыйлар, сез зур гөнаһ эшлисез, – дип, башта аңлатырга тырышып карады.

Аракы корбанына әйләнгән кешегә мондый сүзләр генә үтмәвен аңлагач, андыйлар белән арасын өзде. Изге эшкә изге күңелле кешеләр табылды. Тәлгат белән Дамир үзләре теләп, зират каравылчылары булып эшкә алындылар.

– Хәзрәт, әйтергә дә оят, дини тәртипләрне белүче булмагач, монда моргта эшләүче руслар, татарларны да табут белән күмделәр. Зинһар, тәртип урнаштыра күрегез, – дип үтенде Тәлгат.

Шуннан соң гыйбадәтханә йортында Рәйсә абыстай мөселман кешесен кәфенләп күмү тәртибенә өйрәтә башлады.

– Зиратны тәртипкә салдык, хәләл ит белән туклану мәсьәләсен дә хәл итәсе иде, – диде Таһир хәзрәт. – Коръән ашы уздырганда итне кайдан аласыз?

– Хәләл итне авылдан алып киләбез. «Сайгатина» совхозы белән хезмәттәшлекне көйләп җибәрсәгез, бөтен халык рәхмәт әйтәчәк сезгә, хәзрәт, – диделәр Тәлгат белән Дамир.

Икенче көнне үк, Таһир хәзрәт «Сайгатина» совхозына барып, җитәкчесе белән очрашты. Хәләл итеп суйдыру тәртибен аңлатты. Бер атна эчендә бу эш җайга салынды. Үзенең кешесен алып барып суйдырды. Гыйбадәтханәгә суыткыч алып куелды. Мәҗлескә чакырып килүчеләрдән Рәйсә: «Хәләл итең бармы?», – дип кенә сорады, булмаса, үзе биреп җибәрде. Шулай итеп, мөселманнар хәләл ит белән туклана башлады.

Декабрь аенда Таһир хәзрәтне Хәмит Ясәвиев чакыртып алды. Якты йөз белән каршылады. Үзе дә аның каршына килеп утырды.

– Унике гаилә яши торган бараклар сүтеләчәк, мәчет өчен җир шул урыннан биреләчәк, - диде ул.

– Урыны әйбәт, ул баракларны кайчан сүтә башлыйлар?

– Сүтәргә шәхси эшмәкәрләр ярдәм итәчәк. Зур мәчет салганчы, башта кечкенәрәген салып карарга киңәш итәм, – диде Ясәвиев. – Халык күп йөри башласа, зурайтырбыз.

1994 елның май аенда иске бараклар сүтелеп алынды. Сентябрьдә яңа мәчет төзелеше башланды. Таһир хәзрәт төзелешне финанслауда, Хәмит Ясәвиев булышлыгына таянды. Ярты елдан артык вакыт эчендә 12х12 метрлы мәчет бинасы сафка басты. 1995 елның 25 февралендә Сургут шәһәрендә тантаналы төстә мәчет ачылды. Татарстаннан килгән зур кунаклар арасында республиканың баш казые Габделхак хәзрәт Саматов та бар иде. Себер җиренә аяк баскан көненнән алып, динне торгызу юлында күпме сынаулар аша узган улын кочаклап алды.

– Сабыр иткән – морадына җиткән, улым. Дин ул – безнең тормышыбыз, яшәешебез, кыйблабыз! – диде.

Яңа мәчетнең беренче азанын да Камил әйтте.

– Сургут шәһәре киләчәккә зур адымнар белән атлый. Себер җирендә нефть компанияләре колачлы төзелешләр алып бара. Халык саны елданел арта. Бу мәчет кенә мөселманнарның ихтыяҗны канәгатьләндерә алмаячак. Берничә елдан Россиядәге иң матур мәчет Сургутта булыр, дип ышанам, – диде Таһир хәзрәт, үзе күрергә теләгән мәчет белән мәдрәсәне күз алдына китереп.

– Амин, улым! Мин сиңа ышанам, – диде әтисе.

*Дәвамы киләсе санда*

*Гөлсинә Галимуллинаның*

*«Кайнар диңгез юлы» повестеннән өзек*